Инсур Мөсәнниф

# Озак яшәү сере





Инсур МӨСӘННИФ



# Озак яшәү сере

Хикәяләр, новеллалар, юмор һәм сатира

УФА
«КИТАП»
1999

84 Баш
Ш 24

**Мөсәнниф Инсур (Шәңгәрәев)**

Озак яшәү сере. Хикәяләр, новеллалар, юмор һәм сатира. Уфа: Башкортстан «Китап» нәшрияты, 1999. — 224 бит.

Яшь әдипнең тәүге проза китабы «Учак яктысы» һәм «Ялангач дивар заманы» дигән ике өлештән тора. Беренче бүлектәге хикәяләрдә замандашларыбызның катлаулы дөньясы җитди сурәтләүләр белән ачып бирелсә, икенче бүлектә исә автор һәр геройның бер «гыйльлә»сен табып, тормышыбыздагы кире күренешләрне көлкеле образлар аша тасвирлый.

84 Баш

ISBN 5-295-02132-7 © Мөсәнниф Инсур, 1999

ТП-61

# Учак яктысы



## АВЫЛ ҮРЕ

Гөлфая апаны бүген дә очраттым. Ул кече улы Илдарны җитәкләп, олы юлга карап, авыл үренә таба чыгып бара иде. Кичә дә, аннан алдагы көннәрдә дә күргән идем мин аларны... Сәбәбен дә беләм. Авылда да беләләр.

Гөлфая апа өлкән улы Нәфиснең армиядән хезмәтен тутырып кайтуын көтә.

* * *

— Ике ел үтеп тә киткән... Кара син аны, сизелми дә калды. Әле кичә генә Нәфисне солдатка озаткан кебек идек. Әй, бу гомеркәйләрнең су кебек агулары!

Мондый сүзләрне Гөлфая апа еш ишетә. Чит кешегә ни, тиз сыман инде ул. Ә көткәннәргә бик озак вакыт ул ике ел. Тик менә бер ай була инде Нәфиснең: «Көтегез, кайтам!» —дип хат язуына. Ә Гөлфая апа көтә, һәр көн көтә. Күңеле белән әллә нәрсәләр уйлап бетерде инде. Ниләр генә булмас, дисең. Аннан, курыкканга куш күренә, диләрме әле?

Ул Әфган дигән җир турында нәрсәләр генә сөйләмиләр...

Уйлары улыннан үткәннәренә, үзенең тормышына күчә.

...Хәтерендә әле. Аңа ике-өч яшьләр чамасы иде бугай. Әнисе, аны җитәкләгән килеш, күз яшьләрен сөртә-сөртә, авыл үреннән ераклаша барган олауларга карап тора. Әле бернәрсә дә аңламаган кызына, иелеп:

— Кул болга, кызым, әтиең сугышка китте бит, — ди һәм үзе аны күтәреп ала, тыела алмый шым гына елый. Гөлфая олауларга ак кулъяулык болгый. Ак юл сезгә! Ак юл... Олаудагылар да аны күрә, җавап булып берничә кулъяулык, акчарлак сыман, һавада тибрәлә. Өзек-өзек булып гармун, җыр тавышы ишетелеп кала да, олаулар борылмада күздән югала...

Соңыннан да күп тапкырлар килде алар әнисе белән авыл үренә. Тик әтисе генә күренмәде дә күренмәде. Олауларга төялеп киткән кешеләр дә берәм-сәрәм генә кайттылар. Ярты авыл ятим калды. Тик кайгы бөтен ил белән килгәнгәме, ил белән күтәрүе дә җиңелрәк булды.

...Әнисе әйткәндәй, гомеркәйләр аккан су кебек, ага да ага. Гөлфая да кул арасына керә башлады: буыннары ныгынып җитмәсә дә, фермага савучы булып эшкә китте. Үзе яшь, үзе уңган, өстәвенә, авылның беренче сылуы. Буй-сыны да килешкән, кайсы яктан карасаң да, кимчелеген таба торган түгел. Хәтта чәчләренә чал кереп, күңелләре мүкләнеп беткән агайларның да, аны күргәч, йөрәкләре жилкенеп куя. «Их, яшь чакларым кайда соң?!» — дип уфтаналар.

Ә фермада эш авыр, бар нәрсә кул көче белән башкарыла. Малкайларга эчерер өчен суын да елгадан көянтәләп ташыйлар. Ул чакларда ничек түзделәр икән, хәзер үзе дә аптырый. Көннәр буе фермада яткан чаклары була иде. Хәзер уйлап куя: ул авырлыкларга түзәргә аңа әллә сөюе ярдәм иттеме икән? Яшьлек мәхәббәтсез буламыни — Гөлфаяның да йөрәгенә ут капкан иде. Ничек кенә капкан иде әле — ялкыны, төтене башкаларга да күренмәдеме икән ул чакта?!

Электән үк бер-берсенә күз атып йөргәнгәме, тиз аңлаштылар. Аңлаштылар да, кавыштылар да. Заманына күрә артык зур булмаган туй үткәрделәр. Тик Хафизга армиягә китәргә вакыт җитте. Нәфис тумаган иде әле. Гөлфая Хафизны:

— Без сине икәүләп көтәрбез, — дип, авыл урендә елый-елый озатып калды.

Нәфис туды. Бик озак булса да, өч ел вакыт узып китте. Хафизның кайтыр вакыты җиткәч, улын йә күтәреп, йә җитәкләп, көн саен диярлек, авыл уренә йөри башлады. Үзе дә сизми, әллә күпме вакыт борылмадан күзләрен алмый, менә-менә, кош кебек канатланып, аның ире, сөйгәне килеп чыгар, дип көтте. Сулышы белән тартып алыр дәрәҗәдә сагынган иде Гөлфая аны! Очрашу минутларын көннәрен генә түгел, ә сәгатьләрен дә исәпләп көтте.

...Тик Хафиз кайта алмады.

Чик буенда, Ерак Көнчыгышта хезмәт итә иде ул. Ил сагындагы соңгы нарядларының берсендә, өч ел буе йөргән чик буе сукмагында, безнең илдән нинди генә юл белән булса да, теге якка чыгарга омтылган аеруча куркы-

ныч чик бозучыны тотканда авыр яраланган. Тик дошман да шунда үзенең үлемен тапкан. Ә Хафиз ике көннән соң, аңына да килә алмыйча, хәрби шифаханәдә мәңгегә күзләрен йомган.

...Авыр булды Гөлфаяның япа-ялгызына Нәфисне үстерүе. Кеше төрле сүзләр дә ишеттерде, кайсыбер азгын ир-ат та бәйләнеп азаплады: ул бит яшь иде, чибәр иде. Тик ул бирешмәде, тешен кысып түзде. Берсенә дә карамады. Мидхәтне очратканчы шулай дәвам итте. Ә Мидхәт, ничектер, аның күңелен эретә алды. Аны да тормыш нык кына каккан иде. Шуңа, ахры, Гөлфаяга Мидхәт:

— Бергә яшик, — дигәч, аңа кияүгә чыгарга ризалашты. Нәфис тә үсеп бара. Гөлфая, ияләшеп китмәсләр, дип бик курыккан иде, ярый әле шиге бушка булды. Улы үги этисенә тиз ияләште. Егет кешегә янында ир-ат булуы кирәк шул. Мидхәт тә аны үз улы кебек күрде, бер авыр сүз әйткәне, бер кырын караганы булмады. Үз улы Илдар тугач та үзгәрмәде ул Нәфискә. Әнә шулай дөнья мәшәкатьләре белән еллар үтә торды. Нәфискә дә армиягә китәргә вакыт җитте. Гөлфая апа аны да авыл урендә озатып калды. Үз гомерендә өченче солдат... Гөлфая апаның хәлен аңласа, күп нәрсәгә шаһит авыл үре генә аңлагандыр. Улы да күңеле белән сизенгәндер, тик аңа, яшь кешегә, армиягә китү сагышлырак булса да, барыбер бәйрәм генә.

— Әнкәй, нигә инде тагын елыйсың? Ике генә ел бит — тиз үтә ул, елама, — дип, аны юаткан була.

Менә озату минутлары да үтте, Нәфисне алып киткән машина артыннан тузан болыты

гына күтәрелеп калды. Нәфис үзен озатырга килгән авылдашлары, Илдарны җитәкләп басып торып калган әнисе күздән югалганчы ак кулъяулык болгап барды. Гөлфая апага бу еракта калган хатирәләрне исенә төшерде. Аннан, елаудан кызарган күзләрен сөртә-сөртә, авыл ягына борылды... Мидхәт тә, аның хәлен аңлап, төрлечә юатырга тырышты.

Һәм менә ике ел үткән дә. Гөлфая апа көн дә диярлек авыл үренә килеп, озак итеп улы кайтасы юлга карап тора. Тузанлы авыл юлы борылмага, икенче үргә кадәр караеп ята. Тик анда әлегә беркем дә күренми. Гөлфая апаның уйлары һәрчак улы тирәсендә әйләнә. Үзгәрдеме икән? Үзгәргәндер. Ике ел гомер аз түгел. Аннан, хезмәт — хезмәт инде, ялга да кайта алмады. «Бәлки кайтарырлар да әле», — дип хаты килгән иде. Хезмәтендә хәлләр үзгәреп киттеме — ана күңелен җилкендерүе генә калды, кайтмады. Армия хезмәтен аңлый Гөлфая. Кайта алмаса да, үпкәләп булмый. Шар сугып йөрми. Исән генә булсын. Ни боералар — шуны үти. Әйе, Нәфис үзгәргәндер инде. Атасы кебек озын буйлы, ябыграк кына гәүдәле иде. Инде хәзер ир булгандыр. Олпатлангандыр. Элек тә йөзгә нәкъ Хафиз иде. Гөлфаяның йөрәге сызып китте. Ә хәзер Хафиз нинди булыр иде икән? Билгеле, яше буенча ир уртасы кеше, йөзгә дә олыгаер иде. Һаман да Гөлфаяны өзелеп яратыр идеме икән? Гөлфая үзалдына елмаеп куйды. Яратыр иде. Күзләрендә нинди сөю балкый торган иде — унҗиде яшьлек кыз түгел, таш эрерлек. Ә ул... Менә ничә ел инде икенче кеше белән яшәп ята. Юк, үзен аның истәлегенә хыянәт итте дип исәпли алмый ул. Ун

ел оныта алмады, аның белән үткәргән һәр көнен хәтерендә тотты... «Тик, гафу ит, Хафиз, тереләргә яшәргә кирәк. Син аңлыйсыңдыр мине — яраткан кешеләр бер-берсен аңларга тиешләр. Тормыш бер урында тормый, һаман алга бара. Менә улыбызны армиядән көтәм. Аның энесе, син аны белмисең инде, алты яшьлек Илдар да көтә абыйсын. Урамда берәрсе очратып:

— Абыең кайтмадымы әле? — дип сораса: «Юк шул, кайтмый да кайтмый», — дип нәүмизләнеп җавап бирә, күзләреннән менә-менә яше атылып килеп чыгар төсле...» Гөлфая кече улын аркасыннан тупылдатып сөеп куя. Илдар аңа күтәрелеп карый.

— Их, бәләкәчем, сине дә солдатка озатыр көннәрне күрәсе бар бит әле, — дип ана улының башыннан сыйпый.

— Ә мин солдат булмыйм, — ди Илдар, энисенә сыенып.

— Ничек инде — булмыйсың? Ә безне кем саклар?

— Ә мин генерал булам.

— Булырсың, улым, булырсың, — дип елмая аның сүзләренә Гөлфая.

Алар кайтырга чыкты. Илдар беркадәр ара энисе белән җитәкләшеп килде дә, ниндидер кызык нәрсә күреп, алга йөгерде. Аңа ни, дөньядагы бар нәрсә дә кызыктан гына тора кебек шул әле.

...Сәгатьләрен генә түгел, минутларын да санаган тагын берничә көн үтте. Ятса да, торса да, Гөлфаяның уенда улы булды. Борчылып бетте. Ә Мидхәт аны тынычландырырга тырыша:

— Үз-үзеңне бетермә әле, энисе. Кайтыр.

Үз ихтыярында булса, анда калмас, — ди. Әй, шул ирләрнең...

Шулай да, Нәфис кайта, дигән хәбәргә үзен никадәр генә әзерләмәсен, бу аңа көтелмәгәнчәрәк яңгырады.

Ишек алдына утын алырга дип чыккан иде. Ашыга-кабалана капкадан кереп килгән хат ташучы кызны күргәч, Гөлфаяның йөрәге «жу» итеп китте. Тиз йөрүдән Ленаның йөзе алсуланып киткән, үзе еш-еш тын ала. Тик аның шатлыклы елтыраган күзләрен күргәч кенә, хәбәрнең яхшы булуына ышанды.

— Гөлфая апа, сөенче! — дип әйтеп салды хат ташучы кыз, аның янына килеп җитәр-җитмәс элек, шат елмаеп.

— Йә, хат бармы, саескан, әйт тизрәк, — дип аны ашыктырды Гөлфая.

— Ә сөенчегә ни бирәсең? Бу юлы сөенчегә бирәр нәрсә бирмичә котыла алмаячаксың. Кәнфитең кирәкми, күлмәкме анда...

— Соңыннан, кызым, соңыннан... Кайчан буш иткәнем бар?.. Ярар инде, Лена кызым, тилмертмә. Ә хәзергә сөенчегәме? Сөенчегә — ике колагың үзеңә... юк, сөйгәнең сөендерсен.

— Әй, синең шул булыр инде. Ярый, хат кына булса, сөенчесез һич бирмәс идем... — Аннан бертын белән әйтеп салды: — Гөлфая апа, Нәфис кайтты!

— Кайда?! Кайда ул?! — Гөлфая апа кулыннан кочагы белән утыны төшеп киткәнен сизми дә калды, үзе чак, һушы китеп, җиргә утырмады.

— Ә ул безнең авыл үрендә утырып калды. Күрше авылдан олы юлдан үргә кадәр бергә кайттык. Үргә җиткәч, ул: «Лена, бар, син кайта тор, ә мин азрак утырып торам эле.

Авылыбызның шушы үре ике ел буе төшемә керде, бер дә юкка түгелдер», — ди. Үзе уйчан гына көлә. Ә мин әй йөгердем, әй йөгердем, сөенче алыйм, дип... Нәфис: «Әнкәй белән эткәйгә әйтми тор, көтмәгәндә кайтып төшим әле», — дигән иде дә, мин түзмәдем инде, серне чиштем. Ничек түзмәк кирәк. Нинди шатлык бит...

— Нигә инде аны шунда ук әйтмисең? Их, кызым, кызым, ана йөрәген аңлап, белеп бетермисез шул, — дип сөйләнеп, Гөлфая апа, күлмәгенә ябышкан чүпләрен кага-кага, капкадан чыгып йөгерде.

«Син үзең бернәрсә дә белмисең, Гөлфая апа», — дип уйлап, аның артыннан елмаеп карап калды Лена. Аннан алсуланып киткән битен куллары белән каплады. «Без Нәфис белән ике ел буе хат алыштык, мин үзем хат ташучы булгач, хәтта әнием дә белми бу хакта», — дип әйтмәс бит инде. Ә Нәфиснең аны әле генә суырып үпкәнен Лена үлгәндә дә берсенә дә әйтмәячәк. Әле дә иреннәре ут кебек янып тора.

...Нәфис тирә-ягына тагын бер кат күз йөгертеп чыкты. Менә ул аның туган ягы! Кабул ит солдатны! Киткәндә малай озатсаң, ир-егет булып җиткән узаман каршыла. Синнән элек тә күпләр киткән — кемдер үз ирке белән, кемдер мылтык көбәге астында, кемдер илне сакларга — һәм күбесе кире әйләнеп кайтмаган. Каберләре кайда икән аларның — беләсе иде. Нәфисләр затыннан да аз түгелләр бит. Ә менә Нәфис кайтты. Яшәргә, балалар үстерергә, эшләргә кайтты. Һәм яңадан солдат киеме киярго туры килмәс, дип кайтты.

Карашын ераккарак күчерде. Монда, туган

як кырларында, урманнарында үзгәреш сизелми. Авыл да һаман шул ук кебек. Хәер, шул укмы икән? Әнә, ике ел эчендә авылда дүрт буш өй урыны арткан. Икесе — өлкәннәр, ялгыз карчыклар өе урыны, ә икесе... Нигә китәләр кешеләр туган яктан, үскән җирдән? Нигә туктатмыйсың аларны, авыл үре? Нәрсә куа аларны? Куучы да юк кебек. Әллә алар үзләреннән үзләре качамы? Нигә аркылы төшмисең? Калага да китми алар, ә шул ук авыл җиренә, баерак колхоз-совхоз карамагына. Ә туган як, алар киткәч, тагын да ярлылана төшә, тагын бер бизәге юкка чыга. Авыл үре, төш юлларына каршы — алар бит сугышка китми, киресенчә, тылларын ялангач, саклаучысыз калдыра. Ә тыл һәрчак ышанычлы булырга тиеш. Хыянәткә тиң бит бу кыланышыгыз. Их, кешеләр... Бер җирдә дә бәхетне олы юлга чыгарып куймаганнар. Ә Нәфис... үзе нәрсә эшләр? Юк, китмәскә кайтты ул. Һөнәре бар, колхозда машина табылыр. Утларына да керде, суларын да кичте, пуля, мина ничек сызгырганын да кинодан түгел, ә сугыш яланында күреп белде. Сугыштагы авырлыкны җиңгәнне, тыныч тормыштагысын җиңеп булмасмыни? Уйла, Нәфис, уйла. Туган ягыңа, тирә-ягыңа кара да, уйла. Уй барда — тормыш та бар...

Нәфис аягүрә басты, билен ныграк кысып буып, тиздән салынып, чөйгә эленәчәк хәрби киемен рәтләде... Алда көрәш көткәнен кечәге солдат яхшы аңлый иде.

...Гөлфаяга элек якын гына, бер-ике чакрым гына булган авыл үре ерагаеп киткән сыман тоелды. Ничек шәп атларга тырышмасын, һаман барып җитә алмый. Үзенең күз-

ләре авыл урендә. Ниһаять, аннан кызу-кызу атлап килгән солдат күренде: ул да әнисен таныды бугай. Аралары якынайганнан-якынайды. Кинәт Гөлфая дертләп китте, чак кына: «Хафиз!» — дип кычкырып җибәрмәде. Әле аңа таба йөгерүче, әйтерсең, Нәфис түгел, ә Хафиз иде. Охшаса да охшар икән — йөрешләренә тиклем әтисенеке бит. Гөлфаяның уйлары чуалды, күз аллары томаланды. Солдат анасы, үзе сизмәсә дә, туктап, юл уртасында басып тора иде. Улы йөгереп килде дә, аны кочаклап алды, чемоданы җиргә төшеп китте. Ә ана башын улының күкрәгенә терәде дә, моңа кадәр ничә ел тыеп килгән күз яшьләренә ирек бирде. Ә солдат киемендәге егет сүзсез генә әнкәсен юатып, аның вакытсыз чал керә башлаган чәчләреннән сыйпый да сыйпый иде.

* * *

Шулай да Нәфиснең кайтуына бар кешедән дә ныграк сөенгәне Илдар булды бугай. Абыйсы кайтып ярты сәгать вакыт үттемеюкмы, ул солдат фуражкасын киеп, түшенә аның хәрби бүләкләрен тагып, урамда йөреп ята иде. Ә үзе, әйтерсең, бер башка үсеп киткән, шатлыгы эченә сыймый. Телен дә йотканмы, апаларның, әбиләрнең:

— Абыең кайттымы әллә, Илдар улым? — дигән соравына, авызын колагына тиклем ерып, баш кагып кына җавап бирә. Абыйсын менә ни өчен көтеп алалмаган икән ул!

И-и, бу сабый чак, сабый чак!

## ҚАЙТУ

Ислам, Куктауның башына менеп житкәч, азрак аякларын ял иттереп алырга уйлады. Инде ашыкмаса да була. Өч-дүрт чакрым үтеп, әнә теге тауга күтәрелүгә аның авылы күренәчәк. Аннан бары тауны төшәсе дә (алар ягында барлык калкулыкларны, үрләрне халык тау дип йөртә), елганы күпер аша чыгасы гына кала. Әйткәндәй, боз киттеме икән әле? Апрель уртасы бит. Элек сугышка кадәр боз киткәнен карарга бөтен авыл җыела торган иде. Ташлыелга эссе җәй көннәрендә саегып, әллә ни киң кебек күренмәсә дә, язгы ташу вакытында үзен бер күрсәтеп ала. Боз киту вакыйгасы авылдашларына киләсе елның язына кадәр сөйләргә җитә. Аеруча берәр хәтергә сеңеп калырдай хәл булса. Барысыннан да бигрәк бала-чага көтеп ала инде ул боз китүне. Ә олыларга мәшәкате күбрәк. Ел саен диярлек күпме көч салып төзегән күперне алып китә. Ә күпер — алар авылы өчен зур дөнья белән бердәнбер бәйләнеш җебе дисәң дә, ялган булмас. Ул киттеме, станция белән, район үзәге белән ара өзелә. «Их, шуны тимердән мәңгелек итеп салып куярга», — дип хыялланды авыл халкы. Бәлки, сугыш комачауламаса, салган да булырлар иде. Ә хәзер авылда күпер салырлык түгел, ат җигәрлек ир-ат калды микән?.. Уе үзенекеләргә күчте. Аны көтәләр булыр. Сәкинәсе дә, уллары да. Үзе бит госпитальдән: «Көтегез, сугыш бетүгә бер ел дигәндә, «тып» итеп кайтып та төшәрмен, Алла боерса», — дип хат язган иде. Тик менә бик «тып» итеп булмый әле. Аяклары сызлап, тыңламаска

итә. Ичмасам, берсе генә яраланса икән. Юк бит, инде сугыш бетте, дигәндә, ике аягы да яраланды. Немец, каһәрең, ничек эләктерде, диген: уң аякта ике, сул аякта бер тишек. Итенә генә тисә дә бер хәл, сөяге нык зарарланган иде. Шифаханә караватында бер ел аунарга туры килде. Әйтүе генә ансат — бер ел. Тик шулай да кисәргә бирмәде аягын. «Хәзер сугыш бетте, озак булса булыр, тик кисәргә бирмим. Хәзер безгә аякның иң кирәк чагы — эш җитәрлек булачак», — дип кабыргасы белән куйды таләпне. Ярый әле, бәхете, аңын югалтмаган. Сизми дә калыр идең таптаза килеш гарип булып калганыңны. Менә бит, теләгәч, була икән. Табибларга рәхмәт инде, тырышмадылар түгел, тырыштылар, аяклы иттеләр... Ул канәгать төс белән елмайды да, хәл җыйган аякларын сыйпап куйды. Аннан саклык белән урыныннан күтәрелде. Җирдән биштәрен алып иңбашына кигәч, аны рәтли-рәтли, ашкынып, үргә карап кузгалды.

Язгы кояшта изелгән юлдан баруы җиңел түгел, шуңа ул карлырак урыннарны сайларга тырышты. Үз уйларына бирелеп атлый торгач, авылны күздән яшереп торган үр башына менеп җиткәнен сизми дә калды. Туган авылының тулы күренеше ачылды. Үзгәргән дә, үзгәрмәгән дә кебек. Юк, үзгәреш бар икән: берничә йорт урыны буш тора. Урман ерак булгач, озын кыш көннәрендә утынга яктылар микән? Өй тирәләрен әйләндереп алган коймалар да күп урында юкка чыккан. Аннан, йортлар нигәдер бәләкәйләнеп, җиргә сеңә төшкән кебек. Әллә биш ел эчендә авыл буенча сибелеп утырган, хәзер тагын да сирә-

гәйгән агачлар үсә төшкәнгә шулай тоеламы? Ислам йөрәгенең дөпелдәвен басарга тырышып, бер минут чамасы еш-еш сулыш алып, авылга карап торды. Ә-ә-әнә, аның өе. Хатыны, балалары ни эшли икән? Менә хәзер үрне төшәр, елганы кичәр... Тик күпер кайда соң? Бер-ике баганасы гына серәеп тора (күпернең, бозлар кысымына түзми, иртән генә, җимерелеп, агып киткәнен ул белми иде). Ташлыелга киң булып җәелгән, ярларга сыеша алмый бозлар ага. Әх, хәерсез икән. Инде ничек чыгасы?.. Кайтып җиттем дигәндә, менә сиңа кирәк булса...

Ул, килеп туган хәлдән чыгу юлларын уе белән барлый-барлый атлый торгач, ярга килеп терәлде. Арытаба юл юк, аяк астында шаулап елга ята, бозлар, актарылып, өзлексез ага да ага.

Әнә, ярның теге ягында биш-алты кеше җыелып та өлгергән. Аның таудан төшкәнен үк күреп-күзәтеп торганнардыр инде. «Безнекеләр түгелме икән?» — дип уйлый булыр һәркайсы. Сәкинә язган иде, кайтасы кешеләр бар әле, дип. Ә бик күпләр мәңге кайтмаска калды... Аның күршесе Заһитның да үле хәбәре килгән. Хатыны Зарифа биш бала белән ничек яшәп ята икән? Булышасы булыр. Ни генә димә, Заһит белән ничә ел ут күрше булып яшәделәр.

Ә теге якта кеше һаман арта. Үзара сөйләшәләр. «Нәрсә эшләргә?» — дип, киңәш итәләрдер. Бер-ике малай авылга карый чапты. Әллә, танып, сөенче алыргамы? Таныганнардыр, танымый буламы соң. Шулай икән шул. Әнә, авылдан елга буена таба бер ха-

тын йөгерә, үзе нәрсәдер кычкыра. Кара, Сәкинә бит, «Ислам!» — ди, ахры.

Дөрестән дә, бу Сәкинә иде. Яр буена килеп җиткәч, ул тагын:

— Исламкаем?! Синме?! — дип кычкырды. Тонык булса да, монысы килеп җитте.

Ислам да, түзми, кул болгап:

— Сәкинә, мин бу, мин! — дип кычкырганын сизми дә калды. Сәкинә тагын нидер әйтергә уйлаган иде, күз яшьләренә буылды бугай. Башка хатын-кызлар, аның янына җыелып, юата башладылар. Еламаслыкмыни?! Ничә ел бит, ничә ел, исән-сау булгач, әнә...

Шунда Сәкинә янына ике малай йөгереп килеп туктады да, икесе бертавыштан:

— Әткәй! — дип кычкырып җибәрделәр. Малигы белән Хәмите! Исламның тамак төбенә яшь тыгылды. Аларны ишеткәнен аңлатып, башын кагарга гына көче җитте.

Халык теге якта һаман киңәшләшә иде.

— Көймә белән керерлек түгел, агым көчле, бозлар да һаман азаймый. Бер-ике көн көтми чара юк.

— Ә ул нишләр?

— Өенә ярты чакрым калгач, яр башында кунармы?

— Берәр юлын табарга кирәк!

Шулайрак сөйләшәләр иде, ахры. Шунда малайларның зуррагы кызып-кызып нәрсәдер аңлата башлады. Кулы белән бу якка төртеп күрсәтә. Тик олылар аны тыя, ахры, әнкәсе кулыннан ук тотып алды. Ә тегесе һаман тарткалаша. Ул да булмады, малай әнкәсе кулыннан ычкынып китте, йөгереп барып боз өстенә сикереп тә менде. Халык «аһ» итте. Исламның йөрәге кысылды. Су төбенә китә

бит, юньсез! Тик малайның су төбенә китәргә уенда да юк иде, ахры. Мәче житезлеге белән бер боз өстеннән икенчесенә сикерә. Боз аның авырлыгыннан су астына китәргә өлгерми, ул инде икенче, өченче боз өстендә.

Кешеләр теге якта тын алырга да куркып тора. Ә Исламның йөрәге бөтенләй тибүдән туктады кебек. Бу як ярга якынлаша башлагач кына, йөрәгенә жылы йөгерде. Шулай да, улы егыла-нитә калса дип салып ташлаган шинелен кияргә ашыкмады. Ислам ярдан ерак түгел яткан бер колганы әләктереп алган иде, шуны тоткан килеш яр буенда ук басып тора. Менә улы соңгы боз өстеннән ярга сикерде, чатыр чабып килде дә, кинәт, тыны беткәндәй, Исламның каршысында туктап калды. Атасы, дулкынланудан тавышы калтырап:

— Улым... — дип чак әйтә алды.

Шунда гына малай, бу аның әтисе икәненә тәмам ышанып:

— Әткәй!.. — дип, муенына килеп асылынды.

— Улым, улыкаем, шулай ярыймы соң, ә?! Боз астына китсәң? — Ислам аны орыша-орыша иркәләде, сөйде. Үзенең күзләреннән яшь ага. — Зур булып үскәнсең, ә акыл кермәгән, — дип яшь аралаш елмаерга тырышты.

— И-и, бу нәрсә генә ул, — дигән булды Хәмит, һаман аны кочаклаган килеш, бар гәүдәсе белән сыена төшеп. Исламның тамагына килеп тыгылган төер һаман сөйләшергә ирек бирми, үзе Хәмиттән күзен ала алмый, башыннан сыйпады да сыйпады.

— Ә без сине көттек тә көттек. Менә кайта, менә кайта, дип көн дә елга буеннан

кайтмадык. Ә күпер бүген генә китте. Үч иткән кебек бит. Сугыш беткәнче торды, ә бүген... китте, — диде Хәмит, серәеп торган баганаларга карап.

— Кайгырма, улым, без аны тимердән салачакбыз. Сезнең кебек малайлар булганда-мы?! Әнә, Күктауны күчерергә була.

— Һе, күчерерсең, бар. Анысы булмас. Ә менә тимер күпер ярар иде, — дип Хәмит, олыларча, хыялга ук бирелеп китте.

«Әйе, үскән егет булган, ундүрте белән бара бит, — дип уйлады Ислам улының сүзләрен шатлык белән тыңлый-тыңлый. — Ир корына иртәрәк керәсез дә ни, тик нишлисең, заманы шундый туры килде».

Хәмит шунда аның кочагыннан чыгарга була тартылып куйды. Ислам кулларын бушандырды да, сиздерми генә көлемсерәп, читкә карады. Егет кеше егетлеген итә шул. Булды, азрак иркәләнде, ә хәзер үзе ояла да бугай. Янәсе, артык йомшаклык күрсәтте түгелме? Ислам, сүзсез генә, авыр кулын улының иңбашына салып, авыл ягына караш ташлады. Актарылып-актарылып бозлар ага. Теге якта халык тын гына сөйләшеп, аларга карап тора. Сәкинә, Маликны кочаклаган да, яшьле күзләрен алардан ала алмый. Аның тирәсенә җыелган берничә хатын-кыз акрын гына нидер гәпләшә. Исламның башында исә, бу килеп туган хәлдән чыгу юлларын эзләп, уйлар кайнаша. Ни кылырга, нәрсә эшләргә соң әле? Шунда үзе дә сизми:

— Йә, улым, инде нәрсә кылабыз? Безгә бит хәзер теге якка чыгарга кирәк.

— Уһу. Мин ни, чыгармын ул. Тик син...

— Юк инде, улым, алай үлем белән уйна-

мыйлар. Дүрт ел үлем арасында йөргән дә җитәр. Безгә хәзер яшәргә дә яшәргә. Яшәү өчен күпме кан коеп, Гитлерны дөмектердек. Күпме кеше гомерен бирде, башын салды. Барысы да шушы көн өчен... — Ул улын үзенә ныграк тартты. Менә бит, барысы да артта калды. Дөрес, әле алда эш күп булачак. Сугыш җимергәнне төзәтәсе, сезне чын солдат итеп үстерәсе бар...

Хәмиткә күптән нәрсәдер тынгы бирми иде, ахры. Ни хакындадыр сорарга омтылып, еш-еш әтисенең йөзенә күтәрелеп карый. Шуны сизеп, әтисе:

— Нәрсә, улым? — дип сорады. Малайның күзләре ут булып янып китте.

— Әти... — Хәмит туктап тын алды, әйтерсең, әле әйткән сүзенә колак салды һәм шунда гына үзенең нинди бәхетле кеше икәнен бөтен тирәнлеге белән аңлады. Әткәй... Әткәй... Күпме көтеп алынган, ничә тапкыр эчтән генә кабатланып, әйтеп каралган, әткәй, дип эндәшер кешене көтеп алалмаган. Һәм менә — ул аның белән янәшә, аның куллары — иңендә. Моңардан да зур бәхет бармы соң малай кешегә?!

— Әткәй... — дип кабатлады ул яңадан, дулкынланудан тыны кысылуын чак-чак тыеп, — медальләреңне күрсәт әле...

Ислам көлеп куйды. Менә нәрсә тынгы бирми икән солдат улына.

— Бик күрәсең киләмени? Хәзер, алай булгач... — Чүгәләп, биштәрен чиште дә, кадерләп төрелгән кечкенә төргәкне таратты. Язгы кояшта берничә көмеш түгәрәк ялтырады. — Менә шулар инде алар...

Хәмит берсен сак кына кулына алды:

— Уһу... «За отвагу»... Ә моны сиңа кайда, ни өчен бирделәр? Немецларны күп үтергән өченме?

«Үтергән өченме?..» Ислам дертләп куйды. Сугыш... Кем уйлап чыгарган да, кем кеше үтерүдән тәм тапкан икән беренче тапкыр? Сугыш тынып торган араларда күп уйлана иде бу хакта Ислам. Бер генә фашистны теге дөньяга озатмады ул. Өстенә ут яуганда, сине үтерергә дип ажгырып дошман килгәндә кызгану хисе булмый. Ә менә сугышлар тынган арада... Ул бит кеше үтерә, бөҗәк түгел... Ә тыныч тормышта сәбәпсез малны да рәнҗеткәне булмады аның. Аларның да балалары бардыр... Тик яндырылган, атылган, киселгән, мәсхәрәләнгән совет кешеләрен күрәсең дә, уйлыйсың: юк, бу аңлы кеше эше түгел, бу — ерткыч эше. Ә ерткычларны юк итәргә кирәк. Һәм син күбрәк үтергән саен корбаннар саны азаячак кына. Һәм ул атты, тешен кысып атты, чөнки алар аның ике улына, хатынына, үзенә штык төзәп, ут яудырып килә иде...

— Ә-ә, бу, улым, фашистларның берничә атакасын кире кагып, дошманны үткәрмәгән өчен, — диде аннан улының башыннан сыйпап. Улының канәгатьсезлек сизелеп калган чыраен күреп, аны тынычландырырга ашыкты. — Ярый, улым, кайгырма, соңыннан иркенләп бер сөйләрмен әле. Менә өйгә кайтып керик, өстәл артына иркенләп утырыйк. Барысын да, барысын да энәсеннән җебенә кадәр сөйләрмен. Тыңларга иренмә генә... — Шулай дип, Ислам тынып калды, янына чүгәләгән Хәмитнең аркасыннан сөеп куйды.

Бераз тын тордылар, аннан Ислам:

— Анысы булыр. Тик менә безнең алда сугышчан бурыч тора бит әле: теге якка ничек чыгарга? Шул хакта уйлашыйк.

Хәмит калкынып куйды, нәрсәдер исенә төште бугай.

— Иртәнчәк мин Мөхтәрәм бабайның бу якка көймә белән чыкканын күргән идем. Ә кире кайтканын шәйләмәдем. Бозлар бирәр урында тыгылып, елга ачылган вакытны сагалап торгандыр да, кичеп чыккандыр. Чытырлыдагы кызы каты авырый, шуңа хәл белергә киткәндер. Көймәсе, булса, әнә теге әрәмәлектә генә булыр.

— Әйдә әле, алай булгач, карап килик.

Чыннан да, бераз эзләгәннән соң, зиреккә юкә бау белән бәйләп куелган көймәгә юлыктылар. Мөхтәрәм абзый барыбер бүген генә кайта алмас, ә иртәгә күз күрер. Көймәне чишеп алып, суга этеп төшерделәр. Ислам бая тапкан колгасын үзе белән алган иде, Хәмит көймәдә калдырылганына тотынды.

Аларның көймәдә чыгарга җыенуларын күреп, халык төркеме дә ургә күтәрелде. Тик бер ир кеше, ә, Җәүдәт бугай, сул кулы белән елга үренә күрсәтте. Буш уң җиңе бил каешына кыстырылган. Сугышның икенче елында ук өздереп кайткан иде ул аны, Сәкинәнең хатыннан белә. Элек атаклы гармунчы Җәүдәт белән аз әйләнмәде авыл урамнарын яшь чагында Ислам. Көймәдәгеләр ул күрсәткән якка карады. Эре-эре боз кисәкләре агып килә, димәк, аларны уздырып җибәрергә кирәк. Хәзергә Ислам көймә тактасына утырып, тәмәке төрергә тотынды. Хәмиткә дә эш табылды: ул көймәгә кергән суны махсус эшләнгән кечкенә агач көрәк белән түгә башла-

ды. Тәмәкесен суыра-суыра, улыннан авыл хәлләрен сорашты. Авыл халкы авыр, ачлы-туклы яши, анысын белә Ислам. Орлык җитми, атлар аз, камыт-арбалар искергән. Бу эшкә аның кулы бара, бәлки шуңа алыныр. Язгы чәчү дә җитеп беткән. Ничауа, ерып чыгарлар, башлар исән бит. Аяклар да, Алла боерса, рәтләнеп китәр. Бик авыр күтәрмәскә кушты-кушуын табиблар. Белмим, авылда җиңел эш бармы икән ул хәзер? Булса да, аңа тәтемәс. Хәзер үк сизеп тора Ислам — мичәүгә ныклап җигелергә туры киләчәк. Әнә, авылда ир-ат сирәк кенә калган, төп көч — хатыннар, аларга ярдәмгә — карт-коры, бала-чага бар.

Югары яктан килгән бозлар үтеп китте. Ислам елга үренә карады. Артык куркынычлары күренми, ахры.

— Әллә тәвәккәллибезме, улым? — дип эндәште улына.

— Әйдә соң, күпме көтәргә була. — Анысының әтисе янында батыр булып күренәсе килә, сер бирмәскә тырышуы да шуннан.

— Ярый, Аллага тапшырдык, — дип Ислам, учларын төкреклэп, колгага ябышты. Хәмит тә, әтисе эшләгәнне кабатлап, авыр көймәне ярдан этеп җибәрергә ярдәмләште.

— Кайгырма, улым, сугышта моңардан биш тапкыр киң елгаларны «эһ» тә итми кичеп чыга идек, Ташлыелганы да «алырбыз».— Әтисе улын дәртләндерде, шаяртып күз кысты. Малайның күңеле булып, авызы ерылды. Тагын да көчлерәк ишәргә тырышты.

Теге ярга ерак та түгел кебек үзе. Тик көймә әледән-әле бозларга төртелә, аларны читкә этәргә яисә уздырып җибәрергә туры

килә. Шуңа көймә алга авырлык белән генә бара.

— Әй, тизрәк булыгыз, зур боз килә! — дип кычкырып җибәрделәр шунда ярдагылар. Әллә кайдан гына килеп чыккан — андыймондый нәрсә сизелми кебек иде. Хәзер артка да юл юк, бары тик алга гына. Ә боз, юлында очраган бар нәрсәне вата-кыра, бик тиз якынлаша. Авыртмаган башка тимер таяк булды бит әле бу...

— Әйдә, улым, житезрәк! — дип Ислам улын дәртләндерде. — Зарар юк, елганың уртасына җиттек инде... — Һәм колгасын янәшәдән узып барган бозга терәп, көчәнеп этеп җибәрде. Шунда «чырт» иткән тавыш ишетелде, колга шартлап сынды да, Ислам, тигезлеген югалтып, салкын суга барып төште, йөзе белән бозга бәрелде. Язгы су тәнен өтеп алды. Ярдагы халык «аһ» итте. Улы Хәмит тә чак егылмый калды.

— Әткәй! Әткәй! — дип өзгәләнде ул.

— Колгаңны суз, колгаңны, Хәмит! — дип кычкырышкан авазлар ишетелде. Юеш колга кулдан шуды, авырайган кием, биштәре, чолгаулы ботинкалары аска сөйрәде. Шулай да бераз вакыт өстә торырга үзендә көч таба алды. Күзенә улының куркудан агарынган йөзе, яр буенда арлы-бирле чабышкан кешеләр чалынып калды. Якынаеп килгән зур боз кисәген уйлады.

— Улым, улым, ярга, ярга иш! — дип Хәмиткә эндәшергә көч тапты. — Миңа карама, үзеңне уйла! — дип күшеккән иреннәрен чакчак ачты. Авызына су тулды. Аякларын көзән җыерды.

— Ярга, ярга иш, Хәмит! — Ярдагылар да

малайга киңәш бирде. Ә зур боз кисәге якынлап беткән иде инде. Гаҗизлектән елый-елый, соңгы көченә иште малай. Боз тавы аның көймәсе койрыгы янынннан гына ажгырып агып узды.

Ислам, ничә тапкыр үлем белән очрашкан кеше, ләкин аны да курку биләп алды. «Менә кайда килеп тоттың син мине, үлем! Иң үкенечлесе — кайтып җиткәч бит! Сәкинәсе, уллары нәрсә эшләр? Их!.. Ярый, һич югы өлкән улын күреп, сөеп кала алды. Рәхмәт сиңа, Хәмит улым...» Бар көченә ярга йөзәргә тырышты. Тик табигатьнең кыргый көче гади кешенекеннән күпкә зур иде. Барсын куркуга салган боз да якында гына... Ул улының көймәсе ярга җиткәнен күрде... Һәм шул мизгелдә актарылып килгән боз аны үз астына бөтереп алды. Исламның башы тагын бер күренеп калды да, ташкын үз эченә йотты...

Исламны икенче көнне генә, егерме чакрым түбәнрәк урыннан табып алдылар. Ташкын аны елганың борылган җирендә ярга чыгарып ташлаган һәм ул йөзтүбән, газиз туган туфрагын кочаклагандай, ике кулын ике якка җәеп, яр буенда ята иде...

Бу вакыйгадан соң күп еллар узды. Аны хәзер кешеләр хәтерләмиләр дә. Бары тик өлкән буын кешеләре яки туганнары гына исләренә төшерсә төшерәдер. Ә елга корыды. Хәзер ул киңлеге дүрт-биш метрдан узмаган кечкенә инешкә әверелде. «Элек безнең елга шундый киң, ике тегермән ташы әйләндерә иде», — дип сөйләсәләр, яшьләр моңа ышанмый да, көлеп кенә куя. Ә кемнәрдер: «Сәкинәнең каргышы төште аңа. «Корыган көннәреңне күрсәм иде», — дип каргады», диләр.

Корыганын күрде Сәкинә әби. Вафатына да күп вакыт узмаган әле. Гомере булгач, оныкларының балаларын да күрергә насыйп булды. Ә аның каргышына килгәндә инде... Белмим. Хәер, Ходаның кодрәте киң... Иксез-чиксез Җиһанда ни булмас, дисең...



## ЮЛДАГЫ СӨЙЛӘШҮ

Безнең участок шифаханәсенә яңа баш табиб җибәргәннәр, шуны каршы алырга килешем. Хастаханәнең үз машинасы ватылган, шуңа бу эшне рәис миңа йөкләтте. «Район бүльнисендә булыр, шуннан эзләп табарсың», — дигәннәр иде. Көтеп тормаган, ахры. Берәр техника очрап, утырып киткәндер — таба алмадым. Машинаны кабызып, кайтырга кузгалдым.

Район үзәген чыгып, үзебезнең якка бара торган юлга борылуга, өстенә кара костюм кигән (шушындый эссе көнне!), кулына артык зур булмаган чемодан тоткан уртача буйлы ир кеше кулын күтәрде. Мин туктагач, кабинаның ишеген ачып, кайда баруымны сорады. Җавапны ишеткәч, канәгать төс белән кереп утырды. Кузгалып киттек.

— Кунакка кайтасызмы? — дип сүз башладым.

— Юк. Мене сезнең якка эшкә җибәрде-

ләр әле, — диде ул миңа, «шулай ук кунакка кайтучыга охшаганмыни?» дигәндәй, карап алып. — Тәкәрлек участок шифаханәсенә баш табиб итеп.

— Әллә сез Флүр Абдуллинмы?

— Әйе, — диде ул, миңа гаҗәпләнеп карап. Аннан көлеп куйды: — Фамилиямне кайдан беләсез? Маңгаема язылмагандыр ич?

— Мин бит сезне каршыларга дип килгән идем. Тик таба алмадым.

— Азрак көттем дә, түзмичә, юлга чыгарга булдым. Машиналар йөреп тора, дигәннәр иде. Тик, нигәдер, берсе дә утыртмый.

— Шофер халкы хәзер ут капкан кебек чаба. Вакыты шундыйрак. Урып-җыю бара — минуты кадерле.

Ул, килешкән төс белән, башын кагып куйды. Тәрәзәдән күз күреме җирдә җәйрәп яткан иген диңгезенә күз салды. Мин аңлатуны кирәк таптым:

— Ел яңгырлы килде быел. Урып-җыю кайчан башланды, ә яртысы һаман басуда әле.

Бераздан безне куе-кызыл төстәге «Москвич» узып китте, артыннан тузан болыты гына күтәрелеп калды.

— Күзен алган кигәвенмени! — дип куйды юлдашым.

— Яңарак кына сатып алды. Безнең авылныкы. Ферма мөдире, — дип ачыклык керттем.

— Яңа сатып алганга охшаган шул. Минем үземнең дә, машина алгач, аягым җиргә дә тими иде.

— Сезнең дә машинагыз бармыни?

— Бар иде. Хәзер юк. Мәзәктәгечә инде:

алдым, дип бер сөендем, исән калдым, дип икенче сөендем, саттым, дип өченче сөендем.

Мин аңа карап алдым. Юлдашымның йөзенә кара шәүлә йөгергән иде. Ярым җитди, ярым шаярып әйткән сүзләре мине азрак сәерсендерсә дә, сиздермәдем. Аның бу сүзләре артында аңа гына кагылышлы, гыйбрәтле вакыйга яшеренгән иде булса кирәк. Шулай да:

— Әллә һәлакәт-мазарга эләктегезме? — дип сорамый булдыра алмадым.

— Һәлакәтнең дә ниндие әле: кеше таптаттым...

Ул, нигә әйттем инде, дигәндәй, туктап калды. Аның газаплы уйлар төшкән йөзенә карап алып, мин дә тындым. Кешенең кайгысы бар икән, нигә аны, сорашып, яңадан кузгатырга. Андый вакыйга кеше күңеленнән мәңге китми, гомер буе эзәрлекләп йөртә. Күренеп тора, хатирәләр аңа авыр тәэсир итте. Элек тә аз кичермәгәндер, ахры. Үзем дә сизмичә, аның иң авыр күңел ярасына кагылдым бугай...

Машина, калкулыкларга бер күтәрелеп, бер төшеп, җилә генә. Юл читендә электр баганалары, кыр ышыклау өчен утыртылган агачлар торып кала. Алга яңалары шуышып чыга. «Выжт» итеп, каршыга килүче машиналар узып китә.

Бераз вакыт икебез дә сөйләшми генә, юлга текәлгән килеш, үз уйларыбызга чумып бардык.

— Кайтасы юл шактый, ахры, телисезме, мин сезгә башымнан кичкәннәрне сөйлим? — диде ул кинәт, авыр уйларыннан арынып. — Юл да кыскарак тоелыр.

— Авыр истәлекләрегезне кузгатмаса... — дидем мин үз чиратымда, әдәп сакларга тырышып.

— Кайчак шулай була бит: беренче күргән кешегә йөрәгеңдә ни бар, барысын да ачып саласың. Соңыннан үкенеп йөргән чаклар да була. Әнкәй мәрхүм кайчак: «Кешегә бигрәк ышанасың, эчеңдәге — тышыңда. Ә дөньяда адәмнәрнең яманы да, яхшысы да бар. Яман кешеләргә тарып, үзеңә начар булмасын, диюем. Башта эч-бавырыңа керерләр, ә соңыннан ачы итеп чагарлар»,—ди торган иде. Миңа яхшылык теләп әйткәндер инде ул. Ә мин һаман шул гадәтемне ташлый алмыйм. Дөрес, яманына караганда, кешеләрнең яхшысын күбрәк очраттым. Шуңадыр инде, — дип, елмаеп, миңа карап куйды. Азрак сүзсез барды да, дәвам итте: — Ә алар үзләре бик ачык кешеләр иде. Әти белән әнине әйтәм. Кешедән бер яшерен уйлары булмады. Үзләре кимәсәләр кимәделәр, туйганчы ашамасалар ашамадылар, ә мине кеше арасында ким-хур итеп йөртмәделәр. Ничек тә укытырга тырыштылар. Мәктәпне яхшы гына тәмамладым да, медицина институтына укырга кердем. Монда әткәйнең бик озак авырып ятуы да этәргеч ясагандыр. «Улым, табиблыкка укы, бәлки, мине дә терелтерсең», — ди торган иде еш кына. Тик мин икенче курста укыганда вафат булды. Ахры, шуннан язмыш мине ныклап сынарга уйлады. Озак та тормый, әнкәй фаҗигале һәлак булды. Автобусларны авып, аңа ут капкан, берничә кеше янып үлгән. Мин үз гомеремдә беренче тапкыр үксеп-үксеп еладым. Әйе, кеше үз башына төшсә генә аңлый икән. Нигә кайчакта бигрәк рә-

химсез бу тормыш? Соңыннан да әнием бик озак күз алдымнан китмәде. Төн урталарында сикереп торып, үкереп елаган вакытларым булды. Институтны ташларга да уйлап куйган чакларым булмады түгел. Яхшы кешеләр ярдәм итте, әткәй белән әнкәйнең васыятьләрен дә искә алдым. Моннан соң, көчемнән килгән кадәр, кешеләрнең газапларын җиңеләйтергә, кешеләргә бары тик яхшылык кына эшләргә ант иттем. Институтны тәмамлап алты ел эшләгәч, мине хирургия бүлеге мөдире итеп күтәрделәр. Буйдак кешегә күп кирәкме — өйләнергә нигәдер ашыкмадым инде — машина алдым. Ул вакытта абзаңны күрсәң, белмим, таныр идеңме икән! Түбәм күккә тиеп йөрим. Миннән бәхетле кеше юк! Бар кеше миңа карыйдыр, сокланып бармак төртеп күрсәтәдер шикелле. Азрак борын да күтәрелде кебек...

Мин, ул сөйләгәннәрнең нәкъ шулай икәненә һич шикләнми, тыңлап барам. Үземнең беренче тапкыр машина руле артына утырган көнемне хәтерләп, елмаеп куям.

— ...Шатлык томаны эчендә йөзәм. Тик бу бәхетем бары ике айга гына җитте. Бәхетсезлек мине урам чатында сагалап торган икән...

Ул туктап калды, авыр сулап тын торды. Үткәннәрен яңадан күз алдына китерде, ахры. Мин, юлдан күземне алмыйча, тизлекне алыштырдым. Машина, салмак кына гүелдәп, үргә күтәрелә башлады.

— Эштән кайтып бара идем, кинәт машинаның каршысына бер бала йөгереп килеп чыкты. Мин югалып калдым: машинаны читкә борырга да, тормозга басарга да өлгерә алмадым. Аның ата-анасының газапланууларын

күрү миңа, табиб кешегә, җиңел булган, дисезме? Авыр гынамы соң?! Иң явыз дошманыма да теләмәс идем үзем кичергәнне кичерергә. Билгеле, миңа суд булды. Тиешле җәзаны бирделәр. Аны тутырып чыккач, бер ел элекке урынымда эшләдем. Бәлки, гомеремнең азагына кадәр дә шунда эшләгән, яшәгән булыр идем. Бер очрашу мине үткәннәремә кире кайтарып, бөтен тормышымның астын өскә әйләндереп ташлады.

Беркөнне мине төн уртасында «Ашыгыч ярдәм» машинасы белән килеп алдылар. Ниндидер кыз баланы бик авыр хәлдә шифаханәгә китергәннәр. Ашыгыч рәвештә операция ясарга туры килде. Ул уңышлы үтте үтүен. Шулкадәр арыган идем, ял итәргә утыргач, ничек йоклап киткәнемне дә сизми калганмын.

Иртән авыруның хәлен белергә кергәч, кинәт электр тогы суккандай, урынымда катып калдым. Кыз янында мин баласын таптаткан хатын утыра иде. Йөзендә шат елмаю. Нарасые өчен бар куркуларны кичергән ана елмаюы иде ул. Күзләрендә бетмәс-төкәнмәс наз, ягымлы иркәләү чагыла. Мине күргәч, ул урыныннан кузгалды. Шатлык томаны аның күзләрен томалаган иде, башта танымады.

— Айгөлгә операция эшләгән хирург сезме? — дип сорады. Рәхмәт хисләрен белдерергә теләп соравы булгандыр. Тик шунда мине танып алды: куллары кире салынып төште, елмаюы юкка чыкты, йөзеннән кан качты. Ирексездән артка чигенеп, баласын сакларга теләгән кебек хәрәкәт ясады. Мин аңардан ким дулкынланмаган идем. Бер-беребезгә карашып, катып калдык. Миңа ияреп кергән шәф-

кать туташлары, берни аңламый, аптырашып, карашып алдылар.

Мин бу ананың хәлен аңлый идем. Мине күрү белән аның күз алдына икенче нарасые, минем аркада һәлак булган йөрәк парәсе килеп басты. Тик ул үзен кулга алырлык көч тапты. Аның:

— Рәхмәт сезгә. Чын күңелдән рәхмәт, — дип акрын гына әйткән сүзләре аяз көнне яшен суккан кебек тәэсир итте. Көтмәгән идем. Кайтарып берни әйтә алмадым. Бары тик, мине гафу итәргә үзендә көч тапкан ана йөрәге алдында башымны гына идем.

Ул көнне мин эштә ничек йөргәнмендер, ачык кына хәтерләмим. Фатирыма кайткач, бик озак уйланып утырдым. Бернәрсә ачык иде: миңа монда башкача бер генә көн дә калырга ярамый. Хезмәттәшләрем мине гаеплидер, аларга минем белән эшләү авырдыр кебек тоелды. Үземә дә, яшәү урынымны үзгәртсәм, ничектер җиңелрәк булыр төсле. Уйладым да — эшләдем дә.

Менә шулай килеп чыктым мин бу якларга. Үткән гомергә әйләнеп карыйм да, аптырап китәм. Кай арада гомернең яртысы узып та киткән! Ә нинди яхшылык эшләдем мин кешеләргә? Һәм алар эшләгән җинаятемне, саксызлык аркасында булсын, аклый аламы? Минемчә, юк. Ә үз тормышымны мин болай килеп чыгар, дип күз алдыма да китерми идем. Тормыш төрлечә сынап карый икән. Ярты гомереңнең үткәнен күреп, һаман үз урыныңны таба алмавыңны тою җиңел түгел. Шуның өчен көчеңнән килгәннең барысын да эшләп калырга ашыгырга кирәк. Кеше гомере нигә шулай кыска икән, дип уфтанам.

Шулай да, ярты гомер үтсә дә, киләчәккә өмет бар әле. Теләге булган кешегә әле күп нәрсәгә ирешергә була. Кешеләр сине яхшы исем белән телгә алсын өчен көне-төне үз-үзеңне аямый эшләргә дә эшләргә генә кирәк.

...Ул сөйләүдән күптән туктаса да, мин аңа кыеп сүз әйтә алмадым. Абдуллин да үз уйлары диңгезенә чумган иде. Йөзе уйчан, кашлары җыерылып-җыерылып китә. Минем аңа нәрсә дә булса әйтәсем, күңелен күтәрәсем килсә дә, эндәшмәүне хуп күрдем. Сүзләр урынсыз иде монда. Кичерәсен кичергән, уйланасын уйлангандыр. Шулай да бөгелеп төшмәгән, язмыш ничек кенә сынаса да, өметсезлеккә бирелмәгән. Тормыш бит ул. Шушы сикәлтәле юл белән бер.

Калкулыкка күтәрелгәч, безнең авылның искиткеч матур күренеше ачылды. Яңа баш табибның да йөзе яктырды.

— Матур икән сезнең яклар! — диде ул, миңа борылып.

— Искиткеч! Менә күрерсез, табигате генә түгел, кешеләре дә әйбәт. Безнең як чишмәләренең суын эчкән кеше аларның тәмен тиз генә оныта алмый.

Флүр Абдуллин елмайды. Аның авыр уйлары артка чигенде, ахры. Тирә-якка елмаеп карап бара башлады. Бу вакытта ул тормыш юлына яңа аяк баскан кешегә охшаган иде.

Безнең машина, җилдереп, авыл очына килеп керде.

...Бу көннән соң шактый вакыт узды инде. Флүр Абдуллин безнең якларда күптән үз кешегә әверелде. Тәкърлеккә эшкә җибәрелгән бер табиб кызга өйләнде. Ике бала үстерәләр. Тату яшиләр. Якын кешеләр булып ки-

тә алмасак та, исәнләшеп йөрибез. Ул бәян иткән тарихны мин берсенә дә сөйләмәдем. Кирәк тапмадым. Башкалар авызыннан да ишеткәнем булмады. Без капчыкта ятмый, диләр диюен. Аның тормышын белгән кешеләр дә булмый калмагандыр. Тик ул урамга чыкмады. Шулай яхшырак та булгандыр. Тормыш бит ул, төрле хәлләр була, барысын да чыгарып чәчәргә дигәнмени?

«Менә бит, сөйләү генә түгел, хәтта язып та чыккансың», — диярсез. Ә мин героемның да, авылның да исемен үзгәрттем. Хәер, эш авыл белән исемдәмени...



## КАЕРЫЛГАН КАНАТЛАР

Гафият барып кергәндә вокзал, һәрвакыттагыча, үз тормышы белән яши иде. Пыяла дивар буена тезеп куелган каты урындыкларда автобус көтүчеләр кысылышып утырган, урын җитмәгәннәре төркем-төркем булып, җыелышып сөйләшеп тора, ары-бире йөрүчеләр, керүчеләр, чыгучылар да җитәрлек. Вокзал умарта күче кебек гөжли. Кассалар янында су буе чират тезелгән. Күрше шәһәргә билет алырга торучылар тәртип белән баскан, ә якын-тирә авылларга кайтучылар, җылыга җыелган тараканнар кебек, касса тәрәзәсе янын сырып алган. Этеш-төртеш, тавыш-гауга. Гафият туган авылына еш кайтып йөрсә

дә, вокзал аша сирәк китә. Нигә дисәң, һәрчак кеше күп, ызгыш-талаш, ыгы-зыгы, билетлар, хәтта урынсызлары да, сатылып беткән була. Бик иртә чыгып, чират алсаң гына инде. Ә Гафиятнең алай бушка вакыт уздырасы килми, иң отышлысы — юлга чыгып «тавыш бирү». Хәзер юл яхшы — асфальт, машиналар өзлексез чаба, яисә шул ук «билет сатылып беткән» автобус шоферы туктап, утыртып алып китә. Акча эшлиләр — билет биреп тормыйлар, хәер, аны сораучы да юк, ул яктан халык тавыш кубаруны кирәк тапмый. Юл йөрүчегә акчасын шоферга бирде ни дә, вокзал кассасына түләде ни — барыбер. Артыгын таләп итмиләр бит, ә аңа теләгән җиренә мәшәкатьсез барып төшсә — шул җиткән. Ашыкканнар шәхси машина хуҗаларына биш, хәтта ун тапкыр арттырып түләп утырып китәләр. Гафиятнең дә шәхси транспортта яисә дәүләт таксиенда шулай йөргәне бар. Хәзер халыкта акча күп, чүп урынына диярлек: «акча бездә бер букча!» Дәүләт ала белми икән — үзенә үпкәләсен. Ни өченме? Соң, шул Сәхип авылына зуррак автобус бирергә булмыймыни? Акча да шофер кесәсенә түгел, ә дәүләт кесәсенә керер иде. Тик юк инде, белмибез, юк, белмибез хуҗалык итәргә... Тоташ илне сүтеп корабыз, ә кеше турында кайгырта белмибез. Халык мондый очракта, җитәкчеләр үзләре автобуста йөрми, ә кеше кайгысы — төштән соң, дип, белеп әйтә.

Өерелешеп басып торган халык арасына кысылып, урын тапкач, Гафиятне әнә шундый күңелсез уйлар биләп алды. Кешеләрне күздән кичерде. Күбесе — авыл халкы. Төрле йомыш, яисә кирәк-ярак артыннан район үзә-

генә килгәннәр, чөнки авыл кибетләрендә җил уйный. Гафият еш игътибар итә: авыл кешесе нигәдер һәрчак шулай тынгысыз холыклы, нәрсәне дә булса эшләп өлгерә алмам, дип куркып, каударланып, чәбәләнеп яши. Аеруча хатын-кыз. Өлкәнрәк яшьтәгеләре бигрәк түземсез. Үзе этешә-төртешә тора, шул арада барлык гаилә тормышын, район үзәгенә нинди йомыш белән килүен сөйләп алырга да өлгерә. Берничә минут үтүгә аның кем икәнен, балаларының ничәү, кайда яшәгән-эшләгәнен белеп бетерәсең. Азрак күзенә туры карасаң, синең үзеңә дә сорау арты сорау яудыра башлый. Кая кайтасың, кем баласы, әти-әниең исәнме, авылыгыздагы фәлән-фәлән кеше нәрсә эшли, сау-сәламәтме — китә тезеп. Гафият андый авыл апаларын күп күргән, эше буенча да алар белән еш аралаша, гадәтләрен белә. Шуңа сорауларына иренми генә җавап бирә. Нигә рәнҗетергә? Болай да алар өлешенә авыл тормышы дигән көмеш ярыйсы төшкән, иртә картайткан. Үзенең әнисе белән дәү әнисен генә алганда да... Әнә, алар дип шулай атна саен авылга кайтып йөри бит инде ул.

Билет сатучы кыз да нигедер һаман күренми. Автобус китәргә вакыт бар шул әле. Иркенләп торып сөйләшеп, чәй эчеп утыралар булыр. Аларга нәрсә, китәселәре, йә кайтасылары юк, план үтәлми, дип борчыласылары да юк — алар өчен халык хәтта кирәгеннән артык күп йөри.

Халыкны ерып, кассалар ягына үтәргә тырышкан күрше егетен күреп калды Гафият. Фәнит район үзәгеннән ерак түгел урнашкан училищеда укый, шулай ук атна саен кайтып-

китеп йөри. Гафият абыйсын күрүгә, елмаеп килеп житте.

— Гафият абый, син алдарак басып торасың, мә, миңа да ал әле, — дип Фәнит акча сузды. — Син арысаң, бераздан мин басармын. Хәзергә кибетләрне урап килим әле.

Гафият, ярар, дип, ризалыгын белдереп, баш какты. Фәнитнең артыннан карап калды. Аның да тормышы ал да гөл түгел. Әтисеннән иртә калды. Аннан әнисе бер ирне йортка кертте. Тагын дүрт балалары булды. Тик үги әтисе эчә иде. Гәүһәр үзе дә тормышта чарланган хатын, шау-шу чыгарырга маһир. Ә бит ире шундый эшчән, белмәгән һөнәре юк. Эшләгәндә эшли, тик эчсә генә бозылышып китәләр. Гәүһәрне авыл буйлап куалап йөртергә дә күп сорамый. Шулай яшәделәр-яшәделәр дә, Гәүһәр ире өстеннән берничә тапкыр авыл советына барып, утыртам дип яный башлагач, тегесе ташлап чыкты да китте. Ул тумышыннан зимагур иде, болай йөрүе бер бүген генә түгел, читтә тагын ике хатыны, балалары бар, дип сөйлиләр. Чыгып китте дә, юк булды. Әле дә милиция эзли бугай. Ә ул шома кеше, берәр тыныч урында тагын шулай яшәп ятадыр әле.

Дөнья әнә шулай кызык инде ул. «Син үзең дә...» — дип уйлап куйды Гафият. Аны да тормыш аз якаламады. Дөрес, үзенең гаебе дә юк кебек инде. Авылдашлары да аның гаиләхәлен, барысын да әнәсеннән җебенә кадәр белгәнгә, гаепләмиләр кебек. Киресенчә, җәллиләр. «Их, балам, синең дә бәхетең булмады инде, берүзеңә бигрәк авыр», — дип, очрашып-сөйләшкән һәр авыл карчыгы кызганып кала. Авыл кешесе шундый киң күңел-

ле инде ул. Үзен кызганырга кирәк әле аның, сау-сәламәт Гафиятне түгел.

Гафият тә этисез үсте.

Хәзер ул моның өчен берсенә дә кенә тотып йөрми. Дөрес, этисен дә, әнисен дә аратирә гаепләп алган чаклары булды. Анысы — бәләкәй чагында.

Гафиятләр ягы — урманлы як. Элек алар авылы янында урман аеруча бай булган, тирә-як колхозлардан килеп, агач хәзерләп ятканнар. Урманчыларның берсе әнисенә күз төшергән. Соңрак өйләнешкәннәр. Тик үги каенанасы яшьләрне сыйдырмаган, киленен, нигәдер, үз итеп китә алмаган. Ә килен күңеле — пыяла, саксыз кагылсаң — уала, диләр бит. Өч айлык улын алган да, әниләренә кайтып киткән. Йомшак холыклы этисе яклап бер сүз әйтә алмаган. Ә аерым йортка чыгарга — ул вакытта кая аның акчасы, агачы. Хезмәт көне белән ерак китеп булмый шул. Дөрес, бераздан үзе күчеп килеп, хатыны авылында яшәп караган. Тик Гафиятнең дәү этисе Солтангәрәй тагын алып кайтып киткән. Солтангәрәй картны соңыннан бик үкенгән, диделәр. Һи, эш узгач, үкенгән ни дә, үкенмәгән ни. Этисе өйләнгән, тик балалары булмаган. Әнә шулай япа-ялгызы үсте Гафият. «Нигә минем эти юк?» — дип үксеп елаган чаклары да була иде. Ә яклардай кеше кирәк булган вакытлары күп була ул этисез баланың. Шулай да аңа үч тотып үсмәде. Вакыты булганда яисә юл төшкәндә әле дә баргалап тора. Улы бит, әйдә, күңеле буладыр. Кеше алдында: «Улым килгән», — дию генә үзе ни тора. Яше дә олы инде, бар юанычы шул Гафиятләр, бәлки. Ә Гафият этисен ят та

итми, артык якын да күрми, эти тәк эти инде. Моңа аерым яшәү сәбәпчедерме, әллә башка нәрсәме, ул тәгаен генә әйтә алмый. Бу дөньяда Гафият, Ходайдан кала, бары тик әнисенә генә бурычлы. Әнисе фермада эшләгәндә салкын алдырган, инде озак еллар өметсез авырый. Дәү әнисе бар, анысы тома сукыр. Шулай да бер-берсенә күз-колак. Әнисе ике култык таягына таянып йөрсә дә, хәзергә күзләре бераз күрә, ә икенчесенең аяклары калтырап торса да, йөри. Ул да шулай ук гомер буе колхозда эшләгән, ә хәзер белүче дә юк. «Улыгыз бар, әнә, ул карасын», — диләр. Карый Гафият. Бүгеннән үз янына алыр иде. Тик торак шартлары... Ике кечкенә баласы, хатыны һәм үзе сыерчык оясыдай фатирга сыенып, булганына шөкер итеп, яшәп яткан көннәре.

Дөресен генә әйткәндә, аны болай ике арада сугылып йөрү ярыйсы гына җиләтте инде. Яхшылап өйдә дә була алмый, әнисен дә нык-лап тәрбияли алмый. Ярый, ниһаять, бу хатыныннан уңды. Гафият аңа сокланып бетә алмый. Ә Зәлифәсе гаепләргә теләсә, сәбәбе җитәрлек. Хатын алып яшәп карады, аңарда баласы бар. Димәк, шактый акча тотыла, дигән сүз. Юк, бер авыр сүз әйткәне булмады, гаепләп ник бер кырын карасын. Тфү-тфү, күз тимәсен. Ярата Гафиятне — бар сере шул. Дөрес, Гафият әйбәт кеше булса да (эчеп-тузып йөргәне юк), әллә ни өйдә булыша алмый, башка көннәрдә дә эштән арып, нервылары менә өзеләм, менә өзеләм, дип кайта, йә ялкаулык җиңә — күп авырлык хатынына төшә. Балалар белән ул көне буе өйдә. Ә ике яшь баланы каравы, тәрбияләве, эшкә йөрүе

җиңелме-түгелме, башына төшкән кеше үзе генә белә торгандыр...

— ...Гафият абый... — дип кыюсыз гына эндәшүгә борылып караса, кем әле, э-э... Әлфрит басып тора. Әлфрит — беренче хатынының энекәше, ягъни Гафиятнең каенише. Әле мәктәптә, югары сыйныфта укый. Аны тиз генә танымады да. Үскән. Вакыт күп үткән шул инде. Унике ел. Әле ул чакта мәктәп яшенә дә җитмәгән иде.

— ...Билет ал әле, — дип әйтте каенише. Гафият аның тәүге сүзләрен аңламый калды.

— Бер кешегә ала идем бит әле... Ярар, күпләп бирсә, алырмын...

Әлфрит аның яныннан китеп, ниндидер малайлар янына барып басты, нәрсәдер әйтте дә, Гафияткә борылып карады.

Уйлары чуалып китте Гафиятнең. Гомер үтә икән бит. Улына да унбер яшь тулды хәзер. Ә нәрсә эшләп болай килеп чыкты соң әле аның тормышы?

Сафия белән алар бер мәктәптә укыды. Уку елларында аның бар икәнен дә белми иде. Ә мәктәпне тәмамлап берничә ел үткәч булган очрашу барсын да хәл итте. Бер күрүдә гашыйк булды дию — анысы хилафлык инде. Гафият машинада эшли башлаган чак. Урып-җыю бара. Яшь-җилкенчәк ындыр табагында төнгелектә ашлык чистарта. Сөйләшеп йөри торгач, еш очраша башладылар. Иртән таңны бергә аттырган чаклары да була иде. Ә аннан ул аңа колагыннан гашыйк булды. Кызык бит ул мәхәббәт! Шуннан китте инде. Алты чакрым ераклыктагы күрше авыл аның өчен туган авылы кебек якын төбәккә әверелде. Баш чайкарлык хәл бит — җиде ай

буе шунда көн дә кич барып кайта иде. Үзе дә сизми калды — өйләнешеп тә куйдылар. Тик ул, мәхәббәтенә исереп, бернәрсә дә күрмәгән икән. Элек күп егетләр белән йөргән, диләр иде; дөрес булып чыкты. Сафия барысын да инкарь итте. Юк, аңардан мәхәббәте сүрелмәде. Тик шунысы — энисе һәм дәү энисе янында яшәргә теләмәде. Ике авыру кешене тәрбияләве, ай-һай, авыр шул — түземлелек, сабырлык кирәк. Олы йөрәк, киң күңел кирәк. Менә нәрсә җитми иде яшь киленгә. Ара-тирә Сафия:

— Әйдә, безнең авылга китик, яхшы яшәрбез, — дип сүз чыгара башлады. Гафият моңа артык әһәмият бирмәде, сүз ара сүз чыгып әйтелгән теләк дип кенә кабул итте. Аның мәңге энисен ташламаячагын белә бит инде Сафия, ул хакта аз сөйләшелмәгән. Юк, үзенекен итте хатыны. Дөрес, игътибар да җитеп бетмәгәндер аңа. Назланырга ярата иде, наз да җитмәгәндер. Авыл тормышын кем белә — шул аңлыйдыр.

Беркөнне эштән кайтуына Сафия юк иде— ташлап киткән.

Юк, артыннан бармады Гафият. Утлы кургаш кебек әрнүен йотты, бөгәрләнде, өзгәләнде — барыбер бармады. Горурлыгын җиңә алмады, дип әйтә алмый. Аның тормыш таләбе шундый иде — иреңне яраткансың икән, эти-энисен дә яратырга кирәктер. Үзе кайда килен булып төшкәнен белә торып чыкты бит кияүгә. Ахры, исәпләре башта ук шундый булгандыр. Иң беренче чиратта үзен кайгырту ягын карый иде. Соңрак ачыклануынча, Гафиятне дә яратмаган ул. Алучы булганда чыгып калыйм, дигәндер. Чөнки ничә егет бе-

лән йөреп, берсе дә андый тәкъдим ясамаган. Нигә ясасыннар, билгеле... Ә Гафиятнең күзе томаланган иде: мин яратам — шул җитмәгәнме, дип уйлады. Һәм ялгышты. Мәхәббәт ике яклы булырга тиеш, ә берең ярата, икенчең — яратырга рөхсәт итә түгел...

Гафият әти булачагын белде. Сафия янына сөйләшергә барды. Тик тегесенең кире килергә исәбе юк иде. Шулай, бәлки, үз дигәнемә ирешермен, дип уйлагандыр. Тик Гафият үзенең уллык бурычына хыянәт итә алмады. Аны үстерәм дип бүген әнә шулай утыра бит әнисе. Авыру килеш, кеше баласыннан ким булмасын дип тырышкан, укыткан. Үзе бер рәхәт күрмәсә дә, аңа булсын, дигән. Бар тормышын улына багышлап, башка кияүгә дә чыкмаган.

Шулай да, улы тугач барды, ризалатып, кире алып кайтты. Тик Сафиянең монда да үз исәбе булган икән. Янәсе, хәзер, улы да тугач, аңа иярми калмас. Аннан Гафиятне улының әтисе икәнен исбат итү дә җиңел булачак... Тик Гафият андый кеше түгел, үз улыннан баш тартуга бармаячак. Әнә ничек аның үзенә охшап тора...

Тик Сафия белән барыбер тормыш кора алмадылар. Бер сәбәпсез, әбисе килеп, кызы белән оныгын алып кайтып китте. Сафия белән Гафият арасында шундыйрак сөйләшү булды.

— Кайтып китәсеңмени инде?

— Кайтам шул.

— Нигә алай булгач кияүгә чыктың соң? Әллә... яратмыйсыңмы?

— Яратмыйм.

Шунда гына Гафиятнең аңына барып

житте. Сафиянең чибәр йөзен, тик ят күзләрен күрде. Яратмый... Ә яратмагач, нинди гаилә, нинди бәхет?!

— Ярар алайса, бар, — диде дә, башка сүз әйтмәде. Бүгеннән Сафия аның өчен юк иде. Ничек итеп улын юрганга төргәннәрен карап торды. Яз иде. Авыл очына кадәр озатып куйды. Киттеләр. Сафия артына борылып карамады. Төшке аш вакыты үткән иде инде. Гафият туры эшенә юнәлде. Нәрсә булганын да аңламый иде әле ул. Тик хыял сарайлары акрын гына җимерелә барганын тойды... Ун көн өметләнде әле. Ике күзе күрше авыл юлында булды. Ә аннан, көл астындагы куз сыман, соңгы өметләре дә сүнде.

Дөрес, баргалап, хәл белгәләп йөрде. Тик инде ике кисәк бергә ябышмады. Салкын иде аралар, улы да бозны эретә алмады. Мин этисез үстем бит, ул да үсәр, дип уйлады. Билгеле, баланың бер гаебе дә юк, монда бары өлкәннәр гаепле. Тик Гафият хәзер бернәрсәне дә үзгәртә алмаячак... Шул көчсезлеге чыгырыннан чыгара да инде...

Сафия соңыннан кияүгә чыкмады. Гаиләле бер ир белән чуала, диделәр, дөрес булып чыкты. Менә күптән түгел бала тудырганын әйттеләр. Гафият аны һич гаепләми, моңа сөенә генә, чөнки улына иптәш булачак. Үзе дә япа-ялгыз үсте, ялгызлыкның ничек авыр икәнен яхшы белә. Булсын иде сеңлесеме, абыйсымы, энесеме — тормышы һич болай булмас, әнисен тәрбияләү дә җиңелрәк булыр иде. Тик хәзер кемне гаеплисең? Тормыш шулай инде ул — китапларда язганча, барсы да шома гына бармый. Хәзер китап укымыйлар, диләр. Нигә укысыннар — тормышчан түгел, ә

тормыш бит бөтенләй башка. Вәт тормышны сурәтләсәләр, чын тормышны — укырлар иде. Ә әкиятне алар инде балачактан ук укып туйган, аннан, әкият укырга яшьләре дә узган. Тормыш үзе юклы-барлы әсәрләрдән мең тапкыр мавыктыргычрак, кызыклырак, кызганычрак, авыррак... Кыскасы, көлкесе дә, күз яше дә җитәрлек. Һич югы, Гафият гомеренә...

...Этешә-төртешә билет алгач, Гафият Әлфритне эзләп тапты. Автобус китәргә вакыт бар иде әле. Шуңа тиз генә фатирына кайтып әйберләрен алып килергә кирәк — ул аларны әллә билет була, әллә юк, дип, күтәренеп йөрмәс өчен, алып тормаган иде.

— Менә, Әлфрит, билет, тиз генә акчасын бирегез дә... Ашыгам...

— Менә аңа иде ул, — дип, анысы бер бишенче-алтынчы сыйныфлар тирәсендә укыган малайга төртеп күрсәтте.

Тегесе, гаепле кеше сыман югалып калып, ирексездән кесәсен капшап карады. Андый хәрәкәтне акчасы булмаган кеше генә ясый. Әлфрит, аңлап калып, Гафияткә акча сузды.

Гафият урап килгәндә автобус китәргә тагын бер ун минутлап вакыт бар иде әле. Вокзал һаман үз тормышы белән кайный. Мичкә тәгәрәткән тавыш белән диспетчер автобус китүен хәбәр итә. Кемдер китә, кемдер килә, кемдер аерыла, кемдер кавыша. Кешеләр төрле якка таралыша. Бер уйлаганда, вокзал — тормышның нәкъ кечкенә үрнәге. Кешеләр азга гына очраша да, тагын аерыла. Тормыш та шулай... Очрашасың — табасың — югалтасың — онытасың...

Гафият күзе белән теге малайларны эзләде. Тик алар күренмәде. Менә, кызык бит

ул — уйламаганда очраштылар да, үткәнен хәтеренә төшерделәр. Гафиятнең күңелен нидер тырный иде, җанын тынычсызлык борчый иде. Кызык, ничек булды соң әле бу? Ашыгып йөреп, нәрсәне күздән ычкындырды ул? Тик тегеләр күренмәде. Аның күңелен бер уй борчый, шуңа үз күзләре белән күреп, ышанасы килә иде. Автобуска утыра башлау турында игълан ителде, Фәнит тә килеп җитте, тик тегеләр булмады. Әллә соңга калдылар, әллә башка сәбәп тоткарлады.

Автобуста кайтканда да Гафият тынычлана алмады. Нәрсәне күз уңыннан ычкындырды? Нәрсә борчый күңелен? Вокзалдагы хәлләрне яңадан хәтереннән кичерде. Уйлары бишенче-алтынчы сыйныфлар тирәсендә укыган малайга җиткәч, кинәт аны кайдадыр күргән кебек булды. Тик кайда? Йөзе таныш сыман... Кайда күрде аны? Һәм... кинәт Гафиятне яшен суккандай булды... Шул ук йөз, шул ук каш-күзләр, авыз-борын... Соң, бу бит аның үзенең бишенче-алтынчы сыйныфта укыганда төшкән фотосурәтенең төгәл күчермәсе!.. Аның улы!.. Йә, Хода! Менә сиңа очрашу-у-у... Шулай да була икән дөньяда! Гафият малайның үзен гаепле сизгән сыман, югалып калуын, ничек кесәләрен капшавын, кино тасмасын кирегә әйләндергәндәй, күз алдыннан үткәрде. Улы! Гафиятнең шиге калмады. Аның күңелен оялу катыш гарьләнү, гаҗизлек биләде. Нигә язмыш шулкадәр рәхимсез? Үзе этисез үсүе җитмәгән, инде менә хәзер улы?.. Әллә бу ниндидер югары көч әмере белән эшләнәме? Кешенең язмышы маңгаена язылган, ди бит. Син күпме генә тырышма, аны үзгәртә алмыйсың... Яки бу үзенә күрә бер сынаумы? Сы-

нау икән, аны ирләрчә үтә дә белергә кирәк. Ирләрчә... Ә ничек була соң ул — ирләрчә? Еламый-сыкрамыймы, әллә берни булмагандай, яши бирүме? Булганы — булыр, язганы шулдыр, дип?.. Сорау арты сорау, тик җаваплары гына юк. Һәм аларны гомер буе, кабергә кергәнче эзләргә дә эзләргә...

...Ә Билал, автобуска билеты булса да, аның белән кайтмады. Әнисе янына килеп йөргән абый, сеңлесе Гөлчирәнең әтисе була инде, танышлар юкмы, дип, кайтышлый вокзалга сугылган булып чыкты. Әлфрит абыйсы утыртып җибәрде.

Машина кабинасында сикерә-сикерә кайтканда Билал «үги абыйсы»на карап-карап алып, вокзалда очраткан әтисен уйлады. Таный ул аны. Танымаса, Әлфрит әйтер иде. Тәүдә күрмәгән иде, әле дә абыйсы күрсәтте. Тик:

— Исәнме, әти! — дип әйтергә кыюлыгы җитмәде. Әллә әйтәсе дә килмәдеме? Юк, янына килүен, берәр сүз әйтүен көтте. Ә ул танымады микән, ашыгып китеп барды. Элек, ул бәләкәй чакларда, еш кына хәл белергә килеп чыга иде. Аннан әнисе, әтиең өйләнгән инде, диде. Усал итеп тагын нәрсәдер әйткән иде, сабыйның хәтерендә калмаган. Дөрес, әле дә әйткәләп тора ул. Шуңа күңеленә «барысына да әтисе гаепле», дигән уй сеңеп бара. Соңгы вакытларда әтисенең килгәне дә юк. Ә килүен тели малай. Тик әнисе бит... «Очратсаң да, эндәшмә, безгә кирәкми ул», — дип тылкып кына тора. Бу өлкәннәрне аңламассың...

Билалны «үги абыйсы» юл чатында төшереп калдырды, ике чакрым гына калды, инде

җәяү дә кайтып җитәрсең, диде. Малай, олы юлдан читкә чыгып, чирәмнән атлады. Кечкенә аланлыкта туктап, җиләк ашап алды. Өйгә дә кайтасы килми нигәдер. Билал агач төбенә, күләгәгә утырды, аннан чалкан төшеп ятты, күккә карады. Күләгә төшкәнлектән, җиләс, үзе бер рәхәтлек хисе тоясың. Чикерткәләр чырылдый... Әллә елыймы? Яңадан әтисе, әнисе исенә төште. Нигә аның әтисе читтә яши? Кем генә булмасын, аңа әти, әни кирәк. Бергә яшәсеннәр!.. Тик юк, мөмкин түгел шул инде. Бары чынга ашмас хыял... Юллар аерылган, канатлар каерылган... Малайның тамак төбенә төер утырды, күзләренә яшь тулды. Егет булырга, күпме генә елап җибәрмәскә тырышмасын, күзләреннән яшь атылып чыкты, ул үксеп-үксеп елап җибәрде.

...Бу вакытта олы юлдан маршрут автобусы үтеп китте. Анда Гафият үз уйларына чумып, туган авылына кайтып бара иде. Кайчандыр якын булган авыл яныннан узганда, ул тәрәзә аша күз салды. Авыл уч төбендәгедәй җәйрәп ята. Анда аның улы яши... Йөрәген нидер чеметеп алды, хатирәләр яңарды... Тамак төбенә төер утырды.

...Ә бу вакытта кечкенә аландагы агач төбендә бер малай, тәгәри-тәгәри, тыела алмый, үксеп-үксеп елый иде...



## УЧАК ЯКТЫСЫ

Авылыбыз ямьле урынга утырган безнең. Читтән кунакка кайткан кешеләр: «Их, табигате лә табигате! Ял йортында яшәгәндәй яшисез бит!» — — дип, соклануларыннан телсез калалар. Билгеле, алар азга кайта, тиз китә дигәндәй, авыл тормышының мәшәкате күзләренә чалынмый.

Авылыбыз табигатен тагын да күркәмрәк итүче бер үзенчәлекле табигать почмагы бар бездә. Аның хакында әйтми үтсәң, авылыбызның яме икеләтә ким булыр төсле. Ул — безнең авыл уртасындагы каенлык. Артык зур да түгел үзе. Гел бөдрә каен агачлары гына үскәнгә халык аны «каенлык» дип атап йөртә дә инде. Дәү әнием сөйләгән иде: сугыш вакытында, каеннарын кисеп, анда ындыр табагы төзегәннәр, җыен хатын-кыз, карт-коры шунда фронт өчен барабанлы локомотив белән ашлык суккан. Шуннан туп-туры, олау белән, игенне тимер юл станциясенә озата торган булганнар. Әйе, күпне күргән каенлык ул безнең. Авылдашларымның туганнан алып кабергә кергәнче булган тормышына шаһит ул.

Хәзер дә тынып тормый каенлык. Җәй көннәрендә авылның барлык яшьләре җыелышып чыгалар да, каенлыкның әнә шул болын сыман урынында кемнеңдер күптән яткан бүрәнәләренә тезелешеп утырып, учак ягып җибәрәләр. Моннан ун-унбиш еллар элек клубны сүтеп алганнан соң, яшьләр кая барып сугылырга белми йөргәндә кемнеңдер башына килгән очраклы уй ул. Шуннан башлап килә бу гадәт. Кайсыбер көннәрне, гармун

алып чыгып, җырлашып утырабыз, күп тапталганлыктан кара җиргә әверелгән учак тирәсенең тузанын туздырып, биеп тә алабыз. Яшьлек — яшьлек инде, үзенекен итә. Учактан ерак та китми, ак каеннар арасында тәүге кайнар сөю сүзләре дә әйтелә. Кайнар иреннәрнең бер-берсенә кушылуына да шаһит каеннар... Учак тирәсендә җыелышып, берберебезгә сыенышып шулай утырулар мәңгегә хәтердә кала, читтә йөргән авыл яшьләренең дә, кайткач, тәүге сораулары шушы учак турында була. Янамы ул, сүндермәдегезме безнең авыл учагын, янәсе. Яна ул, яна безнең учак, ни эшләп сүндерик ди без аны. Фәһим әйткәндәй, — теленә шайтан төкергән, шаянлык, шуклык өләшкәндә алдан йөгергән (ә без уйнап калганбыз) егетебез бар безнең, — бердәнбер мәдәният учагы булган учагыбыз бит ул.

Әнә шулай гади генә ага тора яшьлегебез. Көндезләрен — эштә, ә кичләрен—учак янында. Көзле-кышлы гына эшләребез яман. Кышның салкын бураннарында өйдә телевизор янында экрандагы кешеләр ике булып күренә башлаганчы утырасың да, аннан ятып йоклыйсың. Җыелышырга клуб юк. Урамга чыксаң да, күпме йөрисең инде. Клуб хакында колхоз җыелышларында да әйтеп карадылар. Бу хакта район, хәтта өлкә гәзитенә дә язып чыктылар. Гәзитләрдә язганча, «мәдәният учагы» кабынмады. Колхоз җитәкчеләренең үз сүзләре сүз. Янәсе, авылыгыз перспективалы түгел, кырыклап кына калган өйле авыл өчен клуб төзи алмыйбыз, тиздән барыбер күчәчәксез. Тик хәзергә авыл халкының күчеп китәргә теләге бик сизелми. Ата-бабаларыбыз

җирен, туган-үскән якны, шундый гүзәл табигатьле авылны ташлап китәргә нинди юләре риза булсын. Бәлки, киресенчә, нәкъ менә шушындый бәләкәй төбәкләрне ныгытырга, зурайтырга кирәктер әле. Билгеле, бу хакта бәхәсләр булмый калмый. Шулай шаулашып алалар да, тыналар. Ара-тирә, олылар үзара җыелышып сөйләшкәндә генә чыкса чыгып кала бу хакта сүз. «Колхозга икенче рәис килми торып, булмас бу эш. Үче бардыр аның безнең авылга», — дип тәмамлана өлкәннәрнең әңгәмәсе. Берәр нәрсә беләләр булырлар...

Менә бүген дә җыелышып чыктык та, балкып янган учак тирәли кайсыбыз чүгәләп, кайсыбыз бүрәнәләр өстенә тезелешеп утырып, Фәһимнең чираттагы мәзәген тыңлыйбыз. Кайдан Хуҗа Насретдин турында мәзәкләр китабын кулына төшергән диген син аны, әнә, хәзер шуннан укыганнарын сиптерә генә, чукынчык. Ә мәзәк сөйләргә дигәндә, аңа гына әйт — шундый килештереп сөйли: үзе һич көлмәс, әйтерсең, әллә нинди, дөнья масштабындагы җитди хәл турында сүз алып бара. Менә бит нинди артист әрәм булып ята — хәзер аны, тот та, авыл сәхнәсенә чыгар иде дә ни... Их!

Кинәт Фәһим мәзәгенең иң кызык урынында туктап калды да:

— Идея бар, егетләр...—Һәм кызларга күз төшереп алганнан соң гына: — ...Гафу үтенәм, оныта язганмын, һәм кызлар, — дип уенчалатып әйтеп куйды.

— Нинди идея ул?

— Башта сөйләп бетер инде. Синең шул булыр, иң кызык урынында туктап каласың

да... — дип шаулашып алды учак тирәсендәгеләр.

— Анысы шулай... — дип җитди генә дәвам итте сүзен Фәһим. — Ә сез беләсезме вакытында туктый белүнең дә файдасы зур икәнен? «Мең дә бер кичә» дигән китапны һәрберегез кимендә ун тапкыр укып чыккандыр. Вакытында туктый белү Шәһризадәгә гомерен саклап калган, һәм үзенекен генә дә түгел, уннарча, йөзләрчә менә сезнең кебек гүзәл, матур, бер кашык су белән йотарлык сылу кызларның гомерен дә...

— Буасы ерылды Фәһимнең. Инде тиз генә туктатырмын, димә, — дип куйды Фәридә.

Фәһим аны, әйтерсең, ишетмәде дә, сүзен ялгап алып китте:

— Идея менә шундый, егетләр-кызлар. Нигә әле клуб юк, кино юк, дип аптырап ятабыз соң әле? Әйдәгез, бүгеннән акча җыябыз да, кинокамера сатып алабыз. Күрсәтер урын юк, дип аптырап торасы түгел — ике каенга ак пәрдә эләбез дә, вәссәлам, экран әзер. Кино күрсәтергә, төшерергә өйрәнү авыр эш түгел, ышанып тапшырыгыз гына, үзем сәгате-минуты белән сезне бу хәлдән коткарырмын. Үз клубларында кино карап, масаеп яткан күрше авыл яшьләренең күзләре дүрт булсын әле. «Мәдәният учагы»быз үзенә бер, кино күрсәтү дә беркайда кабатланмаганча булачак...

— Уһу-у, баш бар да инде үзеңдә, Фәһим...

— Нәрсә эшләп монда әрәм булып ятасың, әйдә, үземә ярдәмче итеп алам мин сине, — диде комбайнчы ярдәмчесе булып эшләүче Фәнгать. Фәһим сүзләреннән соң тына төшкән

көлү тавышлары аның мәзәгеннән соң яңадан учак телләрен куркытып, каеннарны сискәндереп, йокыларыннан уятты.

Шулчак безнең янга җиңел машина килеп туктады. Күрше-тирә авыллардан яшьләр гел килеп йөргәнгә, аңа әллә ни игътибар итүче булмады. Билгеле, кайсыбер кызларның йөрәге «дөп» итеп калгандыр инде — анысын кем белә. Безнең егетләрнең бик яхшы ягы бар: кайсыбер авыллардагы кебек, килгән кунак егетләренә бәйләнү гадәте юк. «Килсеннәр, йөрсеннәр, безнең авылның күңеле киң»,—дип кенә куялар. «Кызларыбыз эштә уңган, төскә чибәр — карата алсалар, каратсыннар», — дип тә җиффәрәләр. Һич арттырып әйтә бу, димәгез, кызларыбыз алтын кебек, йөрәкләре ялкын кебек. Төгәл генә әйтә алмыйм, ничә күрше авыл егете безнең кызларны уйлап, төннәрен йоклый алмый ята торгандыр. Бәлки, аларны да ныграк безнең учак, ә бәлки, учак янына тезелешеп утырып, кайчак җил алып килгән төтеннән күзләрен угалап утырган кызларыбыз тартадыр...

— Кунаклар килде, каршы алыгыз, — дип куйды кемдер. Фәһим урыныннан сикереп торды да:

— Һәрвакыт шатланып, — дип машина янына йөгереп барып, башыннан эшләпәсен кулына алып, мушкетерларча сәлам бирим дигәндә генә, кабинадан төшеп килүче кешене танып, учак яктысы төшмәгән урынгарак сыпыртты. Бу — колхоз рәисе Латыйп Мотыйгуллович иде.

— Сәлам бирдек авылның батыр егетләренә һәм сылу кызларына, — дип шаян гына исәнләште ул тынып калган яшьләр белән.

Тыйнак кына җавап кайтардылар.

— Әллә орышырга килдегезме, иптәш рәис? — дип тынлыкны бозды шунда Фәһим.

— Юк, юк, нигә орышыйм, ди. Менә учак утыгызны күрдем дә, тукта әле, мин әйтәм, кемнәр икән болар, шундый матур итеп ял итүчеләр, дип яныгызга тукталырга булдым.

— Ай-һай, алаймы икән? — диде Фәһим, үзенә дә чак-чак ишетелерлек итеп.

Яшьләр, кысылышып, «рәхим итегез, утырыгыз» дип, кунакка урын бирделәр. Рәис кире какмады.

— Матурлыкка матур да, тик менә көзге яңгырлар, кышкы бураннар җитә бит әле, клуб булсын иде ул, — дип тын гына әйтеп куйды савучы кызыбыз Рәгыйдә.

— Әйе шул...

— Инде ничә ел клубсыз газап чигәбез...

— Кино карар идек, ичмасам...

— Үзебез концертлар, тамашалар күрсәтер идек...

— Элек безнең абыйлар, апалар менә дигән тамашалар оештыра иде бит...

— Идәннәрне «дер» селкетеп бер биюләре үзе ни торыр иде яңа клуб сәхнәсендә, — дип хыялга ук бирелеп китте Нәсим. Ул үзенең биергә гел җилкенеп торуы белән дан алган егет. Гармун тавышын ишетер хәле юк, аяклары үзләреннән-үзләре тыпырдап китәргә генә торалар. Аның бу йомшаклыгы билгеле булганга, егетләр-кызлар көлешеп куйды.

— Бик ямьле урын тапкансыз, әнә, матур итеп учак ягып җибәргәнсез. Клуб бер як читтә торсын. Клубта кичләрне сездәгечә ямьле итеп уздырып та булмый әле, — дип сүзне уенга бормакчы булды рәис.

— Ә кыш көннәрендә? Кыш көне болай учак ягып утырып булмый бит. Салкыннарда мичкә ике ягып өйдә җылы тормый әле, — дип үз сүзен кыстырды Хәлим, әтисе үлгәннән соң өендә хуҗа булып, хәзер төпкә җигелеп тартучы, өч сеңлесенә абый, анасына терәк булып калган егет.

— Ярый, элек — элек булган инде. Хәзер бит космос, атом заманы. Ә без монда бер клуб өчен зар-интизар булып ятабыз. Ояты ни тора. Әнә, күрше колхоз яшьләре көлә бездән. Бездән генә түгел... — «сездән дә» дип өстәмәкче булган иде дә Рәгыйдә, телен тыеп калды. Сүз зурга китә башлаганын сизепме, рәис:

— Ярый, ярый, егетләр-кызлар, уйлашырбыз, киңәшербез, — дип сүзне очламакчы булды.

— Әйе, гел шулай вәгъдә биреп куялар да, аннан онытыла...

— Сүз биргәч — үтәргә кирәк...

— Без дә бит чит кеше түгел. Күпләр колхозда эшли. Производствода эшләсәк ни — барыбер үзебезнең як өчен бит. Без дә өмәсенә дә, башка эшләргә дә катнашып, колхозга ярдәм итеп торабыз, — нефтьче Рәхим дә сүз кыстырмый түзмәде.

Шулай да бәхәс колхоз җыелышындагы кебек артык зурга китмәде. Авыл өстенә төшкән җәйге сихри кичме, яки тирә-якка тылсымлы яктылык сибеп, телләре белән йолдызлы күк йөзенә үрелеп, талгын гына янучы төнге учак сәбәпче булдымы — барысы да тынып, учакка карап уйга чумдылар.

Ә учак яна да яна. Әле берсе, әле икенчесе утын өстәп тора: ялкын азрак сүрелгән-

дәй була да, кинәт, яңа көч белән, «бөлт» кабынып, дөрләп янып китә. Баш очыбызда сары, кызыл, зәңгәр төстәге йолдызлар күз кысыша, тирә-ягыбызда биек дивар булып баскан каеннар да, сихерләнеп, учакка төбәлеп, тынып калгандай... Каенлыкның кайсыдыр почмагында гына берәр кошчык сайрап куя. Аннан, кинәт, ярамаган эш эшләдем, ахры, дигәндәй, туктап кала. Тик бераздан гына тагын икенче бер урында сайрау ишетелә... Аннан дөнья яңадан тынлыкка чума.

Рәис тә, таныш түгел тылсымлы көчкә буйсынып, уйга калган. Күңеленнән әллә төннәрен, учак ягып, атлар саклаган малай чагын, әллә яшь вакытында, колхоз малларын болынга алып чыккач, учак көленә күмгән бәрәңгенең кабыклары кызарып, телеңне йотарлык булып пешүен түземсезлек белән көткән чакларын, әллә студент вакытларының зәңгәр учакларын күңеленнән уздырды — ул да йөрәге белән яшь, уйлары белән ерак иде. Әллә ул да тәүге мәхәббәтен учак янында очраттымы икән? Әнә бит, күзләрендә яшьлек уты яна, йөзендә сизелер-сизелмәс елмаю чагыла...

Ә учак, кешеләрдә эше бар сыман, аларга таба талпынып, омтылып ала, нәрсәдер әйтергә тели кебек. Бардыр, бардыр. «Күңел җылысы алыгыз миннән. Күп итеп, гомерегез буена җитәрлек алыгыз. Башкаларга — күңеле, йөрәкләре өшегәннәргә, катлаулы тормыш юлында адашып, үзләренең учакларын таба алмый йөргән кешеләргә, туып-үскән җирләреннән суынганнарга өләшерсез», — дип әйтергә телидер. Аның да үз теле, үз моңы бар, аңлый белсәң — әллә нәрсәләр сөйли ала ул...

Рәис безнең янда озак тормады. Басудагы комбайннар янына китеп барышы иде бугай. Азрак эшебез, авылдагы тормышыбыз турында сорашып утырды да, урыныннан кузгалды. Кемгә ничектер, ә миңа аның күңелендә ниндидер үзгәреш туган кебек булды. Азмы-күпме, электән күргән кеше—үзебезнең рәис бит. Күзләрендә сүнмәс учак яктысы калды сыман. Китәр алдыннан гына:

— Сезме, учакмы, күңелемне әллә нәрсә эшләттегез әле. Яшьлегемә кайткандай булдым. Әйдәгез, шулай килешик: колхоз идарәсе исеменнән сезгә киләсе елга кышка кадәр клуб төзеп бирергә вәгъдә итәм. Планга кертергә берәр әмәлен табарбыз. Тик бер-ике шарт белән. Үзегез беләсез, колхозда һәрчак кызу эш вакыты, кеше дә җитми, сезнең ярдәмсез башкарып чыгып булмас бу эшне. Өмә турында уйлашырсыз. — Аннан, елмаеп, өстәп куйды: — Җәй көне каенлыктагы учагыгызны сүндермәскә сүз бирәсез. Тик, карагыз аны, янгыннан сак булыгыз, — диде.

Яшьләр мондый шатлыкка түзеп торамы соң?! Каенлыкны яңгыратып, «ура» кычкырмый түзә алмадылар.

— Көнләшәм мин сездән, чукынчыклар. Без дә кайчандыр яшь идек. Хәзер ышануы да кыен. Шуңа үзебезнең яшь чакларыбызны, хәзерге яшьләр ни белән яши — шуны онытып җибәрәбез, ахры. Менә әле шуны учагыгыз искә төшерде, аңа рәхмәт әйтегез, — диде дә рәис, кинәт борылып, машинасына таба юнәлде. Без, яшьләр, бердәм сикерешеп торып, аны озата бардык.

Рәиснең шатлыклы вәгъдәсеннән соң учак яны тагын да җанлана төште. Барысы да,

бер-берсен бүлдереп, клуб төзелгәч нәрсәләр эшләячәкләре турында сөйләшә башладылар. Шатлыгыбыз эчебезгә сыймый иде безнең. Фәһим, тапкыр сүзле Фәһим, учакка карап:

— Ян, учак, ян! Хәтта рәис кадәр рәиснең таш күңелен, туң йөрәген эреттең бит! — дип, көләргә сәбәп кенә көтеп торган яшьләрне көлдереп алды. Рәгыйдәнең кыюсыз гына:

— Тагын алдамаса ярый ла... — дигәнен:

— Авызыңнан җил алсын! — дип бүлдерделәр.

Бүген башка көннәргә караганда шактый озак утырылды. Таралышкан чакта да, башка вакыттагыча, учакны ничек кирәк алай гына сүндереп кайтып китмәдек, ә, киресенчә, утын өстәп куйдык. Ул безнең арттан балкып, ялкын телләренең яктысы белән ак каеннар кәүсәсендә уйный-уйный калды. Янсын, әйдә, бәлки, берәр арыган төнге юлчы аның янында туктап, ял итеп китәр. Ә без иртәгә тагын кабызырбыз сине, учак. Бүгенгә хуш, иртәгәге зәңгәр төнгә кадәр суынмый безне көтеп тор...



## ЧӘЧӘКЛӘР

Кадыйр сыйныфташы Маратны, уйламаганда-көтмәгәндә, шифаханәдә очратты.

Аларның күптән күрешкәннәре юк иде. Кадыйр аны моннан... әйе, ике ел элек күреп калган иде. Күз кырые белән генә, дигәндәй.

Тик сөйләшеп торырга туры килмәде. Еллар үткәнгә яки аралар суынганга түгел. Ә башка сәбәп аркасында.

...Ул аны теге вакытта кибет янында күрде. Алдында чират кайнап торган, ә ишегеннән ашыга-кабалана аракы шешәләре күтәреп яисә кесәләренә яшерә-яшерә берөзлексез чыккан, этешеп-төртешеп алга үтәргә тырышкан кешеләр белән ыгы-зыгы килгән сәүдә ноктасы яныннан үтеп бара иде. Күзенә сыйныфташы Марат чагылып калгандай булды. Кадыйр, кеше үзгәрсә дә үзгәрер икән, дип, аптырады. Шешенгән, күптән кырынмаган йөз, уң күзе астында кара янып кемнеңдер йодрык эзе ярылып ята. Өстендә таушалган, бер генә төймәсендә эләгеп торган пальто. Башындагы бүреге дә яхшы тормыш күргәнгә охшамый. Ул карлыккан тавыш белән, үзе кебек таушалып беткән бер адәм белән чиратта кычкырып әрләшеп тора иде. Китапка сыймаган сүзләр дә ишетелеп кала. Кадыйр ул вакытта аның янына бармады. Ә Марат аны күрмәде дә. Кадыйр соңыннан, бәлки ялгышканмындыр, дип тә уйлап куйды. Бу кешенең аның элекке сыйныфташы булуына ышанасы килмәде.

Тик бүген Кадыйр алдында бөтенләй башка, элекке, мәктәп елларындагы Марат басып тора иде. Үзенә үлчәп, оста куллар теккән костюм, күзнең явын алырдай ак күлмәк кигән, костюм төсенә карап сайлап алынган галстук таккан. Нык кырынганлыктан чигәләре зәңгәрләнеп тора, хушбуй белән әллә башыннан коенган — хуш ис борынны ярып бара.

Шифаханә халатында коридорга чыккан

Кадыйр аның белән чак йөзгә-йөз бәрелешмәде. Исәнләшкәч тә, озак кына кулларын ычкындырмый тордылар.

— Авырып киткәнсең, дисәм? Моңа ышануы да кыен, син бит мәктәпнең беренче спортчысы була торган идең, — дип сүз башлады Марат, елмаеп.

— Юк, болай гына әйткәндә, пүчтәк. Савыктырдылар инде. Бүген-иртәгә чыгарачаклар. Ә үзең соң? Нинди җилләр ташлады? Берәрсенең хәлен белергә килдеңме әллә?

— Шулайрак иде дә... — Шунда Марат кыенсынды, кулындагы чәчәкләрне Кадыйр күзенә чалынмаслык итеп тотарга тырышуы сизелеп тора иде. Тик Кадыйр ак розаларны күреп калды.

— Син нигә уңайсызланып киттең әле? — Кадыйр аңа, шаяртып, бармак янады.—Кыюрак бул, кыюрак, кызлар чаяларны ярата ул. Хәлеңне аңлыйм, минем дә кайчандыр кызларга чәчәк бүләк иткән чакларым бар иде.

— Син нәрсә сөйлисең? Нинди кыз, ди? Ике балам йөгереп йөри. Хатыным шифаханәдә ята минем.

Кадыйр, үзенең кыек «атканын» аңлап, көлми булдыра алмады.

— Ә мин сине һаман егет булып йөрисең икән, дип торам. Өйләнгән булгач, чәчәкләр бигрәк тә кирәк. Кыз белән егет чакта кем дә бүләк итә аны. Бүген бит — хатын-кызлар бәйрәме. Тик хатыныңа, бәхетсезгә җил каршы, дигән сыман килеп чыккан икән шул.

— Шулай туры килде инде.—Бу сүзләрдән соң Маратның йөзе караңгыланып китте.

Кадыйр урынсызга шаяртуына уңайсызланып:

— Бик җитди авырыймы әллә? — дип сак кына сорарга базнат итте.

— Болай юк кебек. Әйтсәм, ышанмассың инде... Барысына да шушы чәчәкләр гаепле...

— Димәк, хатыныңда чәчәкләргә аллергия, дигән сүз. Ә моның белән шаярырга ярамый.

— Алай димәдем ләса. Аллергия булса, бүген монда чәчәкләр тотып килер идеммени?

— Чынлап та... — Кадыйр аптырап калды. — Алайса, чәчәкләрнең ни катнашы бар? Мин сине аңлап бетермим...

— Аңламассың да шул. — Марат тирә-ягына каранып алды да: — Әйдә, булмаса, утырып сөйләшик. Аннан, хәзер хатын күзенә чәчәкләр белән күренергә дә куркам инде. Тагын берәр хәл булмагае...

Ул шулай дип Кадыйрны ныграк аптырата гына төште, кызыксынуын тагын да арттырды.

Дивар буена, хәл белергә килүчеләр өчен почмакка куелган диванга барып утырдылар.

— Хатының нинди серле авыру белән авырый соң? — дип Кадыйр аңа сүзне ялгап җибәрергә булышты.

— Дөресен генә әйткәндә, ул түгел, ә мин үзем авыру идем кайчандыр.

— Син һаман табышмаклар белән сөйлисең, мин хәзер бөтенләй буталып беттем...

— Ашыкма. Ничек бар, шулай сөйләп биргәч, аңларсың. Әйе, куркыныч авыру белән чирләдем мин. Ә өрлек кебек ир кешедә, үзең беләсең, бары тик бер авыру гына булырга мөмкин. Без аны тазалыгыбызны бетерер, бәхетебезне, тормышыбызны җимерер өчен үзебез сатып алабыз. Үзебезнекен генә микән

әле? Нәрсә әйтергә теләгәнемне аңладыңмы инде?

— Эчүне әйтәсеңдер инде.

— Нәкъ өстенә бастың. Көн дими, төн дими, берничә ел буе эчтем. Ә бит шаярып кына башлаган кебек идем. Аннан китте дә китте... Хатын бу елларда ничек түзде икән, үзем дә аптырыйм. Яраткан, димәк. Эшләп тапкан акчамны ничә тапкыр гына өйгә алып кайтканым булгандыр. Ике бала белән ничек көн күргәндер, белмим. Хәзер уйласам, җир ярылса, җир тишегенә керер идем.

Хатын минем авыру белән аз көрәшмәде. Бервакыт бу чиремнән арыначагыма, минем беткән кеше түгеллегемә ышанган, димәк. Тик соңгы вакытта гына, көчсезлегенә ачынып, нәрсә эшләргә белмәде. Ярый әле, акылыма килеп, тукталырга көчем җитте. Бар ихтыяр көчемне тупладым да кырт кистем. Моның миңа күпмегә төшкәнен сөйләп тормыйм. Юк, дәваланмадым. Күрәсең, тәмам агуланып бетмәгән булганмын. Аннан, әгәр кеше үзе теләмәсә, дәвалау гына нәрсә бирә? Эчүне ташлагач, авыр, куркыныч төштән арынган кебек булдым. Юк, алай дию генә дөрес булмас. Шундый хис — әйтерсең, яңадан тудым.

Иске дуслар белән араны өзәргә туры килде. Ә эчәргә дисәң, кыстаучылар җитәрлек. Ныклап эшкә урнаштым. Тирә-ягыма ныклабрак күз сала башлагач, шушы еллар эчендә дөньядан бөтенләй артта калганымны бар тирәнлеге белән аңладым.

Бөркөн эштән кайтканда чәчәк сатып торалар. Ир-егетләр чәчәк ала. Тукта әле, мин әйтәм, мин кемнән ким, хатынны шатландырыйм.

Ничек бу уй минем башка элегрәк килмәгән? Чәчәкләр тотып, өйгә кайтып кердем дә:

— Болар сиңа,—дип Мәрзиягә суздым. Ул кухняда ашарга әзерләп йөри иде. Башта мине эчкән, дип уйлады, ахры. Ә аек икәнемне белгәч, әллә нәрсә эшләп китте: күзләре зур булып ачылып, керфеге дә селкенми миңа карап басып тик тора. Шулай басып торды-торды да, йөрәгенә тотынды. Әгәр тотып калмасам, егылыр иде. Бу аңлашыла да: аның бергә яши башлаганнан соң диярлек, миннән чәчәк күрү түгел, яхшы сүз ишеткәне дә булмагандыр. Үзе бигрәк нечкә хисле, барысын да күңеленә якын алучан. «Ашыгыч ярдәм» чакыртырга туры килде. Йөрәге ярылгандыр яки башка төрле начар нәрсәдер, дип, курыккан идем. Ә бүген шифаханәгә килсәм, авыруы хәзергә тиз үтте үтүен, тик алдагы көннәрдә хатыныгызны андый-мондый кискен кичерешләрдән саклагыз, югыйсә, соң булуы бар, диделәр.

Шуңа менә хәзер куркам. Чәчәкләрне күреп, тагын да һушын югалтып куяр, дим. Нәрсә эшләргә белгән хәл юк. Чәчәкләрне дә бүләк итәсем килә. Гомердә беренче тапкыр бит. Шулай килеп чыксын әле...

Менә шундый хәлләр, Кадыйр дус. Кешегә сөйләсәң, ышанмаулары бар. Хәер, кемгә сөйлим инде мин боларны... Әле сиңа нигәдер...

Кадыйр да аңа нинди киңәш бирергә дә белми, аптырап калды.

...Кинәт Марат сискәнеп китте, аннан агарынды. Үзе дә сизмәстән, утырган урыныннан күтәрелә башлады. Күренеп торган чәчәкләрне яшерергә ашыкты. Кадыйр нәрсә бул-

ганын, Маратны нәрсә куркытканын аңларга теләп, ул караган якка күз салды.

Алар янында диярлек егерме сигез-утыз яшьләр тирәсендәге матур гына ханым басып тора иде. Кадыйр аның Маратның хатыны Мәрзия икәнен аңлады.

Тик Марат юкка курыккан булып чыкты. Мәрзия иренә карап, күз яшьләре аша бәхетле елмая, кай арададыр кулына чәчәкләрне дә алырга өлгергән... Марат, үзе дә сизми, биреп ташлагандыр инде — каушавы йөзенә чыккан бит. Мәрзия аларны кадерләп күкрәгенә кысты. Һәм шунда чык тамчысыдай бер бөртек күз яше, сиздерми генә, ак-ак чәчәкләргә тамды.

Кадыйр, ир белән хатынга комачауламыйм, дип, шым гына караватына кереп ятты. Елмаеп, Марат кулындагы чәчәкләрне күз алдына китерде. Һәм...

Тукта әле, тукта, ә ул үзе хатынына соңгы тапкыр кайчан чәчәкләр бүләк иткән иде соң әле?..



## ТАШ СЫН

Җәй артыннан көзләр килде.

Кеше гомере дә шулай. Яшьлек үтә, картлык җитә. Шуңамы икән, картлар авыр көз айларын өнәп бетерми. Һәм аз гына кояшлы көн булдымы, бакчаларда, скверларда, парк-

ларда картлар пәйда була. Кемдер акрын гына арлы-бирле асфальт сукмак буйлап йөренә, кайсысы эскәмиядә ялгызы уйланып утыра яки, иптәше булса, талгын гына гәп куерта. Тик җылы көннәр сирәкләнә бара. Салкын төньяк җилләре ешрак исә, күктә берөзлексез соры-кара болытлар йөзә. Аяк астында юеш җир чыптырдый. Картлар да югала. Өйләр дә, агачлар да кечерәеп калган, күшегүдән соры төскә кергән кебек. Кошлар чыркылдавы да ишетелми, бары тик шәрә агач ботакларында җил сызгыра. Күптән түгел явып үткән яңгыр тамчылары, шыбырдашып, коелган яфраклар өстенә сибелә.

Шундый көзге көннәрнең берсе иде.

Район үзәгенең яңа нефтьчеләр йорты алдындагы бакча янынннан сирәк-мирәк кенә кешеләр үтеп тора. Монда хәзергә әллә ни карар, игътибар итәр нәрсә дә юк әле. Күптән түгел утыртылган агачлар да күтәрелеп китә алмаган. Хәзер алар кышны каршы алырга әзерләнә. Ә уңдырышлы урман туфрагыннан аерып кызыл балчыкка утыртылган агачларга тамыр җибәрү җиңел түгел. Тик, шулай да, тормыш үзенекен итә, һәркем, һәрнәрсә яктыга, биеккә омтыла.

Яңа сарай алдында девон тирәнлекләрен яулаучы нефтьченең таш сыны да басып тора. Тик нигәдер ул мартен янында эшләүче корыч коючыны хәтерләтә төшә. Өстәвенә, үзе бил тиңентен ялангач. Ирексездән, чишенеп эшләгән нефтьчене бу скульптураның авторы кайда күрде икән, дигән уй килә. Брезент кием киеп эшләгәндә дә тәнгә үтеп керә әле ул «кара алтын». Яки аның: «Нефтьне менә шундый киң күкрәкле, кабарынкы мускуллы кеше-

ләр чыгара», — дип әйтәсе килдеме икән? Ярый, монысы аның вөҗданында.

Урамнан кычкырып көлешә-көлешә үтеп барган өч яшь-җилкенчәк бакчага таба борылды. Скульптура каршына куелган эскәмиягә утырып, кыйммәтле тәмәке кабыздылар. Үзләре, кызып-кызып, мода, кием, рок-музыка, кызлар турында сөйләшәләр. Хәер, башка нәрсә хакында сөйләшсеннәр соң инде? Аларга бит хәзер бер телем икмәк турында баш ватасы юк. Әти-әнисе бар, аларның кесә тулы акчасы бар. Сорарга иренмә генә. Күрше эскәмиягә хәле бетеп килеп утырган картта эшләре дә юк.

Сабир абзый ул. Күрше йортта яши. Яше дә бара — сиксәнне узган. Кайчак зиһене дә чуалып киткәли — шул картлык галәмәте. «Бала-чага акылы керә башлаган инде», — диләр андыйлар турында халык арасында. Яшьләрнең кирәгеннән артык кычкырып сөйләшүе аның колагына кереп тә карамый кебек. Таягына ике куллап таянып, шуңа ияген терәп, нефтьче сынына текәлгән, ниләр уйлаганын, кем әйтмешли, бер Алла гына белә. Юк, Сабир абзый үзе нефтьче түгел түгеллеккә. Ул хаклы ялга чыкканда район җирендә тәүге бораулау корылмалары зур яңалык иде әле. Шулай да, кызыклы, гыйбрәтле тормыш юлы үткән, барысын да күргән, башыннан кичергән.

Кинәт салкын, көчле җил исте. Сабир абзый хәтта селкенеп куйды. Ә егетләрнең берсенең эшләпәсен җил очырып алып китеп, картның аяк астына китереп ташлады. Күрше эскәмиядә көлеш катыш ыгы-зыгы купты. Эшләпә хуҗасы йөгереп килеп җитте.

— Картлач, тот, тот, җибәрмә!

Сабир абзый дертләп китеп:

— Әү, балам? — дип, егеткә сораулы карашын юнәлтте.

Тегесе аңа карап алды да:

— Ә-ә, барысы да аңлашылды, — дип, эшләпәсен иелеп алып, кире китте. Иптәшләре янына килгәч, көлеп нәрсәдер әйтте. Тегеләр, картка борылып карап, кычкырышып көлделәр.

Сабир абзыйның аларда кайгысы юк иде. «Бу таш кешене әйтәм, ялангач бит. Өшидер инде ул. Якын-тирәдә берәр нәрсә дә юк, һич югы, өстенә ябар идем. Үземнең көч җитмәсә, әнә теге малайлар ярдәм итәр иде», — дип сөйләнде ул үзалдына. Тирә-ягына тагын бер тапкыр каранып алды. Ябардай бернәрсә дә юк, һәркайда — таш. Шунда Сабир абзый, башына бер эшлекле фикер килгәндәй, хәрәкәтләнеп куйды. Башта таягын бер читкә сөяде дә, җылы сырмасының төймәләрен ычкындыра-ычкындыра, торып басты, аннан сала башлады.

— Минем өем җылы, бу бичара өшемәсен. — Монысын ул егетләргә әйтте, ахры. Тегеләр аңа аптырап карады.

— Шушындый бугай ул, — дип берсе чигәсе тирәли, юләр дигәнне аңлатып, бармагын боргалап күрсәтте.

— Картлык — шатлык түгел. Аның яшенә җитәргә язмасын, — дип, икенчесе кушылды.

Карт таш сын янына килеп баскан иде инде. Кулында — калын сырмасы. Тик сын биек, аның гына буе җитәрлек түгел. Сабир абзый, ярдәм көткәндәй, яшьләргә борылып карады.

Ә тегеләр хахылдашуын белә. Җитмәсә, берсе:

— Картлач, чалбарыңны да сал, бер булгач, булсын, — дигәч, көлү хәтта йортлар тәрәзәсендә чыңлады.

Нәрсә белән беткән булыр иде бу хәл — сукмакта кырык яшьләрдәге хатын күренде. Картны күргәч, йөгереп үк килде.

— Әткәй, нигә салдың киемеңне? Ки тизрәк, өшисең. Нигә мине көтмәдең инде, урамга бергә чыгарбыз, дигән идем бит.

— Соң, кызым, өшеп тора бит. Менә, кидерик шушыны. Син ачуланма, Фәния кызым, кием бетмәс әле. Яңа пальтом да бар кыш киярга. Анысын бирсәк тә ярый, бигрәк авыр, үзе бер пот. Карт кешегә менә сырма җиңел...

— Йә, ярый, әткәй, әйдә, кайтыйк. Кеше көлдермик. Таш сын бит ул, тимер өшимени? — Үзе Сабир абзыйның сырмасын алып, кидерә башлады. Әтисе карышмады. Бер яктан таягына, икенче яктан кызы кулына таянып, йортларга таба атлады. Ә егетләр бөгелә-сыгыла кычкырып көлеп калдылар. Кызык бит. Аларга бераз вакытка сөйләргә туләусез курсәтелгән бер мажара, эч катыргыч тамаша булды.

Сабир абзый, урамны чыгар алдыннан, туктап хәл җыйды, сынга янә бер борылып карады. Күзләрендә таш сынга ярдәм итә алмаганлыктан туган уфтану иде. Бәлки, бу аның, изгелек эшләргә теләп тә, тәү тапкыр ярдәм итә алмый китүе булгандыр — кем белә? Аннан картның күз карашы егетләргә төште. Алар һаман көлешә иде әле. Картның йөзе караңгыланды, куе кашлары җыерылды.

Егетләрнең берсе, аркасын нидер көйдер-

гәндәй, кинәт борылып карады. Картның карашы белән очраштьт. Бу «көрәш» ике-өч секунд чамасы гына дәвам итте. Егет иптәшләре эндәшкәнгә, аларга борылды.

Сабир абзый күз карашын тагын сынга күчерде дә, «таш, таш», дип нидер сөйләнде. Шуннан соң, көрсенеп, аны сабыр гына көтеп торган кызына борылды. Урам аша чыкканда картның аяк атлаулары тагын да авырайган кебек иде.

Тиздән кыш җитте. Сабир абзый урамда башка күренмәде.

Ә ямьле яз ае кергәч, район үзәге читендәге мөселманнар зиратында тагын бер яңа кабер үсеп чыкты.

## ВӨҖДАН ГАЗАБЫ

«Гали карт каты авырый икән, озакка бармас, ахры», дип ишеткән иде Гыйләҗ. Дөрес хәбәр булып чыкты. Әле генә оныгы килеп:

— Сине картәти чакыра,—дип әйтеп китте.

Яшь чакларында Гали белән Гыйләҗ дус булып йөрсәләр дә, соңыннан аларның аралары суынды, дөресрәге, Гали читләште бугай. Соңгы вакытларда, очрашсалар да, исәнлек-саулык сорашудан узмыйлар иде.

...Гыйләҗ карт барып кергәндә өйдә Гали белән аның хатыны Талигадан башка кеше юк, Гали түрдә, биек итеп салынган түшәк өстендә ята иде. Аның хәлсез, кан әсәре калмаган куллары аз гына калтырыйлар. Гыйләҗ Талига белән баш кагып кына исәнләште дә, түргә үтте. Аңардан күзен алмаган Гали,

«утыр», дип ымлады. Гыйләҗне аның күзләре гаҗәпләндерде: алар туры карарга курыккандай, бер әйбердән икенчесенә күчеп йөриләр һәм Галинең бары тик күзләре генә яшиләрдер, ә калган әгъзалары җансыздыр кебек тоела иде.

Гыйләҗ авыруның аяк очына, караватянына куелган урындыкка сак кына килеп утырды. Галинең ябыккан, күзләре эчкә баткан, ияге очлаеп калган йөзенә карагач, күңеле кызгану хисе белән тулды, тамагына төер утырды.

— Бирешкәнсең, кордаш, бирешкәнсең, — диде ул карлыгып киткән тавыш белән. Тик Гали аның сүзләрен ишетмәде, ахры.

— Нигә чакыртты икән... бу, дип аптырама. Хәзер аңлатам, — дип сүз башлады ул. Аның тавышы гыжылдап чыга, бер сүз әйткән саен диярлек туктап хәл ала. — Ничә ел күңелемдә... йөрттем. Онытырмын, дидем,—онытылмый икән. Ә хәзер түзәрлегем калмады, үзем белән гүргә алып китәсем килми... Синең хөкемгә тапшырам, чөнки сиңа кагыла ул. Тыңла, ни әйтсәң дә, ни генә дисәң дә — синең ихтыярда...

Ул туктап хәл алды да, сөйли башлады.

— Тик син мине бүлдермә, сөйләп бетергәнне көт. Дөнья хәлен белеп булмый...

...Смоленск дигән кала янында әсиргә төшкәннән соң безне бер лагерьдан икенче лагерьга йөрттеләр. Берсендә озак кына тордык. Немецның безне бушка ашатырга исәбе юк иде, станциягә, Германиягә озатыр өчен, агач төяргә йөртәләр. Иртәннән алып караңгы төшкәнгә кадәр эшләтәләр. Лагерьга йокларга гына алып кайталар.

Беркөнне авырып егылдым. Авыруларны эшкә алмыйлар иде, берничә кеше каты сәкедә аунап калдык. Көндез, азрак хәл кергән кебек булгач, барактан тышка чыктым да, сакланып кына аның ышыграк дивары буйлап киттем. Саклануның сәбәбе шул: көндез әсирләр эштә, сакчылар лагерь буйлап аяк өсте йөргән әсирне күреп калсалар, манарадан ут ачалар. Кызык өчен. Сиңа сөйләп торасы юк инде, үзеңнең башыңнан кичкән.

Шулай бер барак янында җирдә яткан әсиргә тап булдым. Аның яңа дип әйтерлек итеге белән шинеленә күзем төште. Ә әсирдә җан әсәре юк диярлек. Йөзен сакал баскан, үзе тире дә сөяк кенә калган. «Озакка чыдамас, барыбер үләр», — дип уйладым да, итеге белән шинелен салдырып алдым. Борылып китим, дигәндә, аның йөзе миңа таныш сыман тоелды. Ныклап күз салгач, таныдым мин аны. Ул — син идең...

Гыйләҗ сискәнеп китте, тураеп утырды. Аның күзләре Галигә кадалды.

— ...Тик синдә яшәү чаткылары бик аз калган иде бит. «Барыбер үләчәк», дип уйлап, үз барагыма кире борылдым. Ә икенче көнне безне тагын икенче урынга күчерделәр...

Гыйләҗ аны, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, зур авырлык белән тыңлап утырды. Гыжылдаган тавыш һаман тынмады:

— Монда кайтып, синең исән-сау икәнеңне ишеткәч, нәрсә эшләргә дә белмәдем. Төннәрен саташып, сикереп тора идем... Ә шинелең белән итегеңне чыгарып ташларга да, юк итәргә дә кулым бармады, нидер тотты. Бүгенге көнгә кадәр сакладым...

Аның тавышы яңадан өзек-өзек чыга башлады:

— Бәхиллегеңне бир миңа... Тынычлап үлим... Беләм, изге күңелле кеше син... Әнә, теге елны авылда янгын чыгып, алты йорт янып киткәч, үзеңнең яңа бураңны җиде балалы Нәҗметдингә биргәнеңне халык һаман онытмый... Бир бәхиллегеңне... Итегең белән шинелең чормада... Ал шуларны... Алмасаң, каберемдә дә тынычлык булмаячак миңа...

Гали сөйләгәндә ниләр генә үтмәде Гыйләҗ картның башыннан. Күзләре җаны менә-менә чыгам дип торган Галидә булса, уйлары ерак иде аның. Моннан кырык ел элек үткән хәлләрне тагын да исенә төшереп, җаны дертләп китте.

...Әйе, булды андый хәл. Концлагерьда таралган ниндидер чир аны да аяктан еккан иде. Баракның тынчу һавасына чыдар әмәле калмагач, шуышып булса да, барак алдына чыкты. Тик салкын, ачлык, авыру үз эшен эшләгән, кире керерлек хәле калмаган, аңын җуеп, ятып калган. Әнә шунда Гали аңа юлыккандыр да инде. Тик Гыйләҗнең әҗәле җитмәгән булган, күрәсең... Күпме яткандыр, мәетләрне җыеп йөрүче әсирләр командасы, аңа тап булып, әле җаны бар икәнен күреп, шифаханә сыман урынга илтеп куйган. Кешене, җаны була торып, җиргә күмеп булмый бит инде... Ә Гыйләҗнең әчәсе суы бетмәгәч, туган иленә әйләнеп кайтты, балаларын аякка бастырды, кеше итте...

...Юк, бер сүз әйтә алмады Гыйләҗ. Кирәкмәс иде Галигә моны сөйләргә... Үзенә дә, Гыйләҗгә дә җиңелрәк булыр иде... Гыйләҗ акрын гына урыныннан торды да, Галигә кү-

тәрелеп карый алмыйча, ишеккә юнәлде. Ишек тоткасына үрелгәч, туктап нидер әйтергә уйлаган иде дә, аяклары тыңламады. Түшәктә яткан бу кеше белән бер һаваны сулар хәле калмаган, аңа монда һава җитми иде.

Аны, көчсезлегеннән куз кебек янган күзләр, әле һаман өметен өзми, нидер көткән килеш, озатып калдылар...

...Гали карт үлеп күпмедер вакыт узгач, нәрсәдер эзләп чормага менгән оныгы, шинель белән итекне табып, дәү әтиемнең сугышта йөргән киемнәре, дип, аларны мәктәп музеена илтеп тапшырды.

## ХОДАЙ ХӨКЕМЕ

Кичә, кичке якта, Яңа күпер урамындагы унынчы санлы йортта зур фаҗига булган. Өч катлы йортның түбәсеннән калын боз катламы ишелеп төшеп, Зәкәрия исемле ирне басып үтергән. Яңалыкка сусаган тирә-як йортларда яшәүчеләр, «гөж» килеп, шаулашып хәбәр сөйли.

Икенче көнне күршедә урнашкан унберенче санлы йортның ишек алдына да кич эштән кайтып килүче халык җыелды. Һәркемнең үз сүзен әйтәсе, мәрхүм белән булган вакыйгалар турында сөйлисе, аның хакында белгәннәрен башкалар белән уртаклашасы килә. Кемдер кайчандыр бергә табында утырган, кемдер бергә эшләгән, кемнеңдер улы аның кызы белән бер мәктәптә укый икән. Тик, иң мөһиме, кешеләрне нык кызыксындырганы — аракы эчкән булганмы, юкмы? Бу сорау, билгеле, күбрәк хатын-кызга тынгылык бирми.

— Эчкән булганмы соң?
— Эчкәндер, эчми әллә. Хәзер эчмәгән ир бармыни?!
— Юк, алай бик «төшереп» йөргәне сизелми иде.
— Бәлки, эчкәндер дә. Кайбер акыллы ирләр, эчсә дә, кешегә күрсәтми. Безнекеләр кебек, урамда аунап ятып, кеше көлдерми.
— Өй алкашы, дисең инде? Бәлки, саранлыктандыр? Безнекеләр генә ул, «дусларны» сыйлыйм дип, ыштанын салырга риза...
— Йә, хатыннар, әллә нәрсә сөйләмәгез мәрхүм турында. Урыслар, әнә, мәрхүм турында яки яхшысын гына искә ал, яки бернәрсә дә сөйләмә, ди.
— Анысы шулай инде. Әле болай гына әйтүем. — Тик тагын үзе үк: — Нигә, дөрес түгелмени? Катылыкка каты иде инде. Бурычка кайчан гына акча сорап керсәң дә, белгәне «юк» булды...
— Әллә үчең бар идеме — кирегә «сукалап» тик торасың?
— Нинди үчем булсын, ди? Бергә тапканым да, сатканым да булмады.
— Соң, шулай булгач, сиңа саран ни дә, юмарт ни...
— Урыны җәннәттә булсын, диген, ичмасам.
— Эчкән булган, ди шул. Алай күп түгел бугай. Хатыны Факия теге сатучы Зәбирәгә сөйләгән. «Нигәдер эчем пошып тора, аракыны да, хатын, китер әле саклап тоткан яртыңны», — дигәч, биргән идем. Бер рюмка гына салып эчте дә, аш ашады, чәй эчте. Аннан тәмәке тартырга дип, ишек алдына чыкты. Нәрсәдер «гөрст» иткәнгә, кешеләр кычкы-

рышканга тәрәзәдән карасам, боз астыннан ике аягы гына күренеп тора. Йөрәгем ярылгандай булды. Их, ничек сизмәдем, нигә әйтмәдем, башка вакытта бәдрәфкә кереп кенә тарта иде бит, дип. Хәзер үкендең ни дә, үкенмәдең ни. Әҗәле алып чыккандыр инде», дип елый дип сөйләп торды Зәбирә.

— Шулай инде. Әҗәлең җитсә, күркә тап-тап үтерер, ди.

— Әйткән идем бит, эчкән булгандыр, дип.

— Һи, ул явыз аракы кемнәрнең генә газиз башына җитми дә, кемнәрне үксез ятим калдырмый. Ходай күрсәтмәсен инде, безнекеләр дә эчә. Ут йотып, өйдә ятасың, кайда, нәрсә эшләп йөри икән, кемнәр белән сугышты икән, кайда үтереп ташладылар икән, дип. Я, Ходай, үзең ярдәм бир Алла бәндәләренә...

Сүз әле бик озак шушы фаҗига тирәсендә әйләнде. Иң соңыннан чыгарылган «хөкем карары» кыска, ләкин каты булды: бу эчкечелек күпме өрлек кебек ирләрнең башына җитә. Менә тагын бер мисалы — күрше йорттагы бәхетсезлек очрагы.

Тик бер як читтә хатыннар гайбәтен сүзсез генә тыңлап утырган, бераз кызмача Зәки абзый гына үзалдына сөйләнеп куйды:

— Ярый, эчкән дә, ди. Тәмәке тартып түбә астында торган, ди. Өстенә бозлы кар ишелеп төшкән дә, үлгән, ди. Тик монда аракы белән үлем сәбәбе арасында нинди бәйләнеш бар, аңламыйм. Ир кеше үлсә, тоталар да, эчеп үлгәндер әле, диләр. Ходай хөкеме ул. Түбәне вакытында көрәргә...

Аның соңгы сүзләре өстән, түбәдән ишелгән шытырдау, дөбердәү астында югалып калды. Түбәдән асылынып торган бозлы-кар-

лы авыр өем ишелеп, бер-берсен уздырырга тырышып гәпләшеп торган хатын-кыз төркемен күз ачып йомганчы аяктан екты. Үзәк өзгеч кычкырулар гына ишетелеп калды. Тиздән өч-дүрт хатын-кызны бер-бер артлы килеп җиткән «Ашыгыч ярдәм» машиналары алып китте.

...Өченче көнне кич күрше уникенче санлы йортның ишек төбенә монда яшәүчеләр җыелды. Кичә унберенче йортта хатыннар белән булган хәтәр вакыйгага карата үз сүзеңне әйтми, белгәнең белән уртаклашмый, бераз гайбәт сатып алмый буламы соң инде...

Ә түбәдәге авыр карлы-бозлы өем, акрынакрын гына шуышып, һаман саен түбә кыегының читенә якынлаша иде...

## БЕР-БЕРСЕНӘ ОХШАГАН

Юлда йөргәндә, гадәттә, беренче тапкыр күргән кеше дә якын һәм үз булып китүчән. Аның белән танышуыңа әле бер сәгать тә үтмәгән, ә ул кешене инде берничә ел беләсең кебек. Һич тартынмый эч серләреңне сөйлисең, тормыш хәлләрен барлыйсың. Кешенең халәте юл йөргәндә кинәт үзгәрә, ул икенче кешегә әверелә. Галимнәргә киләчәктә юл йөрүнең кеше психологиясенә йогынтысын өйрәнү буенча күп эшлисе бар әле. Бу өлкә — күтәрелмәгән чирәм. Шаярта дип уйламагыз, минем болай җитди сүз сөйләгәнем дә юк иде әле.

Башкалага автобуста барганда бер гаилә әгъзалары белән урыннарыбыз янәшә туры

килде. Үзләренең яше кырыкка якынлашып килсә дә, яшь ярымлык балалары да бар. Ире улын кулыннан да төшерми, аны төрлечә уйната, шаярта, аңысы шаркылдап көлә, ачылыр-ачылмас теле белән нәрсәдер сөйләнә, аңлата, сораша, тәрәзәгә төртеп күрсәтә, автобус эчендәге пассажирларга карап, нидер әйтергә тели. Аларны читтән генә күзәтеп, сокланып барам. Бәлки, мәхәббәтләрен соңлап кына тапканнардыр, шуңа әле аеруча бәхетле вакытларыдыр, дип уйлыйм. Менә, ямь өстенә ямь, бәхет өстенә бәхет булып, балалары да туган. Үзләре төскә артык матур булмасалар да, уллары сабый гүзәллеге белән гүзәл. Тулырак кына ак йөз, яңа гына чыккан аслыөсле дүртәр сөт теше энҗе кебек җемелди. Кием-салымы да бик чиста, пөхтә, аны «өф» итеп кенә торалар. Әлегә кыска йомшак кара чәчләре матур итеп таралган. Аңа сокланып карыйм. Бала да миңа елмаеп текәлә, кызыксынучан күзләре ялтырап китә. Аны, үзем белгәнчә, уйнатырга тырышам. Күчтәнәчкә дип алган шоколад кәнфитне сумкадан чыгарып, кулына тоттыргач, «серләр» аеруча берегеп китте.

— Йә, улым, нәрсә әйтергә кирәк абыйга? — дип атасы улына эндәшә. — Рәхмәт, дияргә кирәк, шулай бит?

— Әммәт! — дигән була тегесе.

Шулай безнең арада сүз бәйләнә сүз чыгып китте. «Кунакка йөреп килергә булдыгызмы?» — дигән сорауга:

— Исәп шулайрак иде. Менә тормыш иптәшемнең эти-әнисенә улыбызны күрсәтеп килик әле, дибез.

— Улыгызның яше шактый күренә, әле

һаман дәү этиләренә күрсәтмәдегезме? — дип сорыйм, аптырап.

— Шулайрак туры килде инде. Кайтып өйләнергә форсат тимәде. Без илнең бер почмагында, алар икенчесендә яши. Үзләре килер иде, яшьләре шактый. Ә без салкын, кеше аягы сирәк баскан якта акча сугабыз. — Әңгәмәдәшем көлеп куйды. Ул җир читендәге бер поселокны атагач, мин чыннан да шулай икәненә ышандым.

Шактый ара үткәч, автобус шоферы пассажирларны ял иттереп, аяк яздырып алырга туктады. Әңгәмәбез анда да туктамады. Галим исемле икән. Ул да минем тормыш хәлләрем, кайда эшләвем, гаилә хәлем турында сорашты. Үземнең инде егерме ел гаиләле кеше булуым, ике бала үстерүебез турында әйттем.

— Ә сез яңа өйләнешкәнгә охшыйсыз. Әле һаман баллы аегыз үтмәгән кебек, — дим, аны шаяртып.

— Һо, инде безнең бергә яши башлаганга уникенче елыбыз китте.

— Балаларыгыз ничәү соң, ишлеме?

— Ишле булмаган кайда? — дип яңгыратып көлеп җибәрде ул, тигез тешләрен күрсәтеп. — Өч малай бар. Нәрсә эшләтергә, ничек карарга да белгән юк, баш катты инде.

— Ничә яшьтәләр соң? Үсмер балаларның хәзер холкы утыра башлаган чак, тәрбиягә авыр бирелә торганнардыр. Үз тәҗрибәмнән беләм. Яңа көн туган саен бүген нәрсә ватарлар, нәрсә җимерерләр, кеше нәрсә дип килеп әйтер, мәктәптән кайсы укытучысы чакыртыр инде, дип котым очып тора торган иде. Өлкәннәре ничә яшьтә соң?

Галим тагын бер тапкыр кычкырып көлде дә:

— Кадимгә — бер яшь тә җиде ай, Нәдимгә — бер яшь тә җиде ай, Сәлимгә — бер яшь тә җиде ай... — дип, кызык итеп кенә әйтеп куйды.

— Нәрсә, игезәкләрме?!

— Әйе, — диде ул, бәхетле елмаеп. — Хатын белән ничә еллар гомер кичердек. Балабыз булмады. Һәм кинәт менә шундый бәхет...

Шунда башыма уй килеп төште. Әллә шаярта инде юлдашым? Өч игезәк, өч малай булгач, кайда соң калган... икесе? Бу сорау ничек тел очымнан ычкынганын сизми дә калдым.

— Ничек — кайда? Өйдә калдылар. Безгә бит аларны карарга шәфкать туташы бирделәр, аннан, аларның барысын бергә бу кадәр ерак юлга ничек курыкмый алып чыгасың? Монда җылы булса да, безнең якларда буран уйный, салкын.

Шулай да мин бу хәлне берничек тә башыма сыйдыра алмадым. Ә дәү әтиләре калган ике оныгын күрә алмый бит. Һәм тиз генә күрә дә алмаячак. Әле менә ничә елга бер кайтырга туры килгән.

Тик ул миңа каршы төште:

— Юк, тукта әле, синең моңа аптырап калганыңа мин аптырыйм. Берсен күрде ни дә, өчесен бергә күрде ни... Алар бит барыбер бер-берсенә су тамчысы кебек охшаган. Әби белән бабай түгел, үзем аермыйм әле аларны. Әнә, хатын ничек аерадыр... Ә өч яшь бала белән Себердән, Ерак Көнчыгыштан Европага кайтуы ул сиңа пилмән ашау түгел.

Уйлап-уйлап тордым да, Галим белән килештем. Һәм аңа кушылып көлеп куйдым.

Менә шундый бәхетле гаилә белән танышырга туры килде миңа юлда. Һәм үкенмим. Бу хәлне, кызык күреп, кемнәргә генә сөйләмәдем инде. Сезгә дә юлда йөргәндә тирәягыгызга күзегезне ачыбрак карарга киңәш итәм. Юлда аяклы мәзәкләр тулып ята ул. Кешегә сүз катарга гына иренмәгез, хәлен, тормышын сорашыгыз. Һәм сүз бәйләнә сүз китәр... берәр гыйбрәтле вакыйга ишетерсез. Килеп миңа сөйләсәгез, әбәзәтелни хикәя итеп чыгарам мин аны. Кулы белгән кешегә берни тормый ул...



## ҖИР ТЕТРӘҮ

Авылда җәй көне шундый бер мәл була: бар дөнья ничектер тынычланып кала, нидер көткәндәй тоела. Көне буе сайраган кошлар да, тынып, эссе көннән соң хәл җыйган кебек. Кояш баерга да әллә ни күп вакыт калмаган. Һәрнәрсәдән күләгә төшә, ул озыная бара. Бу — көтү кайтыр алдыннан булган тынлык.

Мин, өй тирәсендә эш беткәч, көтү кайтырын көтеп, урамда койма буенда үсеп утырган өянке агачы төбенә эшләнеп куелган эскәмиягә чыгып утырдым. Ничектер вакытны уздыру өчен өйдән бүген килгән гәзитләрне алган идем.

— Исән-сау гынамы, энем? Укыйсың инде, ә? — дигән тавышка күтәрелеп карадым. Минем янда бүген кырынмаганлыктан чигәләрен сакал төкләре баскан Фазыл агай басып тора иде. Исәнлек-саулык алышкач, мин аңа:

— Укыйм, Фазыл агай, хәзер дөнья уку белән алга бара бит, — дип җаваpладым.

— Анысы шулай, — дип килеште ул минем белән, яныма утырып алгач. — Ни язалар соң? Һич кенә дә вакыт юк, гәзит-мазар укырга да форсат тими.

— Дөньяда кызыклар күп инде ул. Менә әле «Безнең якларда җир тетрәү буламы?» дигән мәкаләне укып утырам.

— Нәрсә дидең? Җир тетрәүме? Йә, йә, ничек, андый нәрсәләр бездә дә бар, дигәнnәрме соң? — диде ул кинәт җанлана төшеп.

— Алай куркыныч нәрсә юк, Фазыл агай. Булса да, андый зур зыян китерердәйләре юк. Сизсә дә, аларны бик сизгер приборлар гына тотып ала. Галимнәр дә бу хакта шулай ди.

— Галимнәр, галимнәр! Нәрсә белә соң алар, кәгазьгә ябышып, бүлмәсеннән чыкмый ятучы ул синең галимнәрең! — дип кинәт Фазыл агай кызып китте.

Мин, аптырап, аңа карадым. Аның чәнечкеле күзләре, җавап көтеп, миңа текәлгән иде. Ничек җавапларга белмичә:

— Нигә алай дисең әле? — дип әйтү белән чикләндем.

— Әйтәм шул, белгәнгә әйтәм. Мең чакрым арада яшәп, нәрсә беләләр соң алар? Әйт әле, синең үз гомереңдә берәр галимне күргәнең бармы?

— Бар, нигә булмасын. Минем белән синең кебек кешеләр...

— Йә, синең булыр да, син укыган кеше. Ә менә минем — юк. Ә күрсәм, әйтер идем: сезнең барыгызны да эшегездән куарга кирәк, дияр идем... Һе, җир тетрәү юк, имеш! Менә безнең өйгә килсеннәр, күрерләр... Ничек җир генә түгел, ә дөнья тетрәгәнен.

Мин ирексездән көлеп куйдым. Эш менә нәрсәдә! Соңгы араларда Фазыл агайның Мәдинә җиңги белән аралары бозылып киткәнен ишеткән идем. Шуңа җанына тынгылык таба алмыйдыр, ахры. Ә ул, һич кенә дә шаяртырга уйламаганын белдереп, дәвам итте:

— Син көләсең, ә минем елыйсым килә. Җир тетрәү юк, имеш. Ә менә бездә көн дә җир селкенә, өйнең асты өскә килә. Кайда йөри шул вакытта синең галимнәрең? Нигә берсе дә аңлатмый бу хәлнең нәрсәдән икәнен?

— Нәрсә булды соң, Фазыл агай? Бәлки аңлатып сөйләрсең?

— Нигә сөйләмәскә, сөйлим шул. Кешедән яшерен-батырын уем юк. Үзең дә беләсең, быел кызыбыз унны бетерде. Менә атна-ун көн элек кенә урта белем турында таныклык бирделәр үзләренә. Җиңгәң җенләнде бит, энем, кызымны артист итәм, дип. Кызның әллә ни осталыгы да юк инде, күреп торам. Ә хатын әйтә, аларны укыталар бит, ди. Һе... талантың булмаса, укыту беләнмени? Ә менә мәгәр Фәридәне кыз кеше, димә, техниката кулы чат ябышып тора. Үземә охшап туган. Өч ел минем белән комбайнда ярдәмче булды. Трактор йөртергә хокук кәгазен дә мәктәптә үк алды. Әле менә миңа яңа комбайн бирделәр,

ә искесендә кызым үзем эшлим, ди. Эшләр дә шул. Тик юк, әнисе күзне дә ачтырмый. Соң, мин әйтәм, хәзер булыр-булмас артистлар буа буарлык. Начар артист булганчы, өйрәнеп алса, менә дигән механизатор чыга аннан. Ә хатынның үз туксаны туксан. Көндез эштә булгач, колагым тынычлап тора. Ә кичләрен давыл куба. «Тракторда эшләп, майга батып йөрү—хатын-кыз эше түгел, синең майга каткан киемнәреңне юа-юа да ару җиткән», — ди. Соң, кызым үз киемен үзе юа бит аны. Әнә шулай яшәп ятабыз әле, энем. Ярый, кайтыйм инде. Хәзер менә син тыңлап тор: бездә җир тетриме, юкмы? Синең галимнәрең бернәрсә дә белми. Тетрәми, имеш. Менә безнең өйгә килеп тыңласын алар, — дип сөйләнеп, ул йортына карап атлады. Мин утырып калдым.

Чыннан да, бераздан, бездән ун йорт аша өйдән бик әче итеп:

— Ә-ә-ә, кайттыңмы әле, майлы крис?! — дип тын һаваны челпәрәмә китергән тавыш яңгырады.

Мин көлемсерәп куйдым. Бу хәл озакка бармас ул. Җир тетрәү дә бер булып ала да, тына бит — Фазыл агайның да өендә тынычлык урнашыр. Ә калган ягына килгәндә — безнең Фазыл агай үз сүзен сүз итә торган кеше...

## ҖАЕН ТАПТЫ

Галим белән Сәет — ут күршеләр. Еш кына бер-берсенә кунакка да йөрешәләр, капка төбендә кояш батканчы гәпләшеп утырган

чаклары да була, шуңа һәркайсының гаилә, тормыш хәлләрен яхшы беләләр. Галимнең күршесе язмыштан зарланмый. Нигә зарлансын ул — йорт-җир иркен, кура тулы мал-туар, кош-корт. Хатыны да «һайт» иткәнгә «тайт» итеп тора, өйләрендә татулык хөкем сөрә. Яшә дә яшә генә. Әйе, дөньясы түгәл Сәетнең. Тик көтмәгәндә тормыш аның да бәкәленә нык кына китереп сукты. Йөзенә кара төште, үзе дә бөкрәеп, буйга кечерәеп калгандай булды...

Ә эшнең асылы шунда. Бер генә кызы үсте Сәетнең. Яшерен-батырын түгел: бердәнбер горурлыгы, өмете иде ул. Берәрсенең калага киткән кызы яки улы турында сүз чыкса, Сәет:

— Мин дә кызымны авылда калдырмаячакмын. Үзебез авылда чиләнгән дә җиткән. Институтка кертәчәкмен. Әлегә көчем бар чакта, укытып калырга кирәк. Тормышым хәзергә менә дигән. Биш елга гына түзәрбез. Ә кызым, укып бетереп, шәһәрдә төпләнеп, шунда кияүгә чыкса, безне дә үз янына алыр, иншалла. Карт көнебездә бер җиңеллек күрергә язгандыр бит инде, — дип сүз кыстырырга ярата торган булды.

Чыннан да, ун сыйныфны бетергәч, Нурия калага китте, тик институтка керә алмады. Акланмады Сәетнең өметләре. Ә менә икенчесе чынга ашты. Бер ел үттеме-юкмы, Нурия, кияүсез калырмын дип курыктымы икән, үзеннән унбиш яшькә өлкән кешегә тормышка чыкты да куйды. Менә монысын бик авыр кичерде Сәет. Түзмәде, шушы хәбәрне ишетү белән, кызы һәм кияве янына барып кайтты. Ни булса да булгандыр, шу-

лай да, кайтканда, күңеле азрак тынычланган иде.

— Кияү әйбәт кенә кешегә охшаган болай... Ничек булыр тагын... Түбә чәче юк инде юклыкка. Мине юаткан була тагын үзе. «Бер генә кыз үстердек, анысы да яныбызда юк, дип кайгырышып ятмагыз. Җае табылыр әле», — ди. Табар да, зур укыган кеше бит. Тик ничек булырын гына ачыклап әйтмәде, ул «җай» кайчан, ничек буладыр, — дип күршесенә сөйләнеп торды.

— Шулай, күрше, тормыш хәлләре бик катлаулы инде. Кыз баланы үстерәсең дә, чит кеше ала да китә. Син бертөрле уйлыйсың, ә ул икенче төрле булып чыга, — дип, күршесенең күңелен тынычландырырга тырышып, сөйләнде Галим.

Тик аның үзен дә аямады тормыш. Ничә ел дөньяны бер төпкә җигелеп тарткан хатыны үлеп киткәч, Себердәге улы янына күчеп китәргә туры килде аңа. Әнә шулай юллары аерылды. Күршесен бик ярата иде Галим, аңа ярдәм итәсе килә иде. Тик үзе дә ярдәмгә мохтаҗ булып калды шул.

...Элекке күршеләр берничә ел гомер узгач, Галим авылга кунакка кайткач кына, очраша алдылар.

Күрешкәч, билгеле инде, бер-берсенең хәлен сорашу китте. Дөньяда ниләр бар, тормышлар элек ничек булган да, хәзер ничек — шул хакта сөйләшеп алдылар. «Картлык — шатлык түгел» дигән тирән мәгънәле сүзләр дә ишетелеп калды. Ялгызлыкның яхшы нәрсә түгеллеге дә телгә алынды. Яшьлекләре искә төште. Сәетнең кызы, кияве турында сүз чыккач, Галимнең хәтеренә күршесенең аңа күп

еллар элек әйткән сүзләре килде. Әңгәмә азагында аның күңелен калдырмаска тырышып, шул хакта сүз башлады.

— Кыз белән кияү һаман калада, дисең инде? Киявең һаман зур укыган кешеме? Яшәргә үз яннарына чакырмыйлармы соң? Алар ни, кала кешесе, авыл турында ишетергә дә теләмиләр инде. Үземнекеләрдән беләм. Аннан, Сәет күрше, синнән шуны сорыйм әле. Исеңдәме, бердәнбер кызың шәһәргә китеп, кияүгә чыккач, бик кайгырган идең. Ә киявең: «Кайгырма, җае табылыр», — дип әйтте дигән идең, хәтерем ялгышмаса. Ничек булып бетте соң, киявең биргән сүзен үтәдеме?

— Хәтерең яхшы икән әле, кордаш, ялгышмыйсың. И-и-и, Галим дус, син сөйлисеңме аны, мин әйтимме. Зур белемле кеше җаен тапмый буламы соң? Таптылар. Кияүнең үзенең генә башы җиттеме икән, әллә кыз белән икәүләп уйлаштылармы, анысы безгә караңгы инде, кордаш. Ә авыр хәлдән тиз чыктылар: дүрт кызларын да, бәләкәй чактан ук, без үстерәбез. Тәпи йөри башлау белән берсе арты икенчесен безгә китереп куя тордылар. Бер генә сәгать тә ялгыз яшәгәнебез юк. Әле менә дәү әниләре белән җиләккә киткән иделәр. Җиңел түгел инде түгеллеккә. Көч бетеп бара, картаябыз. Шулай да, хәзергә сыер асрарга көчебез җитә әле. Балаларга сөт кирәк бит. Ә киявем белән кызым ничек яшиме? Бик яхшы яшиләр, кордаш, хәтта, мин әйтер идем, артыгы белән яхшы бугай. Икесенә дүрт бүлмәле фатир, машина, дачалары бар. Безне дә онытмыйлар, рәхмәт яугырлары. Ел саен кайтып торалар. Кияүнең чәчеме? Бетте, кордаш, бетте, бер бөртеге дә калмады. Соң,

үзең уйлап кара, уен эшмени ул дүрт кызны үстерүе? Үзең дә беләсең инде, Галим, балалар үстермәгән кеше түгелсең.

Башын иеп, аны тыңлап утырган Галим карт, элекке күршесе үзенең кияве, кызы, оныклары турында сөйләп бетергәч, берара эндәшми торды да:

— Һи-и, Сәет кордаш, белмәгән кайда инде ул. Тик синең хәлләр четереклерәк икән шул. Тиз генә ерып чыга торган түгел, — дип әйтеп куйды.

Картлар уйчанланып калды. Икесенең дә уйлары бер тирәдәрәк йөри иде. Берсе балаларны үстереп кеше итүнең җиңел эш түгеллеге хакында баш ватса, икенчесе моның авыр гына түгел, ә катлаулы һәм җаваплы бурыч булуы турында уйланды... Оясында ни күрсә, очканда да шуны кабатлый бит алар, гөнаһ шомлыклары...

## ҺӘРНӘРСӘНЕҢ ТӘРТИБЕ БАР

Көн дә, төшке ашка кайтканда, юл уңае кибеткә сугылып, икмәк-сөт алу минем өскә йөкләтелгән. Моның бер авырлыгын да күрмим, нигә дисәң, гаилә йөген бергә тартсаң гына җиңел була, дип бәләкәйдән үк өеткы салганнар.

Тик иң яманы әлеге дә баягы шул чират инде. Санаулы гына минутлар сизелми дә үтеп тора, төш вакыты да кыскара, ә бит өйдә ашарга әзерләп, капкалап алырга да өлгерергә кирәк. Һәм көн дә шуңа игътибар итәм: чиратның яртысын пенсионер әбиләр тәшкил

итә. Ә үзләре һәрнәрсәгә шикчел карый бит
әле алар. Йә акчасын алдан әзерләп тормый,
янчыгын икмәкне йә сөтне букчасына салгач
кына чыгара, аны ашыкмый гына чутлый, са-
тучыга суза. Тик акчасы һәрчак ким булып
чыга. Сатучы: «Тагын фәлән сум кирәк,
әби», — ди. Ә әби акча янчыгын күптән төйнә-
гән, бик тирәнгә яшереп тә өлгергән була.
Яңадан шул ук күренеш кабатлана. Чиратта
торучы яшьрәкләр шаулаша башлый — алар-
га өенә йөгерергә, аннан-моннан капкалап,
кире эшенә юрттырырга кирәк. Бер әби алып
китә, аннан икенчесе... Һәрберсенә кимендә
бер-ике минут кирәк булганда да, чиратта
утыз-кырык кеше торса, үзегез исәпләп кара-
гыз инде.

— Әби, сез бит көне буе өйдә утырасыз,
кибеткә нәкъ төшке аш вакытында чыкмаса-
гыз булмыймыни соң? Һич югы, ярты сәгатькә
иртәрәк, йә соңрак килсәгез, үзегез дә болай
интекмәс, эшкә йөрүчеләр дә сукранмас иде,—
дип әйтеп карадым берсенә.

— Анда синең эшең булмасын, кайчан те-
лим, шунда чыгам, — дип кенә авызны тома-
лады бу. Шулай да икенчесе, бераз йомшара
төшеп, сер пәрдәсен азрак күтәрә төшүне ки-
рәк тапты:

— Һии, балакаем, һәрнәрсәнең тәртибе
бар, дигәндәй, алай кызыгы буламыни аның?
Кешеләр арасында бераз бәрелеп-сугылып
йөрмәгәч, чиратта этешеп-төртешеп тормагач,
бераз тел чарлап, йә әрләшеп-әйтешеп ал-
магач, кибеткә йөрүнең ни тәме? Гомер буе
шулай өйрәнелгән инде, хәзер бизеп булмый.
Шулай булмаса, яшәүнең бер яме дә калмас
иде безнең өчен. Болай да көне буе дүрт ди-

вар арасында утырасың. Балаларның, кич эштән кайтканда, синең белән сөйләшеп утырырга ни хәле, ни теләге калмый, кайта да, «ахух» итеп урынга егыла, йә «Руза-Мария» карыйм дип, шул тилибизергә кадала. Аннан ашарга әзерли, ирләр гәзиткә ябыша. Әнә шулай гомере үтә инде карт-корының. Ә син, йә иртәрәк, йә соңрак чыгып булмыймы, дисең... Ә үзеңә пенсиягә еракмы соң әле, балам? — дип йөземә карады.

— Ерак әле, ерак, әбекәй!.. — дип, икмәксөт алып, алдан әзерләнгән акчаны түләп, ишеккә юнәлдем.

Чиратта миннән артта торган һәм әле генә соравыма җавап биргән әби, түмен белеп кенә акча янчыгын чишеп калды. Иманым камил, сатучыга сузган акчасы аның, билләһи газим, һәрвакыттагыча, тиешледән ким булып чыгачак.



## ТАЙГАЛАК

Сәгыйть, газ плитәсен төзәтергә дип, слесарь чакырткан иде. Төш алдыннан, сәгать уникеләрдә килмәкче булып, өендә торырга куштылар. Шуңа эшеннән сорады да, тиз-тиз атлап кайтырга чыкты.

Ә урамда, кичә генә яз сулышы сизелеп, тамчы тамып торса да, бүген салкынайтып

җибәргән. Аяк асты бозлавык кына. Сакланыбрак, юлга карап басмасаң, очып барып төшүең дә бар. «Юлны караучы оешмаларын да әйтер идем, ком сибәргә буладыр бит», дип уйлый-уйлый атлады ул. Мондый көнне аяккул сындыру берни тормый.

Шулай дип уйлап та бетермәде, аңардан алда барган, зур гына сумка күтәргән әби, таеп егылып, чалкан барып төште. Каты бәрелде бугай — хәрәкәтсез ята. Берәр нәрсә булдымы икән әллә? Юк ла, әнә, калкынып, торырга тырыша. Тик бозлавыкның нәкъ уртасында булгач, тора алмый азаплана. Мондый көнне карт-корыга өендә генә утырасы да бит... Ярый, аягына үзе басар әле, әби нык күренә. Урамда йөрергә хәле җиткәч, анысын гына булдыра алыр. Йә берәрсе ярдәмләшер. Сәгыйть үзе булышыр иде дә, ашыга шул. Слесарьлары да кәтәргә ярата торган халык түгел. Бер ай буе чакыралар инде — менә чак көтеп алдылар. Сәгать тә беренче киткәндер инде...

Әби яныннан ашыгып үтеп барган Сәгыйть, сәгатенә күз салырга дип, кулын күтәрде. Тик уен тормышка ашырырга да өлгерә алмый калды. Аягы таеп китте дә, «шап!» итеп әби белән янәшә егылды да куйды. Башы бозга бик каты бәрелде, күзләреннән зәңгәр утлар күренде. Җайсызрак та төште бугай, кулы аста калды, кабыргасында нәрсәдер каты итеп чәнчеп алды, хәтта тыны кысылды. Әллә ыңгырашты да инде. Әбинең:

— Әй, балакаем, имгәнмәдеңме? Саграк йөрсәң булмыймыни? — дип әйткәне колагына чалынды. Әби үзе дә һаман аягына баса алмаган, утырып тора.

— Сак йөрү беләнмени? — дип җаваплап мыгырданды Сәгыйть. Аннан сак кына калкынып карады. Күкрәгендә тагын нәрсәдер чәнечте, йөзен чытып куйды. Баш әйләнүе бетсен өчен күзләрен йомды.

— Әй, балакаем, бик каты егылдың, ахры, имгәнмәсәң ярар иде, — дип сөйләнгән әбинең сүзләре аңына барып җитте.

Сәгыйть аның ничек итеп башта дүрт аяклап торуын, аннан картларча, ахылдый-ахылдый, аягына басуын күз кырые белән күреп торды. Үзе дә, башының шаулавына карамастан, саклык белән торып утырды. Әби, келтерәп килеп җитеп, аңа аягына басарга ярдәмләште. Авырткан кулын уып торган Сәгыйтькә:

— Кая, сынмаганмы, кулың бөгеләме, ай, балам, бәла аяк астында, дип картлар белми әйтмәгәндер шул, — дип өтәләнә.

— Юк, ахры, юк. Әйдә, әби, бу тайгалактан чыгыйк әле, йә яңадан егылырбыз, — дип саклык белән, аягын шудырып кына, боз булып каткан тротуардан читкәрәк чыкты. — Мине кызганасың, әби, кая, үзеңнең кулыңа берәр нәрсә булмаганмы соң? — дип сорарга көч тапты. Нигәдер үзен шушы әби каршында гаепле тоя иде ул.

— Юк, юк, балам, борчылма, менә бит кулым йөри, бармаклары да селкенә. Мин акрын баргач, егылуын да сак егылдым. Син генә бик ашыга идең бугай, каты төштең. Авыртамы һаман? — Сәгыйтьнең кулына ымлады.

— Яшь кешегә нәрсә булсын? Сезгә генә чичектер... — Үзе һаман читкә карарга тырышты.

— И-и, балакаем, карт кешенең сөякләре катып беткән инде аның, чуртым булсынмы? Яшьләрнең генә ул сөякләре утырып бетмәгән, бәрелгән-сугылган урын да ныграк сызлый. Безнекен тормыш чыныктырган инде... Бар, улым, үз эшең белән бул, бик ашыгасың, күреп торам. Булышуыңа рәхмәт, инде үзем дә кайтып җитәрмен. Бер авызың пешсә, салкын суны да өреп кабасың аны — акрынрак, абайрак атлармын...

Сәгыйть, һаман әле бар тәнендә авырту тойган килеш, урыныннан кузгалды. Тик әбигә күтәрелеп карарга гына нигәдер кыюлыгы җитмәде. Шулай да әбинең:

— Саграк йөр, балам, тагын да егыла күрмә, — дигән сүзләре артыннан куып җитте...

## ЧИРАТСЫЗ АРАКЫ

Кибеттә чиратта торабыз. Бәйрәм алды булгангамы — кеше күп. Хәтта үтеп-сүтеп йөрүе авыр. Чират акрын кузгала. Бертуктаусыз йөреп торалар: кемдер керә, икенчеләре чыга.

...Ишектә ике кеше күренде. Алдан кергәне — бер аягы протезлы карт, аңа ияргәне — өрлектәй таза егет. Аталы-уллы булырга тиешләр, йөз чалымнары гаҗәеп охшаш. Картның күкрәгендә медальләр чыңлый.

Шушы икәү минем игътибарымны җәлеп итте.

Карт, ишектән керү белән, чиратның башына юнәлде, ә егет читкә барып басты. Кеше күп булганлыктан, карт алга тиз генә үтә алмады. Диварда «Сугыш ветераннары чират-

сыз хезмәтләндерелә» дигән язу торса да, карт ләм-мим сүз эндәшмәгәч, аңа игътибар итүче булмады. Теге егет бу хәлгә бераз вакыт карап торды да, карт янына барып, дорфа гына:

— Әткәй, нәрсә эшләп һаман басып торасың? Сугыш гарибе бит син, дивардагы язу күз буяу өченмени? — дип эндәште.

Шунда башкалар да сугыш ветеранын күреп калды.

— Үт, бабай, үт. Сиңа чиратсыз бит, — дип, читкәрәк тайпылып, кысылышып аңа урын бирделәр.

Карт, нәрсәдәндер уңайсызлангандай, тиз генә сатучыга акча суызды һәм ул биргән шешәләрне сумкасына тутыра башлады. Аннан, агач аягына аксый-аксый, этешә-төртешә чиратны ерып, ишеккә юнәлде. Аны көтеп торган улы, кулыннан сумкасын эләктереп алды да, беренче булып чыгып китте. Әтисе, протезына шак-шок басып, аның артыннан иярде. Медальләре чыңлады. Тик нигәдер миңа аларның көмеш моңы үзгәргән, тоныкланган кебек тоелды.

Йөрәгем әллә нәрсә эшләп китте. Күңелемдә бу картны кызгану хисе кузгалды.

Үзенең нәрсә эшләгәнен һәм улым дип кемне үстергәнен аңлыймы икән ул, дип уйладым. Карт ветеранны куып җитеп: «Әллә дүрт ел буе миллионнар белән бер сафта нәрсә өчен кан койганыңны, нәрсә хакына аягыңны калдырып кайтканыңны, улыңны алдыңа утыртып, бер генә тапкыр да сөйләгәнең булмадымыни, бабай?» — дип сорыйсым килде. Әллә... бары тик шул «нарком йөз граммы» гына хәтерендә калганмы?

## ГАИЛӘ ҚЫЙССАЛАРЫ

### Уртак моң булмаса

Гаилә корганда, кәләш белән кияүгә, икесе дә уйный белмәсә дә, кубыз белән гармун бүләк иттеләр:

— Кем иң беренче уйнарга өйрәнә, шул биетә, — диделәр.

Кәләше тиз арада кубыз чиртә башлады, тик ире, нигәдер, аның көенә биергә теләмәде. Үзе дә шул арада гармунга өйрәнеп алды. Тик кәләше генә аның җырын җырламады.

Аерылыштылар. Ә сәбәбе шул — уртак моң таба алмадылар.

Мәхәббәт дигән көй иде ул.

### Үз арбаңа утырсаң...

Гаилә дигән йөккә җигелгәч, кәләшнең дә, кияүнең дә ата-аналары:

— Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың ул, — дип, ике яктан да балаларына машина бүләк иттеләр.

Тик, нигәдер, ир белән хатын бер-берсенең арбасына утырырга теләмәде, һәрберсе үз арбасын сайлады. Бер-берсенең җырына да кушыла алмадылар, чөнки икесенең дә көе дә, җыры да ике төрле иде. Озак та үтмәде, үз арбасына утырып, үз җырын җырлап, икесе ике якка китте...

Әнә шулай мәхәббәт дигән уртак көй тумады, гаилә дигән йөк юл башында авып калды.

Ә сәбәбен мин шунда күрдем: чыннан да,

алар үзләре эшләп тапкан мал түгел, ә ата-анасы «арбасына» утырган иде шул. Шуңа чит-ят көй көйләүләре дә гаҗәп түгел... Бергә яшәп, бергә эшләп тапкан гына кадерле шул. Гаилә дә, өч таган кебек, нык була...

## ТАБИГЫЙ ТОЙГЫ

Әле генә яңгыр явып үтте. Урамда әле монда, әле тегендә күлләвекләр җыелып калды. Ә бер иңкүрәк урында, бар урамны иңләп, яңгыр суы җыелган. Җиңел аяк киеме белән, чыланмый гына, үтим, димә.

Аптырап карап тора идем, каршыга шундый матур бер кыз килә. Дөресрәге, икәү алар, тик янәшәсендәгесе әллә ни «аһ» итәрлек түгел, шуңа күз теге каһәре — чибәрендә генә. Дөресрәге, аякларында. Җитмәсә, үзе чамасыз тар, үзе чамасыз кыска итәк кигән. Киләләр болар бар дөньяларын онытып, көлешә-көлешә сөйләшеп. Култыклашканнар. Ә кызларның аягында — көяз читек. Кечерәк күлләвекләрне урап узалар. Тик, хәерчегә җил каршы, дигәндәй, алар да бар урамны иңләп яткан күлләвеккә килеп җиттеләр. Ничек чыгарга? Урап узарлык түгел, дидем бит инде. Күлләвекне ерып чыкмый хәлләре юк. Күз һаман теге чамасыз кыска итәкле, озын аяклы кызда. Ә аның миндә кайгысы да юк. Аның уенда — күлләвек аша читеген пычратмый ничек чыгу. Менә кыз... итәген... күтәрә төште дә, сак кына күлләвек аша атлады. Менә кызык! Итәк белән күлләвек арасы — метр ярым чамасы. Монда итәкнең ни кысылышы?!

...Тик шунда кинәт уйлап куйдым: табигый тойгы, эчке сизем (инстинкт) бит бу! Кайчандыр ерак әбиләребез озын, җиргә сөйрәлеп диярлек йөргән күлмәк кигән заманнардан җанның иң яшерен почмагында саклanып калган хатын-кызның табигый тойгысы! Әлек бит әби-апалар, итәкләре суга йә баткакка тиеп чыланмасын, пычранмасын өчен итәкләрен шулай нәзакәтле генә чеметеп тотып, аз гына, читек башлары гына күренерлек итеп күтәреп, ерганакларны аша атлап чыга торган булганнар. Димәк, әле дә хатын-кызларыбызның күңелендә, һич югы, бер почмагында, үзләре дә абайламаган әнә шул эчке сизем сакланган дигән сүз.

Яшәсен табигый тойгы!

## ТИРГӘСЕННӘР, ӘЙДӘ...

Калада гәзиттә эшли башлагач, авылга ял көннәрендә генә кайтып йөрергә туры килә башлады. Кайчак өй яны бакчасында казынган күршем Наил абзыйны очратам. Ул күптән түгел генә пенсиягә чыкты, хуҗалыкта кайнашырга вакыты җитәрлек. Койма аша гына исәнлек-саулык сорашып, бераз сөйләшеп торабыз. Ул эшем белән кызыксына, тәнкыйтьлисез инде, ә, дип сораштыра.

— Тәнкыйтьлибез, шуннан үзебезгә дә эләгә, — дим аңа, көлемсерәп.

— Нәрсә, тәнкыйтьне яратмыйлармы? — дип сорый ул.

— Булгалый, — мин әйтәм.

Ул мине:

— Тиргәсеннәр, әйдә, күрше. Эшләгәндә менә мине дә орышалар иде (ул ике дистә ел нефтьче булып эшләде, ике орден белән бүләкләнде). Хәзер пенсиядә булгач, тиргәүче юк. Тиргәсеннәр, әйдә, — ди ул яңадан, кабатлап. — Пенсиягә чыккач, туктарлар әле, — дип юата. Мин ары атлыйм. Тик аның нәрсә әйтергә теләгәнен хәзер генә төшенә башладым кебек. Татар акылы — төштән соң бит ул...

Күрәсең, аңа күнегелгән эшеннән, ничә ел бергә эшләгән иптәшләреннән аерылу җиңел булмагандыр. «Тиргәсеннәр, әйдә», — дигән сүзе белән күбрәкне аңлатырга теләгәндер. Сагышы шулай тышка бәреп чыккандыр. Тик авыл кешесе хискә бай булса да, сүзгә саран бит ул. Нәрсә әйтергә теләгәнен аңласаң аңлап, аңламасаң аңламый каласың. Мин дә, аның сүзләрен хәзер хәтергә төшерәм дә, уйлыйм. Минем дә яшьрәк берәр танышыма: «Тиргәсеннәр, әйдә», — дип әйтер көннәрем килеп җитәр... Шуңа хаккамы, нахаккамы, орыша башласалар, эчемнән генә үземне тынычландырам:

— Әй, тиргәсеннәр, әйдә...

## ШАЯРТА БИТ УЛ...

Сабитның биш яшьлек улы урамнан акырып елап кайтып керде. Күз төбе күм-күк.

— Нәрсә булды? — дип, аны алдына утыртып, сораштыра башлады әтисе.

— Әнә, Марат... сугыша... уа-уа... Күз төбенә кар белән тондырды... уа...

Икенче көнне Сабит Маратның этисе Кәримне күреп сөйләште:

— Син азрак тыйсаң иде улыңны. Кичә минем малайның күз төбенә кар белән кундырган. Күзе чыкса?

— Әй, Сабит, син дә бала-чага сүзен сөйләп торма инде. Үзең үскәндә ничек үстең соң? Кар бәрешеп уйнамый идеңме? Марат әле нәрсә аңлый? Шаярта бит ул.

* * *

Ике-өч ел үтеп китте. Марат тагын Сабитның улын, велосипедта китеп барган җиреннән, тиктомалга этеп еккан. Тегесенең борын җимерелгән, тубык-терсәкләре сыдырылган, киеме ертылган. Үксеп кайтып кергән. Сабит — сабыр кеше. Шулай да, икенче көнне, Кәримгә әйтми булдыра алмады:

— Син ул шалапаеңны тыясыңмы, юкмы? Әнә, минем малай тагын канга тузып кайткан.

— Харап булган икән, — дип көлемсерәде күршесе. — Күзе чыкмаган, аяк-кулы сынмагандыр бит. Бала-чага арасында ни булмас? Аннан, бик шук инде минем малай. Аны карават аягына бәйләп куеп булмый бит. Шаярткан булган ул, Илдусыңа ялгыш тигән.

* * *

Сигез ел вакыт үтте. Яхшысы ташбака адымы белән килсә дә, яман хәбәр тиз тарала, диләр. Сабит та ишетте: Кәримнең улы

Марат, иптәш егетләре белән, җыелышып, күрше урам малаен тукмаган. Кәримне милициягә чакыртып, теңкәсен корыттылар. Шуңа Сабитка зарланып торды:

— Менә син, әй. Егетләргә бераз шаярып алырга да ярамый. Хәзер төрмәгә утыртырга гына торалар. Ярый, азрак төрткәләп алганнар, ди инде. Шуннан ни булган? Яшьләр бит, үсә торган кешеләр. Көч утыра. Үзара көрмәкләшеп тә алмагач, нинди егет, ди алар...

Теге малайның ата-анасы белән килешкәннәр, ахры, Маратка ул-бу булмады, җил-давыл тимәде. Тирәнгә җибәрмәскә җаен таба белә инде ул Кәрим күршесе.

* * *

Гомеркәйләр аккан су кебек.

Тагын да бер ел үтте.

Ял көнне Сабит күпкатлы йортларының ишек алдына чыгып утырды. Кулына кабы белән тәмәке һәм шырпы тоткан Кәрим дә күренде. Башына йөзне кояштан каплый торган зур козыреклы кипке кигән.

— Син нәрсә, яшьләр сыман, мода артыннан куа башладыңмы әллә? — диде аңа Сабит, көлеп. Тегесе җан ачуы белән:

— Мода, ди әле монда, — дип, шырпы сызып, тәмәке кабызды. Бик күңелле булмаган җавап ишеткәч, Сабит күршесенә игътибар беләнрәк карады. Тегесе, уңайсызланып, читкәрәк, кояш төшмәгәнрәк урынга шуып утырды. Сабит аптырап китте: Кәримнең ике күзе дә кара янып чыккан.

— Нәрсә булды, әллә баскычтан егылдыңмы?

— Баскыч, сиңа. Кичә теге маңка малай эчеп кайткан. Әти кеше буларак, бер-ике ачулы сүз әйткән идем—ул миңа бер-икене «ямады». Вәт, эттән туган нәрсә. Әтисенә кул күтәрә бит. Син аларны тырышып-тырмашып үстерәсең, ә рәхмәт урынына... Тфү! Кайдан өйрәнгән, диген син аны. Үземнең гомеремдә кешегә кул күтәргәнем булмады. Кемгә охшап туган... Милициягә дә хәбәр итеп булмый — үз улым. Күрәләтә яптырасы килми. Нәрсә эшләргә дә белгән юк. Бүген тагын иртән чыгып киткән иде, кайда йөридер... Тагын «ләх» исерек кайтырмы икән инде.

Сабит эндәшмәскә булган иде дә, түзмәде:

— Ә кайтса ни булган, күрше? Нигә аптырыйсың аңа? Хәзерге яшьләрне үзең беләсең — шук бит алар. Синең улың да бәләкәйдән шаян булды. Әле дә шаярткандыр ул. Андый гына шуклыкка түзәсең инде, — диде күршесенең күзләренә туры карарга тырышып. Тегесе, нигәдер, карашын читкә алды...



## САБАНТУЙДА

Тормыш булгач, төрле хәлләр була, дигәндәй, Нәгыймнең яшь кенә килеш хатыны үлеп китеп, берүзе ике бала белән ялгызы

торып калгач, башта аны бик җәлләделәр. Тик кырыгы да узмады, төрле кеше төрлечә өйләнергә димли башлады. Алар үзләренчә хаклы да иде, чөнки берсеннән-берсе кече ике малайны аякка бастырырга кирәк. Ир кешегә хатын-кыз тәрбиясе дә җитми, кием-салымын да яхшылып юа, ашарга да пешеренә беләме ул. Нәгыймгә чыгарга теләүчеләре дә, башкалар димләгәне дә бар. Нигә дисәң, Нәгыйм әле яңа егерме алтысын гына тутырган иде. Ул иртә өйләнде, армиядән кайтуына улы йөгереп йөри иде инде. Аннан кече уллары туды. Тик бергә-бергә үстерергә генә насыйп булмады.

Әйе, Нәгыймгә ике бала өстенә килергә курыкмый риза булган кызлар да юк түгел иде кебек. Ә ул, тотты да, күптән түгел өч малай белән тол калган Мәрьямне алды да куйды. Аның ире, исерек килеш, тракторга утырып, күпердән авып үлде. Аның да, минем дә балалар бар, яшьләре дә шул чама, бер-беребезгә сүз тидерергә урын калмас, дип уй йөрттеме икән Нәгыйм. Кыскасы, аның балалары әниле, ә Мәрьямнекеләр этиле булды. Мәрьям начар хатын түгел, теле дә өтеп бармый, эшкә дә уңган. Шуларын да уйлагандыр инде. Аннан, халык алар кайчандыр яратышып йөргән икән, тик, араларында нидер булып, Нәгыйм армиядә чакта Мәрьям кияүгә чыгып куйган, дип сөйли иде. Ә Нәгыйм, шуңа үч итеп, хезмәтендә вакытында, ялга кайткан җиреннән, өйләнеп киткән икән, диделәр. Ничек булса да булгандыр, алар яхшы торып киттеләр, тату яшәделәр. Балалары да, бәләкәйдән бергә үскәч, этиләре йә әниләре башка дип, исләренә дә алмадылар.

Нәгыйм белән Мәрьямнең тагын да биш уллары булды. Күпме көтеп тә, ник бер кыз тусын. Ел саен диярлек тупылдатып кына торды Мәрьям. «Герой-ана» исеме алды.

Әнә шулай еллар үтә торды. Балалары да бер-бер артлы үсеп җиттеләр. Тик башкалар кебек читкә чыгып китәргә атлыгып бармадылар. Армиядән кайта тордылар, өйләнеп, авылда төпләнә бардылар. Шунысы гаҗәп, егетләр барысы да төптән нык, әтиләре кебек, юан беләкле, таза булып үстеләр. Һәм бер генә сабантуй да аларсыз үтмәс булды. Буынга утыру белән көрәш мәйданына чыга бардылар. Шулай ук башка уеннар да алар катнашлыгыннан тыш үтми иде.

...Менә быел да, кайда гына карама, Мәрьям белән Нәгыймнекеләр. Икесе көрәшә, берсе чүлмәк вата, өченчесе капчык белән сугыша, дүртенчесе колга башына үрмәли... Берсе дә бүләксез калмый. Егетләрнең үзләре генә белгән сере бар. Бүген әтиләренең туган көне, аңа илле яшь тулды. Уллары, алдан сөйләшеп, сабантуйдан бүләксез кайтмаска сүз куештылар. Ә инде соңыннан барысы да бүләкләрен әтиләре алдына китереп салачак. Шуңа һәркем бүләкнең беренчесен эләктерергә чамалый. Һәм тырышлыклары бушка да түгел: әнә, Галимеме, Сәлимеме, колга башына менеп, нәрсәдер алып та төште. Ә иң кечесе, быел сигезенче сыйныфны тутырганы, ат чабышында икенче килде. Нәгыйм үзе ярышларда катнашмый, улларына горурланып та, көлемсерәп тә, читтән генә көч биреп тора. Ә Мәрьям исә, горурланудан бигрәк, егылыпнитеп, имгәнеп куймасыннар, дип борчыла. Ана кеше һәрчак ана шул инде.

Тик иң кызыгы алда көткән икән әле. Ул— аркан тартыш башлангач булды.

Ничек шулай туры килгәндер, арканның бер ягына Мәрьямнең тәүге иреннән һәм Нәгыймнең тәүге хатыныннан туган малайлары, ә икенче ягына соңыннан туган уллары басты. Бу тамашаны күрергә бар халык җыелды. Сокланмаслык та түгел шул — егетләр, иң өлкәненнән алып иң кечесенә кадәр, барысы да өрлек кебек, киң җилкәле, аякларны терәп басканнар, бер якның да бирешергә исәбе юк. Китте шуннан тартыш, көч сынаш. Кешеләр, кычкырышып, көч бирә, киңәш итә, тирә-якта шау-шу, көлешү. Мәрьям белән Нәгыйм дә монда, аркан тартышучыларны урап алган халыкның беренче рәтендә. Алар гына тын да алмый, тавыш-өнсез, бер-берсенә карашып, бу тамашаның ни белән бетәрен кызыксынып күзәтә. Соңгы улларының яше бәләкәйрәк булса да, көчләре бертигез кебек, сынатырга исәпләре юк. Тик шулай да өлкән улларының тәҗрибәләре зуррак идеме, каршы як акрынлап аркылы сызыкка якынлаша башлады. Халык аның саен ныграк шаулады, ике якка да көч биреп торды. Түгәрәк тагын да ныграк кысылды. Тик сызык белән кече уллары арасында ара аз калгач, Мәрьям түзеп тора алмады, ахры, иренә:

— Нәгыйм, Нәгыйм, дим. Кара, кара, минекеләр белән синекеләр безнекеләрне җиңә бит, нәрсә карап торасың?! — дип кычкырып әйтеп куйды.

Бу тартышның ни белән бетәрен көтеп, тынып калган халык дәррәү көлеп җибәрде. Ә Нәгыйм, кече улларына ярдәмгә була, аркан-

га барып тотынганын сизми дә калды. Нигәдер, моңа каршы килүче табылмады.

Дөрес, бу тартыш соңыннан бер якның да җиңмәве белән бетте. Егетләрнең барысына да бүләк бирергә туры килде. Тик халык телендә: «Синекеләр белән минекеләр безнекеләрне җиңә бит!» — дигән кызык сүзе калды. Ә андый шаян сүз бер халык теленә кердеме — онытылмый тәк онытылмый инде ул...

## КОЕ САТУЧЫ

Бу хәлне түтәм сөйләгән иде. Әлеге дә баягы шул авыр сугыш елларын хәтерләп утыра торгач, исенә килеп төште.

— Әй, балакаем, авырлыкларны күрдек инде. Салымнары гына җитмәгән, заем, дип киләләр. Кәнсәләргә чакыртып алалар да, язылмыйча чыгармыйлар. Сатып түләргә малтуар да юк. Анысы ит, тире салымына китә.

Күрше авылда Кави дигән кеше бар иде. Безгә туган тиешлерәк, хәзер мәрхүм инде, авыр туфрагы җиңел булсын. Үзе авыру, шуңа сугышка да алмаганнар. Өй тулы балачага. Бер чакыртканнар моны, ике чакырткannар, өч тә барган. Соңыннан, йомышчыларны күргәч, качып кала башлаган. Шуннан өенә килгәннәр. Күрми калгандыр, ахры, прәме өендә туры китергәннәр. Ялыну, сорау юк анда, ә бары тик «язылasың!» — беттекитте. Кави, акчам юк, дип карый икән. Айваена куймыйлар, ди. «Менә үзегез күреп торасыз, өйнең эче шыр ялангач, балалар ач, үзем авыру, хатыным йөкле». Ә тегеләрнең

берсе наганын алып селти үк башлаган. «Әле син шулаймы, төгән дә фәсмәтән, син Гитлерга ярдәм итәсеңме, хәзер үк төрмәгә алып китәм», — ди икән. Упалнамучаннай булгандыр. Нәрсә эшләсен инде, бахыр. Башын иеп торган-торган да:

— Ярый инде алай булгач, бернәрсә эшләр хәл юк, коены сатарга туры килер. Сез көтеп торыгыз, мин хәзер сатып алучы табып киләм, — дигән дә, чыгып киткән. Тегеләр көтә дә көтә, ди. Бераздан кайсысыдыр аңлап калган:

— Туктагыз әле, ә коены сатып буламы соң?

Шуннан гына алданганнарын төшенгәннәр. Нинди авыр чакта да халык шулай мәзәккә урын таба иде. Шуңа Гитлер мәлгунь җиңә алмады безне, — дип, түтәм сүзен тәмамлады.

— Шуннан арытаба ни булды?

— Белмим, балам. Ни булсын, барыбер заемга язылырга мәҗбүр иткәннәрдер. Заманы шундый иде.

## ҮСЕНТЕЛӘР

Урамда бер малайның үзеннән кече икенче малайны төртеп екканын күреп калдым. Яннарына бардым да, егылган малайга торырга ярдәмләшкәч, зурысыннан сорадым:

— Нигә син үзеңнән бәләкәйләрне кыерсытасың? Алай эшләү начарлык икәнен беләсеңдер бит?

Малай күзләремә куркусыз карады да, мин юатып торган малайга усал күз карашын төшереп алып:

— Ә аның әтисе начар, — дип әйтеп салды.

— Әтисе өчен аны кыерсыталар, диме? Аның ни гаебе бар?

— Ә ул да әтисенә охшаган. Әнием әйтә: «Алма агачыннан ерак төшми ул», — ди.

Мин аңа текләбрәк карадым. Ә ул күзләрен читкә алмады. Туп-туры карап тора.

— Әтисе нинди начарлык эшләде соң?

— Безнең йорт алдында үсеп утырган агачны, машина белән йөрергә комачаулый, дип, кисеп ташлады. Ә ул, — әңгәмәдәшем минем янда шым гына борын тартып басып торган малайга төртеп күрсәтте, — әтисен яклый. Сезнең машинагыз юк, шуңа ачуың килә, ди. Бик исем китте. Үзем агач утыртырга булган идем дә, үсенте генә таба алмадым. Ә ул кайда барын беләм, тик сиңа әйтмим, ди.

Нәрсә дип сүзне дәвам итәргә дә белми, аптырап калдым.

— Башкача бәләкәйләрне кыерсытма, ярыймы? — диюдән уза алмый, аның башыннан сыйпадым да, китәргә урынымнан кузгалдым. Шулай да, начар әтиле малайга, борылып:

— Ә син әйт. Икегез утыртыгыз. Берне генә түгел, ә күп итеп, — дидем.

Алар икесе дә минем арттан карап калдылар.

Юк, шикләнмим: яхшы кешеләр булып үсәрләр алар. Тик теге малайның әтисе агачны кискәндә нәрсә уйлады икән? Үзенең улы барын онытты, аның карап торуын күрмәдеме, әллә бу хакта уйламады да микән?

## АҚ БАБАЙ

Мин Ак бабайны күптән беләм. Аның бер сәер гадәте бар: пыяла ватыклары җыя. Кайда гына күрмәсен, иелеп алырга иренми. Авылдашлар:

— Ак бабай, карт көнендә пыяладан сарай салырга уйлыйсыңмы әллә? — дип шаярта.

Бу сүзләрнең дә үз мәгънәсе бар. Яшь вакытында кулларында балта уйнап торган. Салган йортлары авылыбызны һаман ямьләп утыра.

— Картайгач, бала-чага акылы керә, диләр, шул дөрестер инде, — дип әйтүчеләр дә юк түгел.

Минем өчен Ак бабайның сәер гадәтенең сере уйламаганда ачылды.

Тәндә рәхәт ару тоеп, эштән кайтып барам. Ак бабайлар бакчасы турысына җиткәч, аның үзен дә күрдем. Бик җайсыз тотынып, бакчада нидер эшли. Кулында — көрәк. Чокыр сыман нәрсә казып маташа икән.

— Бир, бабай, үземә, — дип, янына барып, кулыңнан көрәген алдым.

Яшь, нык кешегә нәрсә генә инде — көрәкне җиргә бер-ике батыруга, зур булмаган чокыр әзер булды. Ул кайдандыр иске чиләк алып килде дә, эчендәге пыялаларын шунда түкте.

— Ак бабай, нигә болай үзеңне изалыйсың? Ял итеп кенә ятмый, — дидем, чокырны күмгәч.

Бабай, көлмәссеңме соң, дигәндәй, карап торды да:

— Оныклар бит... Яланаяк рәхәтләнеп чап-

сыннар, дим... Аяклары киселмәсен... Менә минем улларымның, бәләкәй чакларында, гел шулай аяклары җәрәхәтләнеп кайта торган иде. Шул исемә төшә, онык.

Ул бар малайларны да «оныкъ» ди. Ә үзенә оныкларын күрергә насыйп булмаган. Өч улы да Бөек Ватан сугышыннан кайтмаган.

...Тышта — җәй. Ак бабай урамда уйнаган малайларга тәрәзәдән моңсу карап утыра. «Минем улларымның да шулай, көне буе урамда чабып, табаннары ярылып бетә иде. Хәзер бигрәк тә — тимер-томыр, пыяла аяк асты тулы», — дип уйлый ул һәм яшьләнгән күзләрен дивардагы ике фотосурәткә күчерә. Өченчесе сугышка бик яшьли китте шул, карточкага төшәргә дә өлгермәде. Тик оныта буламы соң хәтер?

Ул тагын карашын тәрәзәгә күчерә. Ә балалар йөгерә, уйный.

...Әйе, оныклары күп аның. Уйнап-көлеп кенә үссеннәр, рәхәтләнеп җылы җир өстеннән атласыннар. Тиздән үсеп, аның уллары саклап калган илнең чын хуҗалары булырлар.

Ак бабайларын да хәтергә төшереп, рәхмәт хисе белән искә алырлар.

## ЗӘҢГӘР ЧӘЧӘКЛӘР

Бүлмәмә килеп керү белән туктап калдым. Өстәлдә — кем тарафыннандыр калдырылган зәңгәр чәчәкләр. Өстәл янына килеп, аларны кулыма алам. Хуш исен сулыйм. Күз алдымда дустым гәүдәләнә.

Ул ярата иде бит зәңгәр чәчәкләрне.

— Чәчәкләр — тормышның бер бизәге. Ничек яратмассың аларны! — ди торган иде.

Әйе, тормышны ярата иде ул.

Тик гомере кыска булды. Күктә атылган йолдыз шикелле... Шушы чәчәкләрдәй...

Бүгенгедәй хәтерлим әле мин ул иртәне. Килеп әйттеләр: дустың самолетта фаҗигале һәлак булган. Йөрәгем өзелеп төшкән кебек булды. Ышанмадым. Ничек?! Шулай ук аны башка күрә алмам микәнни?! Моңа күңелем ышанырга теләмәде.

Аерылмас дуслар идек без аның белән. Бәләкәйдән бергә уйнап үстек. Ун ел буе бер партада утырып укыдык. Икебез бергә аэроклубка язылдык. Тәүге очу. Уртак шатлыклар. Өченче ел гына иде бит әле синең беренче тапкыр үзаллы күккә күтәрелүең! Зәңгәр күккә гашыйк идең. Ансыз яши алмый идең. Шуңадыр, ахры, син җәен көн дә бүлмәгә зәңгәр чәчәкләр алып кайта идең.

— Бүлмәмдә зәңгәр төс булмаса, күңелем тарлыга башлый, — дигән сүзләрең әле һаман колагымда чыңлагандай.

* * *

Мин зәңгәр чәчәкләрне дустым мирас итеп калдырган кадерле истәлек кебек күрәм. Шул чәчәкләргә карасам, гүя, алар дустым булып миңа:

— Минем өчен дә оч, дустым! Минем өчен дә ярат чәчкәләрне! Күкне ярат, минем кебек ярат! Күңелеңне төшермә, исеңдә тот — тормыш бу. Аның сикәлтәләре дә, чокыр-чакыр-

лары да, куркыныч упкыннары да булуы мөмкин! — дип әйтәләр кебек.

Тыныч бул, дустым! Синең исемеңә, синең эшеңә мин беркайчан да, бервакытта да тап төшермәм!

...Күккә карыйм: ул шундый чиста, шундый биек. О, зәңгәр күк! Кемнәр генә сине мактап шигырь язмаган, җыр чыгармаган. Нинди матур син! Тик кайчакта нигә рәхимсез буласың соң?!

Ә сез, зәңгәр чәчәкләр? Сез дә шул зәңгәр күкнең бер өлеше түгелме? Сезгә аның төсе сеңгән. Сез кешеләргә матурлык өләшәсез, аларны илһамландырасыз, көч бирәсез. Сез бит гүзәл яшь кызның зәңгәр күзләре кебек нәфислек, сафлык чәчәсез. Сез кешеләрне тормышны яратырга, матур яшәргә өйрәтәсез. Күпләр сезнең телне аңламый икән, аларга ачуланмагыз. Димәк, вакыты килеп җитмәгән...

Их, гүзәл чәчәкләр! Зәңгәр чәчәкләр...

## ИСБАТ ИТТЕ

...Ул җитәкчеләргә үзенең төгәллелеген, алар әйткән һәр сүзне яки теләкне «Баш өсте!» дип үтәргә әзер икәнлеген күрсәтергә ярата иде. Ә бит үзе начар кеше дә түгел, тик холкы гына йомшак. Үзеннән вазифасы югарырак булган кешеләр алдында, алар нәрсә әйтсә, шуны үтәргә әзер икәнлеген күрсәтергә форсат эзләр булды.

Шулай бервакыт үзенең турыдан-туры җитәкчесе, аның хакында, әллә чын, әллә шаяртып:

— Аңа ышанмагыз, үзен берәр күрсәтер әле ул, — диде.

Аның күзеннән йокы качты. Төннәрен йокламый, уйланып ятар булды. Һәм, чыннан да, тиздән, барысын да аптырашта калдырган бер эше фаш ителде.

Ә җитәкчесенең:

— Менә бит, мин нәрсә дигән идем! Дөрескә чыкты түгелме? — дип әйткән сүзләре аңа иң югары мактау сүзләре булып яңгырады.

Анардан барысы да читкә тайпылды, дуслары ташлады, хәтта гаиләсендә тынычлык бетте, балалары йөз чөерде.

Тик ул артык борчылмады. Чөнки җитәкчесенең, чыннан да, сизгер акыллы, үзенә буйсынган кешеләрне үтәдән-үтә күрә белүче икәнлегенә тагын бер тапкыр ышандыра алды бит...



# Ялангач дивар заманы



## ТЕЛСЕЗ ГАРМУН ЗАРЫ

Элек кая гына бармасын, Хәнифкә: «Гармуныңны калдырма!» — дип әйтә торганнар иде. Аның гармуны — мин булам инде. Әйе, бар иде яшь чаклар, күрек тулы көй чаклар. Хәниф минем телләремә басуы була — барысы да хәйран кала торган иде. Ә менә хәзер телсез утырам. Мәхәббәт харап итте мине, мәхәббәт!

Шулай берчак Хәниф гашыйк булды. Шул ут бөрчәсе Фәниягә инде. Хәниф армиягә киткәндә чибек кенә бер кыз иде, ә өч ел эчендә кай арада үсеп, яңа пешкән җиләк кебек булып киткән. Ә ул сылулыгы, чибәрлеге!.. Артыннан күп егетләр йөреп карады, тик берсен дә якын китермәде. Кемне көтәдер...

Хәниф тә, кайткач, аны бер генә күрде — бөгелде дә төште. Ә үзе өч ел диңгездә йөзгән егет бит әле. Хәтерем калды. Аның элек бар белгәне гармун, ягъни, мәсәлән, мин идем. Тузан кундыру түгел, өрмәгән җиргә дә куймый иде. Ә хәзер Фәния дә Фәния. Нәрсәләр генә сөйләп бетермәде ул миңа үзенең шул почык борынга булган сөюе турында. Имеш, бары тик аны гына ярата, ул иң чибәре, иң

уңганы, андый кыз дөньяда юк. Фәниядән башка берсен дә сөйми, берсе дә кирәкми...

Ачуым килеп, ямьсез итеп кычкырырга чамалыйм, тик Хәниф оста гармунчы шул, телләремә бер-ике генә баса — йөрәк өзгеч сагышлы көй уйнап алам да китәм. Шуннан мине бар көченә тартып җибәрә дә, китә урам буйлап җырлап. Ул кайтканнан бирле: «Кемне ярата икән шушы Хәниф? Әллә... минеме?» — дип, авылның бар яшь кызлары төннәрен йокысыз уздыра, дип әйтсәм дә, ялган булмас.

«Тамчы тама-тама таш яра», диләр, дөрестер ул. Хәниф гел теленнән төшерми сөйли торгач, шул Фәния миңа да якын булып китте. Аны күрсәм, көемне матуррак, моңлырак итеп чыгарасым килә дә тора. Ә Хәнифне әйткән дә юк: бармаклары да җитезрәк йөри башлый, йөзе дә яктырып китә, тик теленә генә әллә нәрсә була да куя. Бер авыз сүз эндәшә алмый. Шуңа да ул әйтә алмаган сүзләрне мин телләрем белән аңлатырга тырышам. Чыннан да, минем тавышны ишетү белән үк Фәниянең йөзе балкып киткәнен сизә башладым. Юкәдә икән, болай булгач, чикләвек! Мин аның саен матуррак уйныйм. «Хәниф сине ярата бит, Фәния, нигә күрмисең?» — дип тора бар булмышым. Аңламый буламы соң кыз йөрәге, аңлый ул минем сүзләремне — йөзендә кояштай елмаю чагыла, бит очлары алсуланып, үзе тагын да чибәрләнеп китә. Әмма көннәр үтә тора, ә Хәниф һаман сөю сүзләрен күңелендә саклый. Ничек ярдәм итәргә икән шуларга?

Ләкин борчылуларым юкка булган. Хәлләр

көтмәгәндә ачыкланды да куйды. Тик мин генә телсез калдым.

...Икесе дә авылның бер очында яшиләр алар. Беркөнне мине уйнатып, урамны ун кат әйләнгәннән соң, башкалар таралышып бетеп, икесе генә калгач, Хәниф:

— Җитеп торыр, гармунның телләре талды, — дигән булып, мине култык астына кыстырып алды. Кара, кара, үзенең бармаклары талганын миңем телләргә сылтый түгелме соң бу?! Тик Хәниф мине нык итеп кыскан иде шул, берни дә әйтә алмадым...

Кайталар болар шулай сүзсез генә. «Их, пешмәгән!»—дип, Хәнифне әрләп киләм. Нинди тылсымы бар икән бу Фәниянең?! Аның белән бергә калса, авызына су уртлагандай, телсез була да куя бит. Сизеп торам, югыйсә, Фәния аның сүз башлаганын гына көтә. Юк, шуны күрми.

Әнә шулай егетне әрләп килә торгач, Фәнияләр капка төбенә килеп җиткәнбез. Торалар шунда юкны-барны сөйләшеп. Дөресрәге, Фәния сорый, ә тегесе: «Әйе», «юк»; «Дингезме? Ул ни... зур ул, юк, куркыныч түгел» дигән кебек сүзләр белән җавап бирә. Соң, кызлар белән шулай сөйләшәләрме? Фәниясе йә керәм, йә кайт, дими. «Төн салкынча бүген»,— ди. Юк, Хәниф аңламый. «Их, ужым бозавы!» — дип әрлим эчемнән. Шунда Хәниф:

— Фәния! Мин сине яратам, — дип әйтеп куймасынмы. Ә үзе читкә караган. Вәт, пешмәгән! Ул да булмады, Фәния аңа таба бер адым атлады да, упкынга ташлангандай, Хәнифнең куенына атылды да куйды. Кара, кара, маладис икән дә ул Хәниф — кызны кочаклап алды түгелме соң?! Шуны уйлап та

бетермәдем, аның култык астыннан ычкынып, «дыңк» итеп җиргә очып төштем. Фәниянең:

— Их, Хәнифкәем! Мин дә сине яратам. Тик нигә бигрәк кыюсыз син, күпме көтеп йөрдем шушы сүзләреңне, — дигәнен ишетеп, телсез калдым. Шуннан тындылар. Нәрсә эшлиләр икән дип, күз салсам — әллә үбешеп торалар инде?! «Эһем, эһем!» — дип, тамак кырып куйсам да, миндәмени аларның кайгысы.

...Юк, Хәниф мине онытмаган икән, күтәреп алды да:

— Их, Фәниякәем, матурым минем! Белсәң иде, мин нинди бәхетле! — дип, уйнамакчы булып, күрекләремне сузды. Тик көй урынына ямьсез гырылдау гына чыкты...

— Нәрсә булган бу гармунга? — дип, Хәниф мине бер-ике тартып, аннан-моннан әйләндереп карады да, онытты. Аларның аңлашу бәхетеннән телемнән язганны кайдан белсен ул. Хәер, минем кайгы идемени яшьләрдә? Иң бәхетле көне бүген аларның.

...Әнә шул көннән башлап ятам инде өйдә. Хәнифкә аңа нәрсә, яңа гармун алып җибәрде. Шуны уйната. Минем хакта уйламый да торгандыр, ахры. Тиздән туйлары була икән — аларның шул хакта сөйләшкәнен ишетеп калдым. Шунда Фәниянең сүзләре колагыма кереп, хәтта тын алудан туктадым.

— Хәниф, бу гармунның нигәдер тегесе кебек моңлы түгел әле. Әллә туебызга искесен төзәтеп аласыңмы? — диде ул.

— Үзем дә шуны чамалап тора идем әле. Син дә андый уйда булгач, төзәтәбез аны, нигә төзәтмәскә! — Хәнифнең шулай дигәнен ишетеп, сөенүемнең чиге булмады. Юкка бор-

чылганмын, уйныйсы көннәр алда икән әле. Ну, биетәм туйда болай булгач! Шәп чакларны искә төшереп, бер җилкенеп алу кемгә дә ярый торган эштер инде ул.

## ДӨНЬЯ — КУЛАСА

Каладан авылга ялга кайтып барыш. Артымнан куып җитеп, тузан болыты күтәреп узган машина кинәт шып туктады. Яңак сөякләре калкып торган, йөзен сакал-мыек баскан шофер, кабина тәрәзәсеннән үрелеп:

— Гыймран энем, син түгелме соң? Әйдә, утыр! — диде.

Мин кереп утырдым. Кузгалып киткәч:

— Ялга кайтам, дисең инде? Тәмәкең юкмы? Кала күчтәнәче белән сыйлап җибәр әле, үземнеке бетеп киткән, — дип, тартырга сорап алды.

Тавышы да, йөзе дә таныш кебек үзенең. Сак кына сорарга булдым:

— Таный алмый торам. Сез кем буласыз соң әле?

— Их, энем, энем! Танымасаң да, ачуланмыйм. Дөнья үзгәртә икән ул. Ферма мөдире Фатыйх абыең булам мин...

Гаҗәпләнеп, аның кайчаннан бирле машинада эшләвен сорадым.

— Байтак булды инде, энем. Гөлгенә колхоздан киткәннән бирле... — Ул, шулай диде дә, туктап калды. Мин шунда барысын да хәтеремә төшердем.

...Безнең колхозның гына түгел, бөтен тирә-якның беренче чибәре ул Гөлгенә. Йөзе —

айдай, буй-сыны — зифа талдай, дигәндәй. Нәкъ китапларда язганча инде: үзе сылу, үзе уңган. Барлык кичәләрдә, яшьләр уенында башлап йөрүче дә ул. Гөлгенә дип уфтанмаган егет бар идеме икән тирә-якта?! Фермада савучы булып эшли иде ул. Ике ел эчендә өчмеңчеләр сафына чыкты. Колхозда гына түгел, исеме районга таралды.

Гөлгенә дип күп егетләрнең йөрәге яна иде. Мин дә шуларның берсе инде. Һәм, минемчә, өметләрем бушка да түгел кебек. Нигә, төс-баш бар, колхозның алдынгы шоферы, машинам һәрчак төзек, Гөлгенә сауган чиләк-чиләк сөтләрне, әчетми-нитми генә май заводына алып барып җиткерәм. Өстәвенә, бер дигән гармунчы үзем. Беркөнне тоттым да, Гөлгенәгә йөрәгемне ачып салдым.

— Гөлгенәм, бергенәм, — дидем, — мин сине яратам, синсез яши алмыйм, янган шәм кебек сүнәм, теләсәң ни эшлә, дәвасын тап, — дидем.

Ә Гөлгенә:

— Их, Гыймран, — диде. — Синең кайгы — кайгымыни ул, менә миндәге кайгы — кайгы, ичмасам. Ничек кенә дүртмеңчеләр сафына чыгыйм икән? Ферма мөдире, Фатыйх агай, явыз, аяк чала бит. Ә шул үргә чыкмый торып, сөю, мәхәббәт дигән нәрсә ике ятып бер төшемә кермәячәк.

Чынлап та, бу вакытта Гөлгенә белән ферма мөдире арасында бик зур тарткалаш туган иде. Ничә кат әйтте Гөлгенә Фатыйх агайга:

— Абзар түбәсен яңадан яптырырга кирәк, су үтә. Азык цехының җиһазларын алыштырырга, тирес түккечләрне төзәтергә, машина белән саву корылмаларын урнаштырырга ки-

рәк, — диде. Җиһазлар булмаса бер хәл иде, ә алар складта тутыгып ята. Юк, үгез кебек киреләнеп, аяк терәп катты бит мөдир.

— Булыр, булыр, Гөлгенә кызым, көтә белергә кирәк. Алардан башка кичектергесез эшләр дә баштан ашкан, — ди дә, оныта.

— Үкенерсең, Фатыйх агай, тик соң булыр, — дип куркытып та карады Гөлгенә. Кулын гына селтәп куйды ферма мөдире. «Кайчан әле чебен дулап тәрәзә ватканы бар?» — дип уйлый торгандыр инде эченнән генә.

Ә Гөлгенә... Гөлгенә көннәрдән беркөнне калага китте. Авылда яшәүнең яме калмады. Гөлгенә артыннан мин дә читкә чыгып киттем. Бер мин генә түгел икән авылның ямен югалткан. Фатыйх агайдан шуны белдем: тирә-як авыллардан тагын байтак егетләр: «Хәзер, Гөлгенә булмагач, ни эшнең, ни авылның кызыгы юк», — дип шәһәргә киткәннәр. Эш моның белән генә дә бетмәгән — алар артыннан колхозның кызлары да: «Егетләр булмагач, безгә авылда ни кала?» — дип, кайсы кайда таралышып беткән.

— Ә егетләр киткәч, — дип дәвам итте сүзен Фатыйх агай, — машинада, тракторда эшләргә кеше калмады. Кызлар булмагач, колхоз сыерларын саварга савучы юк. Гомер буе «өф» итеп кенә торган җиңгәңне дә фермага җибәрергә туры килде. Ә рәис: «Ферманы гына түгел, колхозны да тараттың, хет бишкә ярыл, тик юлын тап, эшне алып бар», — дип, бик каты кисәтте. Эшләр менә шулай катлауланып китте әле, энем. Ферманы да җитәклим, үзем машина белән сөт ташыйм. Син сакал-мыекка аптырама, кырынырга вакыт юк.

Ә җиңгәңнең җылы түшәген күрмәгәнгә бүген егерме бишенче көн.

Шунда аның күзеннән, тузанлы йөзендә эз калдырып, ике бөртек яше тамды. Аннан өмет белән миңа карады да:

— Энем, син намуслы гына егет күренәсең. Шуңа күрә, ышанып, сиңа гозеремне җиткерәм: Гөлгенәне эзләп тап та, әйт. Фатыйх абыең сине, кайтсын, дип, тезләнеп үтенә, диген. Машина белән саву җиһазларын, каладан кешеләр чакыртып, өч көн эчендә куйдырган, дип тә өстә. Абзарлар төзекләндерелгән, азык цехы гөрләп эшли, тирес түгү дә көйләнгән, сөт күп, тик савучы гына юк икән, диген. Аннан синең машина да тик утыра бит әле, энем. Әллә, дим... Кайтыгыз бергәләп. Аннан, бәлки бүтәннәр дә кайтыр...

Кайтып җиткәч, аны тынычландырып, төшеп калдым. Ул машинасын туктатып та тормыйча:

— Энем, мин әйткәнне үтәсәң, мәңге онытмам, — дип кычкырды да, китеп барды.

Берничә атнадан мин аның гозерен үтәдем — Гөлгенәне култыклап кайтып төштем. Хәзер ул сыерлар сава, ә мин шул май заводына сөт ташыйм. Башка яшьләр дә берәмсәрәм кире кайта. Бездә хәзер элеккедәй күңелле. Тиздән Гөлгенә белән туебыз булачак (тәки дүрт мең үренә чыкты бит!). Туебызга рәхим итегез. Безнең якларны да күреп китәрсез.



## ҚАРА ТАВЫК ЙОМЫРКАСЫ

Яратмый башлады үзенең күршесен Хәким. Аны күрсә, җене кузгала. Ә бит уйламаган-нитмәгәннән генә купты бу яшерен дошманлык. Берничә тавык йомыркасыннан.

Җәй көне, йорт-кура тирәсендә йөргәндә, Хәким ике ихатаны бүлеп торган койма буендагы кычыткан арасыннан ун йомырка табып алды. Аларны кәләпүшенә тутырганын күршесе Сәлим күреп калган икән.

— Ару гынамы, күрше? Байлык тапкансың түгелме соң? — дип авыз ерып тора.

— Байлык ни, күрше, аяк астында ята инде ул. Иелеп алырга иренмә генә, — диде Хәким.

Сәлим аны шаяртырга теләпме:

— Кичә шул тирәдә безнең ике тавык йөри иде, синекеләр күренмәде бер дә, — дигән булды.

Әйтмәсә яхшы буласы икән. Хәким ачуланды да китте.

— Нәрсә, әллә син мине... теге, кем дип, исәплисеңме?

— Тукта әле, күрше, кызма. Мин бит шаярып кына әйттем. Андый байлык ни, үзебездә дә җитәрлек. Әнә, келәттә зур кәрзин тулы. Кирәк булса, кереп ал, барыбер кайда куярга белгән юк.

Күршесе Сәлимнең киң күңелле булырга тырышуы Хәкимнең бәгыренә агулы ук булып кадалды.

...Сәлим бу йомырка сарысыдай кечтик кенә вакыйганы күптән онытты, ә менә Хәким... Онытырга теләсә, булдыра алыр иде, тик теләмәде.

Күршесенә аяк чалыр өчен Хәким юк кына нәрсәне дә сылтау итәр булып китте. Халык белми әйтмәс, дип, күршесенең берәр җиргә барырга җыенганын күрсә, тиз генә хатынын, буш чиләк көянтәләтеп, аңа каршы җибәрде. Тик файдасы гына булмады. Киресенчә, күршесенең буш чиләкләренә очрап, почтага барган Сәлим лотереягә машина отты.

Буш бидрәләр ярдәм итмәгәч, кара мәче алды. Рәхмәт яугыры, анысы гел Сәлимнең өе тирәсендә урала. Тегеләрдән берәрсе күрендеме — «ялт», юлларын аркылы кисеп чыга да китә.

Тик бер уңышсыз этлектән соң гына Хәкимнең кара әрәмтамакны куып чыгарудан башка чарасы калмады.

Күршесе машина откannан соң Хәким дә машина алган иде. Беркөнне район үзәгенә җыенды. Күршесе Сәлим дә гаражы янында чуала. Хәкимне күргәч, ерактан ук елмаеп сәлам бирде, аннан, килеп, хәл-әхвәл сорашты. Ә бу вакытта кара мәче хуҗасының аяк арасында урала иде.

Сәлим дә район үзәгенә җыенган икән.

— Әллә син дә шул яккамы? Әйдә, бергә барабыз, минекенең нәрсәседер килешми әле. Юлда ватылып китсәм, сөйрәтеп кайтырсың,— дип тора.

Тик Хәким, соңрак бармакчымын, дип, ризалашмады. Сәлим машинасы янына юнәлүгә, кара песи дә аның артыннан китте. Хәким, моны күреп, мыек астыннан көлеп куйды...

Бер булмаса, булмый икән ул, егетләр. Хәким, район үзәгенә баргач, урам чатында бер йөк машинасы белән ничек бәрелешкәнен сизми дә калды. Нык кына яньчелде, каһәрең.

Ярый эле, Сәлим очрап, сөйрәтеп алып кайтты. Менә шунда Хәким ярты картайды инде. Гаражы яныннан кузгалып киткәндә машинасы алдыннан үтеп киткән кара мәчесен хәтеренә төшерде. Өенә кайту белән аны урамга чыгарып ташлады.

Башына ят уйлар да килеп куйгалый хәзер. Нигә аңа гына шулай кире соң әле бу тормыш? Әллә бар каргышы үзенә төшәме соң? Хәтеренә теге йомыркалар килде. Тфү! Нәрсәдән башланды бит. Әллә барсына да үзе гаепләме икән?

...Җәй җитте. Хәким машинасы янына теге вакыттан соң чыкканы юк иде, шуны төзәтеп яткан көне. Тик нигәдер эше ырамый. Сәлимне чакырыр иде — кыен... Шуны уйлап та бетермәде, ялгыш бармагына чүкеч белән сугып алды да, аны ачу белән койма буена, кычыткан арасына атып бәрде. Аннан, кыткытаклап, бер тавык очып чыкты.

Шуны гына көткән, диярсең, күрше өйнең тәрәзәсе ачылып китте. Аннан, елмаеп, Сәлим карап тора иде.

— Ару гынамы, күрше? Һаман шул кара тавыгың кычыткан арасына саламы?

— Гөнаһын үз өстемә ала алмыйм, күрше, кем тавыгыдыр — күрми калдым. Сезнеке бугай ул, әнә бит, өй алдыгызда берсе сөрән сала, — диде Хәким, ояны тикшергәннән соң.

— Ташла әле шул йомыркаларыңны! Әйдә, кер әле, күрше, кер. Самавыр да кайнаган, утырып бер чәй эчик, күптән сөйләшеп утырган юк. Ә машинаң өчен кайгырма, икәүләп хәзер төзәтәбез дә куябыз аны.

— Һе... Ашау — эш калдырмый, дисең инде. Ярый, алай булгач. Хәзер кулны гына чай-

кап алам да... — дип, Хәким коймага кагып куелган юынгыч янына юнәлде.

## «ЭКСТРА» СЕАНС

Парикмахер, ягъни безнеңчә чәчтараш Мәмәт базар шартларында яшәү үрнәкләрен үз җилкәсендә шактый өйрәнеп-күзәтеп йөри торгач, ниһаять, бер карарга килде. Нигә, ул башкалардан киммени? Аңа да бер-бер кәсепкә тотынырга кирәк. Тик менә нәрсә белән шөгыльләнергә соң әле? Товар җитештерергә кулыннан килмәс, алыпсатарлыкка тотынырга да йөрәге җитми. Әгәр дә медицинаны сайлаганда? Операцияләр ясарга ук тотынмаса да, төрле чирләрне дәваларга алынырга булыр иде. Мәсәлән, алкашларны. Үзләре эчүләрен ташларга теләмәсәләр дә, аларны ташлатырга теләүчеләр буа буарлык бит. Хатыннарын гына алыйк. Аларның кайбер юләре ирен бу чирдән йолып алу өчен актык акчасын чыгарып бирергә дә риза. Артыгын да сорамас иде Мәмәт. Аңа кешечә яшәү өчен күп тә кирәкми — аена биш-ун миллион җитәр иде.

Эшне озакка сузмады Мәмәт. Шактый акча түләп, бер айлык курсларда укып, «халыкара экстрасенс» дигән исем алып чыкты. Таныклыгын да бик матур итеп язып бирделәр. Ә «уку» өчен киткән акчаны ул бер сеанста кертәчәк.

Арытаба нәрсә эшләргә кирәклеген дә яхшы үзләштерде Мәмәт. Телевизор карый да ул. Реклама — менә нәрсә иң мөһиме. Тексты

күптән әзер инде аның: «Әл-көһел чиреннән бер көн эчендә котылдыру — бары тик халыкара экстрасенс Лин Фул Гарри үзәгендә генә!». Аннан, бераз икеләнеп утырганнан соң, «бер көн» дигән сүзне сызып ташлады да, «бер сәгать» дип төзәтте. Гомерен чиратларда уздырган, бер минутлык йомыш өчен берәр көн вакыт сарыф итеп иза чиккән халыкка бу «бер сәгать» дигән сүзнең ничек тәэсир итәчәген белә шул Мәмәт. «Лин Фул Гарри» дигәне нәрсә була инде тагын дип, һич аптырамагыз. Мәмәтнең фамилиясе Гарифуллин — бары шул гына. «Гарри» дигән исемнең дә тылсым көче аңлашыладыр. Чит илдән китерелгән дисәң, урам уртасындагы пычракны йөзе белән сөзәргә әзер торган кешеләргә җитә кала ул.

Рекламасы гәзиттә әллә басылып чыгып өлгерде, әллә юк, төшке аш вакытында бер ирне хатыны җилтерәтеп китереп тә җиткергән. «Ашыгам, кибеттә чиратым җитә, тизрәк булмасмы икән?» — дип ялына үзе, ике йөз илле мең сум акча сузып.

Клиентны күргәч, Мәмәт баш чайкамый булдыра алмады. Чире азынганы йөзенә чыккан: калтырап-чәчрәп тора, битен-йөзен куе сакал-мыек баскан. Күзләрендә бер нур юк, алар төпкә баткан — менә-менә, орбитасыннан ычкынып, ашказанына төшеп китәр төсле. Кәчтүм-чалбарын салмый, әллә бер ай буе җирдә аунаган инде — гармун күреге тәк гармун күреге.

Ирен алып килгән хатынкай бик омтылса да, Мәмәт бүлмәсенә авыруның үзен генә чакырды. Өендә «игәве» җитмәгән, монда да өйрәтеп торыр иде бугай.

Анысын-монысын сораштыра-сораштыра, авыруның костюмы белән чалбарын салдырып, ярдәмчесе булып эшләгән кызга тоттырды. Анысы күрше бүлмәгә чыгып юк булды. Мәмәт сырхауны кәнәфигә утыртты, түшенә ак япма япты, кирәк-ярагын, үткен пәкесен чыгарды. Авыру нәрсәдер әйтергә теләп, авызын ачкан иде, аны:

— Сеанс вакытында сөйләшү катгый тыела! — дип шып туктатып куйды.

Аннан процедура бүлмәсенә чыгып, кырлы стакан мөлдерәмә тулганчы, «Экстра» дип язылган ярты литрлы шешәдән ниндидер төссез сыекча агызды. Авыру янына чыкты.

— Тамчысын да калдырмыйча эчеп бетер! — дип боерды.

Пациент калтыраган куллары белән стакага ябышты, тик, чайпалдырып, өстенә түкте. Мәмәт ярдәмгә килеп житмәсә, стаканны идәнгә төшереп вата иде.

Авыру башта, карышып, азрак уртлап кына карады. Арытаба инде, кире тартып алмасыннар, дигәндәй, «голт-голт» итеп йотарга тотынды. Стакан бушагач, хәлсез күзләре белән өстәл өстен капшады. Мәмәт аны яхшы аңлады. Иснәргә икмәк катысы эзләве инде, бичараның.

— Минем ысулда беренче сеанстан соң капкалап алу каралмаган, — дип Мәмәт кырт кискәч, жиңен иснәп канәгатьләнүдән башка чарасы калмады.

Инде Мәмәт сабынланган пумаласы белән үткен пәкесенә тотынды. Авыру, суйсаң, суй инде, дигәндәй, барысына да риза булып, битараф төстә күзләрен йомды...

Гомер буе сакал-мыек кыруда күзе чык-

кан Мәмәткә бу эш ике минутка да җитмәде. Хушбуйлар сибеп җибәргәч, иркәйгә кеше төсе кереп, йөзләре алсуланып китте. «Дару» да килеште, ахры. Ярдәмчесе кәчтүм-чалбарын да чистартып, үтүкләп җитештерде.

Үзенең ирен ишектә күргәч, мескен хатын аны башта танымый торды, ахры. Ә таныгач инде, артына авып китте. Ярый Мәмәт урындык куеп өлгерде. Әле ярты сәгать кенә доктор янына карачкы кертеп җибәреп, инде хәзер алсу йөзле, кырынган, чалбары-күлмәге үтүкләнгән, елмаеп торган иреңне кабул итеп алсаң, син дә егылырсың.

— Ә хәзер авыруга кайнар аш ашатырга кирәк һәм мөмкин кадәр тизрәк. Югыйсә... — диде Мәмәт инде монысында аның аягына егылган хатынга.

...Әнә шулай Мәмәткә дан килде. Исеме бар илгә таралды. Хәзер клиентлардан котылыр хәл юк — эш хутта. Чит ил машинасында гына йөри, ун бүлмәле йорт салды. Ә авырулармы? Тереләләрме соң, дип сорыйсыздыр инде. Әллә тагын, шайтаным белсен. Бәлки, тереләләрдер дә. Иң мөһиме — Мәмәт биргән вәгъдәсен һич тайпылышсыз үти. Кайчак «экстра» сеанслар бер сәгатькә дә сузылмый әле. Пациентлары чөгендер төсле кып-кызыл булып, терелеп чыгып китәләр. Икенчедән, аның ысулында алай бернинди дә хәрби сер юк шикелле. Теләге булган хатын-кыз шундыйрак юл белән ирен өендә дә дәвалый ала. Ә теләге юк икән — аңысына инде бер Алла хөкемдар. Калганында Мәмәтнең эше юк. Аракы күрдем, дип, эчә белми эчкәннәр бетмәсә — Лин Фул Гаррига да эш бетмәс.

Җәмәгать, тагын сорауларыгыз бармы?

Булмаса, бигрәк тә яхшы. Экстрасенслар, алар, үз эшләренә синең белән минем кысылганны бик өнәп тә бетермиләр. Шуңа бик нервыларына тимик, андыйлар синең белән миннән башка да житәрлек.

## ӨЧ БАЖА

Быелгы 8 Март бәйрәменнән соң Вәлигә «хәйләкәр» кушаматы тагылып калды. Электән үк хәйләгә оста булса да, моңа кадәр эш кушаматка ук барып житкәне юк иде.

Ирләр көнендә (23 февральдә) гаиләләре белән кече бажалары Сәмиләргә жыелышканнар иде. Вәли хатыннарның ничек матур итеп чөкердәшә-чөкердәшә бәйрәм табыны әзерләп йөргәннәрен карап утырды да, бераз кызып алган һәм «Бажалар» жырын суза башлаган ирләргә серле генә итеп:

— Бер киңәш-табыш бар иде сезгә, бажалар, — диде.

— Йә, йә, сөйләп жибәр, тыңлап карыйк, — дип бажалары Кәли белән Сәми колакларын торгызды.

— Тиздән хатын-кызлар бәйрәме дә житә бит әле, егетләр. Безгә дә шулай йөгерешеп йөреп, табын әзерлисе, кәләшләрнең күңелен күрәсе бар. Ел саен аерым-аерым бәйрәм итәбез. Әллә быел менә шулай, хатын-кызлар кебек, бергәләшеп үткәрәбезме? Мәсәлән, мин үзем табын әзерләргә яратмыйм. Пешеренә дә белмим инде. Әвәләштерсәм дә, шул бәрәңге, йә йомырка тәбәсе. Ә өчебез берләшсәк, авырлык та өч тапкыр жиңеләер иде...

— Ну, бажа, баш та бар үзеңдә, — дип Кәли аны шунда ук күтәреп алды.

— Нигә булмасын, була ул, — дип Сәми дә шатланып ризалашты.

Сигезенче март ни — менә тора, килеп житкәне сизелми дә калды. Иртән үк, алдан сөйләшкәнчә, Кәлиләргә жыелыштылар. Көн дә бәйрәм, көн дә туй дигәндәй, ял көннәре дә шундый уңай туры килеп тора. Хатын-кызларның ул яктан бәхете бар инде ул, чукынчыкларның.

Тик ирләрнең эшләре әллә ни алга бармады. Кысан кухняда өч ир кешегә урын таррак булып чыкты. Хатын-кызлар бәйрәме хөрмәтенә ике яртыны «сындырып» алгач, ул тагын да кысанлана төшкәндәй булды. Берничә тәлинкәне төшереп ватып, табасы белән йомырка тәбәсен идәнгә каплагач, бажаларның иң өлкәне Вәли тагын сүз кузгатты.

— Болай булмый, егетләр. Киңәшләшеп алыйк. Киңәшле эш таркалмас, дигәннәр борынгылар да.

Бажалар, шуны гына көткәндәй, уфылдашып, урындыкка килеп аудылар.

— Бүген хатыннарга рәхәт. Әнә, иртән үк урамга чыгып киттеләр, әле һаман кайтып кергәннәре юк. Сәгать икегә өстәлегез әзер булсын, дигәннәр иде, вакыт та житеп килә. Ә безнең һаман табынга куяр бернәрсәбез дә юк, — диде, борчылып, Вәли.

— Шулай шул, — дип жөпләде аны Кәли.

— Ә нинди тәкъдимнәрегез бар соң? — дип Сәми «үгезне» мөгезеннән эләктерде.

— Нинди тәкъдим, дисең инде? — Вәли яңадан сүз башлады. — Карап-карап торам да, тагын бер карап куям. Өч борын шешә

янында гына кирәк икән ул. Ә менә кухняда икәү дә җитә, дип уйлыйм. Шуңа монда ике кеше калсын, югыйсә, бер-беребезгә комачау гына итәбез. Булмаса, мине азат итегез бу эштән. Өлкән баҗа буларак, өстенлек миңа бирелергә тиеш.

— Һай, һай, койрыкны сыртка салмакчы булдыңмы? Иң өлкәне генә түгел, иң хәйләкәре дә икән әле син. Ә кем, бергә уздырабыз, дип котκы таратты? Юк инде, баҗалар. Вәли иң өлкәне булса, мин аңардан алданрак өйләндем, шулай булгач... — Кәлинең бирешергә һич исәбе күренми иде.

Сәми бу гаделсезлеккә түзеп тора буламы?

— Ә мин Алланың кашка тәкәсемени? Аның каравы, абзагыз — күп бала атасы. Хөрмәт йөзеннән...

— Юк, баҗалар, болай бәхәсләшеп эш чыкмас. Әйдәгез, алайса, берәр нәрсә уйлап табыйк, — Вәли баҗаларын тынычлыкка чакырды.

— Шобага тотышырга! — дип кычкырып җибәрде Кәли.

— Шырпы тартышырга! — дип тәкъдим кертте Сәми.

— Юк, алай кызык түгел. Бала-чагамыни без? Тәк, тәк... Ә минем икенче төрлерәк тәкъдимем бар. Өч балыкчы турындагы мәзәкне ишеткәнегез бармы? Ягъни кем дә кем үз тормышыннан кеше ышанмаслык берәр хәл турында сөйли, шул табын әзерләүдән азат ителә.

— Һе... Бик кызык бу, бик кызык... — дип баҗалар икеләнде. Хәтерләренә күргән-ишеткәннәрен төшерергә тырышулары йөзләренә үк чыккан иде.

— Ә нәрсә турында? Шул балыкчы хакындамыни? — Монысы Кәли. Балыкчы шул ул.

— Ә нигә балыкчы гына, ди? Сунар темасы кайсы ягы белән начар? — Инде Сәмидә сунарчы җене кузгалды.

— Юк, бажалар, юк. Бүген бит — хатын-кызлар бәйрәме, әйдәгез, алар хакында.

Килештеләр. Иң беренче булып сүз кече бажага бирелде. «Яшьләргә бездә һәрчак юл ачык», — диде ике өлкәнрәк бажа. Тегесе, авырлык белән булса да, килеште һәм сөйли башлады.

— Беркөнне шулай бераз салмыш килеш эштән кайтып килсәм, тукталышта җиде-сигез әзмәвердәй егет бәйләнде бит. Әллә аракы таптыралар, әллә шаяртып кына тукмарга исәпләре — белгән юк. Әтәчләнеп караган идем — сугып та очырдылар. Менә тәпәлиләр, менә тәпәлиләр. Тукталыш тулы ир заты, ярдәмгә чакырып та карыйм, тик кайда ул, йөзләрен читкә боралар. Шунда тал чыбыгыдай нечкә генә билле бер кызыкай кеше арасыннан атылып килеп тә чыкты, тегеләрнең унысын ун якка, әллә аягы белән тибеп, әллә кулы белән сугып, селтәп ыргытты. Милиция килеп җиткәнче берсен дә җибәрмәде.

— Булыр, булыр, — диде Вәли. — Каратэчы кыз туры килгән инде бәхетеңә...

— Ә, бәлки, дзюдо белән шөгыльләнүчедер. Яисә самбо, яки... э-э... тхэквондо, — дип куәтләде аны Кәли.

Сәми, конкурстан үтмәгәнен аңлап, башын түбән иде.

Инде чират Кәлигә җитте.

— Бу хәл кичә генә булды. Хатынга чәчәк алыйм дип, базарга чыктым. Күңелемә оша-

ганын сайлап алдым. Акчаны түлим дип, кулымны кесәгә тыксам, янчыктан җилләр искән. Кесәгә төшкәннәр! Ары-бире каранам, ык-мык итәм. Тик кайда инде ул! «Их, булмады, — мин әйтәм Кавказ кешесенә. — Акчамны трамвайда сыпыртканнар. Гафу ит, туган, юкка борчыдым». «Кемгә иде соң бу чәчәкләр?» — дип сорый ягымлы егеткәй. «Хатынга иде, иртәгә бәйрәм бит», дим. «Хатынга, дисең инде? Соң, мә, ал, бушлай бирәм»,— дип миңа бер кочак розалар тоттырмасынмы?! Карышып та карыйм, юк, ай-ваема карамый, биреп җибәрде. Менә шундый хәлләр.

— Булыр, булыр, — диеште Вәли белән Сәми. — Алар арасында да юмартлары очрый.

Шулай итеп Кәли дә сират күперен кичә алмады.

— Йә, өлкән бажа, хәзер чират сиңа. Нәрсә белән шаккатырырсың икән? — дип мыек астыннан гына елмаешты кече бажалар, берберсенә күз кысышып. Нәрсә генә сөйләсә дә, җөпләргә үзара килешүләре инде бу.

Вәли серле генә елмайды да, сөйли башлады:

— Минем тарих алай ук кызык түгел, бажалар. Ышанасызмы, юкмы, анысы сезнең эш. Минем гаилә тормышын яхшы беләсез. Шуңа хатын белән ничек яшәгәнне белеп-күреп торасыз. Тик, ышансагыз — ышаныгыз, юк икән, — юк, хатынның бер ягыннан уңдым. Үзегез дә беләсез, бу якка (Вәли тамак астына чиртеп алды) йомшаклык бар. Эштән өч кешегә бишәр-алтышар шешә бушатып кайткан чаклар күп була. Ә кабымлыкка ни — шул бер телем икмәк инде. Кичтән яхшы ул, тик иртән башлана — ах-вах килеп уянасың,

баш чатнапмы чатный. Тик җиңгәгезгә рәхмәт — нинди генә кәефтә булмасын, иртән ачык йөз белән уята. Ник бер авыр сүз әйтсен, ник бер кырын карасын...

— Булыр, булыр, Маһинур җиңги менә дигән хатын, уңганлыгы теленә үк чыккан, — диештеләр, күз кысышып, Кәли белән Сәми.

Вәли, моны күрмәмешкә салынып, хикәясен дәвам итте:

— Өстәлгә килеп утыруым була, алдыма зур тәлинкә белән кайнар аш китерә. Аңысы гына нәрсә әле ул, ә иң мөһиме, егетләр, елмаеп-көлеп, алдыма: «Менә, мә, башыңны төзәт, җаным», — дип... мөлдерәмә тулы бәллүр рюмка белән йөз грамм куя...

— Юк, булмас! Кеше ышанмаслыкны... — дип ике баҗа кинәт, түзми, берьюлы кычкырып җибәрделәр һәм... бер-берсенә күзләрен түгәрәкләндереп карашып, тынып калдылар...

Әнә шулай итеп Сигезенче март табынын әзерләү Кәли белән Сәмигә төште. Вәли әзерне ашап-эчеп, рәхәтләнеп бәйрәм итте. Соңыннан савыт-сабаны да юышмады, сабакы. Шул булды — «хәйләкәр» дигән кушамат ябышып калды.



## КЕМНЕҢ СӨЯРКӘЛӘРЕ КҮБРӘК

Зәйни каладагы баҗасы Эфмирны кунакка чакырып кайчан хат язганын да оныткан

иде инде — күтмәгәндә, үз машиналарына, төялеп, килеп төштеләр. Төялеп дигәч тә, шул үзе, хатыны һәм бер кызы. Бажасы Зәйнидә генә инде ул андый байлык — җиде ыштук. Авылда ни, кышкы төннәр озын, электр уты да атнасына бер көн булса, алты көн янмый — әнә шулай туа торалар, рәхмәт яугырлары. Ярый, бәхетләре белән үссеннәр, Зәйнинең аларны гына ачка үтермәскә хәленнән килә әле.

...Кунак булгач, төрлесе була инде. Мәе дә, чәе дә чыкты өстәлгә. Шуны сизеп калды Зәйни: Эфмир бажасы бик мактанчык икән. Әй мактана бу, әй мактана. Ярый, мактансын, әйдә. Берсе дә ул яктан гөнаһсыз түгел. Калада үскәне дә, авыл кешесе дә.

Берзаман өйдә икесе генә торып калгач (хатын-кыз, бала-чага елга буена китте, ахры), ярыйсы ук кызып алган бажаларның сүзе шул каһәр суккан чәче озын, акылы кыска адәм затларына күчте. Эфмир бажасы коя гына борчакны. Мин болай иттем дә, тегеләй иттем. Исәпләсәң, күрмәгән хатын-кызы, шулар аркасында кичермәгән маҗарасы калмаган. Әле дә калада өч сөяркәм бар, ди. Чыгып бер генә сызгырам, хәзер унысы йөгереп килеп җитә, ди. Фәстерә инде, фәстерә. Фәстерсен, әйдә. Кызык бит шәһәрдә ничек яшәүләре турында тыңлап утыруы. Тик бу фәстерү бик озакка киткәч кенә, Зәйни арый башлады. Күпме кабатларга була инде бер үк хәбәрне... Җитмәсә, нәрсә ди:

— Ә, бажа, синең үзеңнең ул яктан ничегрәк соң, хатын-кыз, дигәннән? Авылда шартлар юк шул, бер хатын белән яшәсәң дә, гаеплә булмый. Аннан, авыл мужигына

кайда инде ул андый ләззәтне тату. Бигрәк кара сарыксыз, томана сукырсыз шул мәхәббәт фәнендә...

Монысы инде артыграк китте. Шул аракы шаукымы. Аекның уенда нәрсә, исерекнең телендә — шул, диләр диюен...

Тик шактый кызмача булып алган Зәйни дә кабынып китте:

— Көл, бажа, көл. Син, өч сөяркәм бар, дип, мактанган буласың. Ә минеке... Бар авыл хатын-кызы минеке! Бер генә сызгырам, барысы да «айт» дигәнче «тайт» итеп, капка төбенә йөгереп чыга. Теләгәнеңне сайлап ал.

— Кит инде, сөйләмә булмаганны! Икәүөчәү булса, туды-суды әле. Һе, бар авыл хатыны, имеш! Булмас, ышанмыйм!

— Әх, ышанмыйсыңмы?! Ярый алайса, әйдә, бәхәс! Иртәгә иртән сәгать биштә торабыз да, сынау үткәреп карыйбыз. Шунда ышанырсың. Бәхәсме?

— Бәхәс!

Ирләрнең сүзе ни белән тәмамланган булыр иде, ярый әле хатын-кыз, бала-чага кайтып керде. Сүз көрәштерү сүнеп калды.

...Иртән Зәйни сәгать биштә уянды. Кичәге хәлләр томан кебек кенә хәтерләнә. Шунда бажасы белән ни хакындадыр бик каты бәхәсләшкәне исенә төште. Ниндидер сызгыру, хатын-кыз... Ә-ә, хәтерләде. Үз алдына елмаеп куйды да, «гөп!» иттереп, бер чүмеч әйрәнне эчеп җибәрде. Аннан чоланда җан-тән белми йоклап яткан бажасын:

— Тор әле, бажа, тор! — дип, серле пышылдап, төрткәләп уятты. Тегесе:

— Ә-ә, нәрсә бар? — дип авыр гына күзләрен ачты.

— Әллә оныттың дамы? Бәхәсне? Әйдә, үземнең сөяркәләрне күрсәтәм. Кичә ышанмаган идең.

Баҗасы да нәрсәнедер исенә төшерде бугай. Кызык булып киткәндер инде, тиз генә сикереп торып, киенде, юынды. Күптән уянып, сыер савып кергән Зәйнинең хатыны Фәрхибану:

— Кая болай иртәләдең, Эфмир кияү? — дип сораша-сораша, каты чәй ясап бирде.

— Ничек йоклап ятмак кирәк җәй көне авылга кайтып, — дигән булды анысы.

Чәй эчкәч, урамга чыктылар. Зәйни Эфмир баҗасы белән түбән очка таба атлады. Авыл күптән уянган, кояш җылысы әле бик үк җиргә килеп җитмәгәнлектән, иртәнге һава салкынча. Анда-монда сузып-сузып сыерлар мөгрәгәне, кош-корт каңгылдашканы ишетелә.

Ниһаять, авыл очына чыгып бастылар.

— Менә, баҗа, карап тор, ничек була ул сөяркәләр, — дип Зәйни, кесәсеннән нәрсәдер алып авызына капты да, сызгыртып җибәрде. Ачы тавыш яңгырады. Әйтерсең, шуны гына көткәннәр, бер үк вакытта ике йөздән артык авыл капкасы ачылып китте, урамга хатын-кыз чыгып сибелде. Ул аллы-гөлле күлмәкләр, яулыклар, алма кебек яшь киленнәр, сылу кызлар... Чак артына аумады Эфмир. Калада мондый сөяркәләрнең анын төшенә дә кергәне юк. Ну, җинде Зәйни баҗасы. Икенче кайтуында бер тартма коньяк Эфмирдан инде.

...Бераздан Зәйни, озын чыбыркысын өстерәп, мал артыннан «шарт» та «шорт» шартлатып, көтүлеккә таба китеп бара иде. Бүген авыл көтүен йөртү чират буенча аныкы шул.

Бажасы ни, бернәрсә дә аңламады — аның өчен авыл тормышы кара урман белән бер иде...

## ОЗАК ЯШӘҮ СЕРЕ

Гәзитебез мөхәррире үз бүлмәсенә чакырып алды.

— Сиңа менә шундый бурыч, — диде ул.— Тиз генә Чокыр-Чакыр авылына җилдер. Анда яшәгән Сәлмән бабайга шушы көннәрдә йөз яшь тула икән. Иртәгә әйберең минем өстәлдә ятсын. Бар, — диде дә, сүз тәмамланганын белдереп, алдында яткан бер мәкаләне аркылы-торкылы сызгалый башлады.

Чокыр-чакырлар аша, көрт ярып, машина белән җилдереп барып җиттек. Без эзләгән бабай ишек алдында буран уйнатып, кичә яуган карны көрәп йөри иде. Нинди йомыш белән килүебезне аңлаткач:

— Сөйләшербез, балалар, сөйләшербез. Ә хәзергә менә шушы карны көрәп ташлыйк әле, — дип, безгә ике көрәк тоттырды.

Эш беткәч, өйгә керде. Уратып-чуратып, йөзъяшәр карттан озак яшәү серләрен сораштыра башладым.

— Белмим, балалар, белмим. Аны белсә, бер Ходай үзе генә белә. Шуңа, Ходай Тәгалә ярдәме беләндер, дим. Әнә, гәзитләр «хезмәттә» дип тә яза, алар белми язмас, син дә шулай дип яз. Мин каршы түгел.

— Аракы һәм папирос белән беркайчан да дуслыгыгыз булмагандыр инде? Гәзит дигәннән, алар да шулай дип яза бит, бабакай.

— Дөрес, балалар, дөрес, кайдан беләләр, диген. Үз гомеремдә беркайчан да кибеттән аракы сатып алып эчкәнем, папирос алып тартканым булмады. Умарта тотам, алмагач үстерәм. Кәрәз балыннан коелган әче балның ничек файдалы икәнен беләсезме икән? Яшерен-батырын түгел, «сәмигулла» белән шаярган вакытлар да булды. Урыс «сәмәгүн», диме әле? Серен белсәң, алмадан да менә дигән әче бал коеп була. Теләсәгез — өйрәтәм. Ә-ә, карчык, — бабай казан янында кайнашкан әбигә эндәште, — китер әле берәр чүмеч шул нәмәстәкәеңне, кунакларга авыз иттерим. Шулай, балалар, барысы да үземдә булгач, кешедә дә аракы эчмәдем, кибеттән дә сатып алмадым.

— Ә... ә, папирос, сигарет тартканыгыз булдымы соң?

— Юк, улым, аны тартканчы, сыер тизәге тарт. Сигәрит, папирус кебек нәрсәләргә дә акча әрәм-шәрәм иткәнем булмады. Тәмәкене, мин аны үзем үстерәм. Урысча «самасад» була. Җиде төрен чәчәм. Хәзер кибетләрдә тарткыч юк, булса да, кыйммәт, күчтәнәчкә алып китәрсез. Шулай, балалар, сигәритне сез дә тартмагыз. Үзең үстергәнгә ни җитә. Үзе майлы, үзе файдалы. Кая, берәрне төреп җибәрик булмаса, үпкәләрне йөздереп, — дип, баш бармагы юанлыгы «кәҗә тәпиен» төреп, пырхылдатып та җибәрде.

...Кич өйгә кайтып кергәндә авызда кәрәз балыннан коелган әче бал белән тәмәке тәме бетеп җитмәгән иде әле...

...«Озак яшәү сере» дигән бу мәкаләм газиттә басылмагандыр, дисезме? Нигә басылмасын, басылды, хәзер бит хәбәрдарлык за-

маны. Тик анда «хезмәт сөйдем», «аракы эчкәнем, тәмәке тартканым булмады», «бал кортлары тотам, алма бакчам бар» дигән сүзләр генә торып калган иде. Нигә көләсез, дөрес түгелмени?

## ЯЛАНГАЧ ДИВАР ЗАМАНЫ

Район гәзитендә ничә ел эшләп, мондый тарихи вакыйганың шаһиты булырга туры килгәне юк иде әле. Киләчәктә оныкларым: «Үзгәртеп кору чорында син нәрсә эшләдең соң?» — дип сорасалар, аларга, күз дә йоммый, шушы хат турында сөйли алам. Намусым пакь, күңелем саф, эшләгән эшләрем ак.

Ярый, башыннан башлап, ашыкмый гына сөйлим әле. Хәзер ашыгасы калмады. Сукты ул изге сәгать! Ярый, хуш, оныкларым сорады, ди. Ә абзагыз әйтәчәк: «Шулай, балалар. Мин матбагада эшләгәндә безнең мөхәрририят менә шундый-шундый хатлар ала иде».

Шулай, килде бу хат. Инде СССР бетүенә шактый еллар узса да, конвертына һаман шул илнең дүрт тиенлек маркасы ябыштырылган, тик бераз читтәрәк кенә: «Новая цена: 1500 руб.» — дип язылган. Мөһере дә бар, кайдан, кайсы көнне салынган, үзәк почтамтка кайчан килеп җиткән, «цензура тикшерде» дигән — кыскасы, барысы да бар. «Редакциягә, хатлар бүлегенә» диелгән. Иң элек хатны шул бүлек мөдире укып чыккан. Әллә укып бетерә алган, әллә юк, чатыр чабып безнең бүлеккә килеп кергән.

— Тугыз-ун ел узды, тик кайда демокра-

тия, ачыклык, гражданлык кыюлыгы, үзгәртеп кору, халык активлыгы, дисез! Бар ул, егетләр, бар! Демократия дә, хәбәрдарлык та, калган барысы да! Менә ул — шуларның дәлиле! — дип дулкынланып һәм тантаналы төстә өстәлгә сак кына теге хатны китереп салды.

Ишекне бикләп, хатка ябырылдык.

«Исәнмесез, кадерле редакция кешеләре! — дип башланган ул. — Хәзер демократия, ни язсаң да була, шуңа күңелдәгеп сезгә ачып салырга булдым. Сез, күп укыган кешеләр, аңлатыгыз әле миңа: нинди хәлгә китереп терәделәр илне? Спекуляция, фәхишәлек, эротика... кексмы шунда тагын. Элек кеше үтерүчеләр генә була торган иде. Хәзер нииндидер мәгафия («Мафияне әйтә инде бу», — дип төзәтеп куйды бүлек мөдире), раһит («рэкет»), инде килеп, ухвати-за-акция («приватизация»), ваучер дип, миен черетәләр халыкның. Аның ухваты күптән бар инде: дүрт җәпле, колхозда сәнәк дип атала. Шуңа акмаса да, тамып тора, җан асрарга җитә. Әле менә ваучер бирделәр. Яхшырагы — маузер йә шмайсер бирсеннәр иде, белер идек нишләргә. Шул кәгазь кисәге 200 мең, 300 мең торачак икән, диләр. Бер кап шырпы миллион сумга күтәрелгәчме? Әйе, анда биш маузерың... әй лә, ваучерың булса, алырга булыр.

Ышаныч бетте бу дөньяга. Ярый, элек Лениныбыз бар иде. Ул һәрчак баш очыбызда булды. Диварга сурәтен эләләр дә, аңа урындыкларын арты белән куеп, зур-зур абзыйлар утыра иде. Син килеп керәсең, утырырга кушса, утырасың.

— Йә, ни йомыш, тиз сөйлә, вакытым юк, — ди. Үзе карый сөзеп каш астыннан.

Аның артыннан Ленин бабай карый сөзеп кипке астыннан. Әйтер сүзеңне дә әйтә алмый чыгып китәсең. Хәзер аңладым мин Ленин бабайны нигә үз каршыларына элмәгәннәрен: ул коммунистларның аның күзенә туры карарлык эшләре булмаган, намусы калмаган икән шул, оятларына көч килгән. Ленин кушканның барысын да алар нәкъ киресенчә эшләп утырганнар икән. Әйткән ди бит мәрхүм Маркс (безнең авылда шул исемне йөртүче алкаш бар иде): «Хәзер партия әгъзалары күп ул, тик чын коммунистлар гына юк», — дигән. Аракы эчкән кеше дә кайчак дөрес сөйләр икән, валлаһи газим. Ленинга да ышаныч бетте хәзер. Әллә нинди китапка сыймаган сүзләрдән генә тора ди бит аның илле томлык әсәрләре. Элек безгә аның әйбәт сүзләрдән торган юлларын гына укыткannar, гөнаһ шомлыгы. Ул да бит кеше аттырган, астырган, патшаны атарга да ул әмер биргән икән. Ә патша әйбәт кеше булган. Үлеп әрәм булган, мәрхүм. Ярый, Сверлау, әй, Екатеринбур җире пух булсын үзенә.

Сталин дигәне дә булган әле безнең илдә. Анысы иң яхшысы булган җитәкчеләр арасында. Шуңа аның тирәсендә йөргәннәре, аңа лаек булмагач, үзләрен-үзләре атып-кисеп бетергәннәр. Алардан күреп, аннан түбәнрәкләре, аннан түбәнрәкләреннән түбәнрәкләре Себергә киткәннәр, яртысы шулай ук атылып үлгән. Шулай ярты ил күченгән, ди, шунда.

Мин бәләкәй чакта сөйлиләр иде: ферма өенә халыклар атасының зу-ур сурәтен элгәннәр. Бер мокыт түзмәгән:

— У-у, мыек хәтәр икән моның, буялса, бер пот он буяладыр, — дип әйтеп ташлаган.

Шулай диюенең сәбәбе бар: ул вакытта, ачлык булгач, эш хакын көн саен бер кечкенә тәлинкә он белән түләгәннәр. Ач кеше, аеруча, бала-чага, түзмичә, өенә кайтып җиткәнче үк тәлинкәдәге онын ялап бетерә икән. Мыегы булган кешенекенә бераз буялып калганлыгы чәйнәп каптырмасаң да аңлашылып торадыр. Шуны күз уңында тотып әйткән инде теге мәхлук. Икенче көнне чыгып та киткән Себер ягына. Кайтмаган. Он урынына тегендә боз ялый торгач, теле белән шунда ябышып үлеп калгандыр инде, мәрхүм. Авыр бозы җиңел булсын.

Шуңа Сталинның пәртритен эләргә куркалардыр. Хәзер дә көн он яларга калды, мыегы хакында әллә нәрсә әйтерсең дә, Себер китеп тә барырсың. Әле уйлап-уйлап торам да, шуны уйлап куям: әллә диварга эләрлек бер җүнле җитәкчебез дә калмаган инде? Соң, уйлап карагыз. Хрущев кукуруз ипие ашатты. Брежневның гомере калай тәтәйгә кызыгып үтте. Андропов, диссидент, дип, ярты СССРны чит илгә куып чыгарды. Горбачев илне таратты, Елчын бабай илне сатып бетереп бара. Черненко дигәне дә утырган, имеш, тәхеттә. Тик анысы кем булгандыр, хәтерләмим. Әй, барыбер халык өчен бер-бер начарлык кылгандыр әле. Шуны уйлыйм тагын: әллә нинди сөйкемсез сөяге бар безнең ил халкының — бер дә җитәкчедән уңмый. Пәртритен эләрлек кеше дә юк. Дивардан пәртрит карап тормагач, эш тә бармый. Демократия заманы, дигән булалар. Демократия түгел — ялангач дивар заманы хәзер. Ә болай ару гына егетләр бар, ди дә соң Дәүләт уйханәсендә. Мәсәлән, монгол далаларын бик яратучы теге Җирән атлы

усал депутат үзе ни тора! Мыек кына үстерәсе бар, ну шәп торыр иде стенада асылынып. Кем белә: сайлап куйсак, монгол далаларында ат уйнатып, куй көтеп йөрергә дә насыйп булыр. Би-ик иркен ди ул дала. Безнең ярты илне сыйдырырлык, имеш.

Шулай, хөрмәтлеләрем, күңелдәгеп ярып салдым әле менәтерә. Авыр эшегездә җиңеллек теләп, керәстиян Хәйбулла абзагыз».

Вәт, оныклар, заманында без менә нинди хатлар ала идек, укый ала идек, диярмен.

«Басыла идеме соң?» — дип сорый инде әллә бер юньсезе?! Кара әле, энем, бәләкәй чагыңда синең арт ягыңа каеш азрак төшкән, ахры. Хәзер үзем өстим, җитми калган булса! Демократия дигәч тә, нигә син провокацияле сорау бирәсең? Укый алгач та бик җиткән. Хәтта артыгы белән әле.

Азындырганнар иде Горбачев заманында халыкны. Әле дә төпләп, чүпләп бетермәгәннәр икән. Ярый, бераз яшик әле. Тамыры белән йолкып атачакбыз. Пәртритен диварга эләрлек берәр юньле җитәкче генә килсен. Шәхесе генә булсын — культын ясыйбыз инде аны.



## КЕМ ТҮРӘ — ШУЛ КӨЛӘ

Бу хәл Җәүдәт абзый кладаущик вакытта булган. Бик сакчыл, хәтта саран иде мәрхүм.

Бар әйбер аңарда, бирсә — бирә, теләмәсә — юк. Булган очракта да кире борып җибәрергә күп сорамас. Үзенә күрә — түрә бит. Ялындырырга ярата.

Бервакыт аңа ферма мөдире Әхмәт абзый шылтырата икән. Болар арасында шундыйрак сөйләшү булган.

— Кем? Җәүдәт?
— Кем эпәт?
— Мин — Әхмәт.
— Ә-ә, зәхмәт...
— Юк, Әхмәт.
— Мәслихәт.
— Ни, Җәүдәт...
— Ни кирәк?
— Ун кәрәк.
— Өй пүдрәт...
— Соң, йөдәт...
— Чо эпәт?!
— Юктыр, әйт?
— Бар, Әхмәт.
— Вәт рәхмәт...
— Тик, Әхмәт...
— Әү, Җәүдәт?
— Сиңа, шәт...
— Нәрсә — шәп?
— Бирмим, вәт.
— Әх, Җәүдәт...
— Юк кәрәк.
— Ну, рәхмәт! — ди дә, Әхмәт абзый, җен ачулары чыгып, трубканы атып бәрә.

Тик дөнья — куласа, бер әйләнә, бер баса, дип әйтмәсләр иде аны. Үч иткәндәй, Җәүдәт абзыйны кладаущиктан алып, аның урынына... Әхмәт абзыйны куйганнар. Җәүдәт абзый исә ферма мөдире булып калган. Бераз-

дан Җәүдәт Әхмәткә шылтырата икән — кө-рәк кирәк, ди. Үзе теге вакытта бирмәде бит. Болар арасында шундый сөйләшү булган, диләр.

— Әй, Әхмәт!
— Кем кирәк?
— Син кирәк.
— Ни кирәк?
— Ун көрәк.
— Ник кинәт?
— Кар көрәп...
— Ал күбрәк...
— Бик теләп.
— Ун көрәк...
— Тап тизрәк!
— Син бигрәк...
— Ай, йөрәк...
— Бар көрәк...
— Тиз кирәк...
— Кем — өрәк?!
— Их, кодрәт...
— Шул, Җәүдәт,
Син — түрә,
Мин — дүрәк,
Мин — түрә,
Син — дүрәк.
Юк көрәк,
Йөр йөдәп, — дигән дә, трубканы урынына салып куйган. Җәүдәт абзыйның ничек ярсыганын күрсәгез икән! Үзе тагын теш арасыннан гына:

— Ярый, тагын кладаущик итеп куйсалар, бу Әхмәткә көрәк бирергә туры килер, ахры, — дип куйган.

## КӨНЧЕЛ КҮРШЕ

Дөньяда төрле кешеләр була. Моны барысы да белә. Ә менә төрле күршеләр булуын барысы да белеп бетерә микән? Ай-һай... юктыр. Менә мин дә, яңа, тугыз катлы йортка күчкәнче, күршеләр гел әйбәт, ярдәмчел, эчкерсез буладыр, дип уйлый торган идем. Баксаң, аларның да көллесе һәм төрлесе була икән. Шулай да, төрлесе булса булсын, тик көнчеле булмасын икән.

Без яшәгән өченче кат мәйданчыгында ике күршем чын мәгънәсендә кеше булып чыкты. Ә менә өченчесе — Вахит дигәне көнчеллеге белән мине шаккатырды. Булса да була икән көнчелләр! Сезнең андыйны күргәнегез дә юктыр әле... һәм күрергә дә язмасын. Ә очрата калсагыз — Аллам сакласын.

Күрше булгач, бер-береңә йөрешәсең инде ул. Вахит та безгә килеп керде. Керде дә, ач бүредәй, алан-йолан каранып, фатирны бер итеп йөреп чыкты. Күңелле генә килеп кергән кешенең шул арада йөзе үзгәрде, сәер булып кызарды. Нигә икәнен аңламаган идем, хатыны Фатиха апа кергәч, ачыкланды.

— Ирем базарга китте әле. Әнә, күршеләрнең келәме икәү, телевизорлары җитмеш тугыз каналлы, видеомагнитофоннары бар, йомшак мебель дә алып утырткannar, ди. Баҗасыннан бурычка акча алган, аны ничек түләп бетерергә уйлыйдыр. Әй, көнчел дә инде. Гомер буе җанымны ашады шул кешегә көнләшүе белән...

Чыннан да, күп тә үтмәде, йорт алдына зур йөк машинасы килеп туктады. Кай арада йөк бушатучыларын тапкан, дөбер-шатыр ди-

ван, кәнәфиләр, төсле телевизор, видеомагнитофон, келәм ташырга тотындылар.

Шул ук кичне күршем, йөзе балкып, килеп тә кергән.

— Менә, күрше, шуны-шуны алдым әле, — дигән була.

Яңа йортта әнә шулай яшәп киттек. Тик моның белән генә бетсә иде ул. Мин берәр яңа нәрсә алсам, инде белеп торам: хәзер күршем дә базарга чыгып чабачак, ничек итсә итәчәк, бурычка муеныннан батса батачак, тик шул әйберне барыбер алып кайтачак... Менә безнең кыз сәнгать мәктәбенең баян сыйныфына йөри башлады. Баян кирәк булды — сатып алдык. Бер көннән соң карыйм — күршем дә баян күтәреп кайтып килә... Кичә кызга пианино алдык. Өч көннән аңа да китереп бушаттылыр. Уйнаучылары да юк бит инде — кызы берәү генә, анысы да кияүдә... Хәзер хатыны керә дә, зар елый:

— Икмәк алырга да акчабыз юк, ә ул бурычка сорап, бер кирәкмәгән әйбер ала. Күршекәем, тыңла әле, зинһар, сүземне, бу арада әйбер сатып алмый торчы, бөлдерә бит бу, мәлгунь, хәер эстәргә урамга чыгарып җибәрә, — ди.

Менә сиңа мә!

— Мин бит, күрше, кирәк булганга алам. Аннан, бурычка акча алмыйм, ә башта акча җыям, шуннан соң гына кибеткә чыгып китәм, — дим.

— Анысы шулайдыр... Тик Вахит абыеңны үзең беләсең, ул аны аңлыймыни? — ди. Аннан бераз эндәшми торды да: — Тагын нәрсәләр аласыгыз бар соң әле? — дип, куркып кына сорый.

— Ни, дип... Менә яңа суыткыч кирәк, аннан тузан суыргыч... Без бит әле генә нәрсәдер сатып алырлык акча эшли башладык. Хәер, элек кибетләрдә теләгәнеңне сатып алырдай әйбере дә юк иде. Тагын менә стенка, китап киштәсе, берничә урындык кирәк...

— Ай, Аллам, күрәселәр бар икән, — дип, елардай булып, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, чыгып китте Фатиха апам.

Монысы кәҗәсе генә, ә мәзәге алда булган икән әле. Күршең көнчел булса, гомергә уйламаган кызык хәлләргә дә юлыгасың икән...

Җәй урталары. Бакчадан кайтып киләм, өйдә былтыргы бәрәңге беткән, хатыным киткәндә:

— Яңа бәрәңге казып кара әле, булса, берәр чиләк алып кайт, — дип калган иде. Кулымда шул. Ике рәт диярлек казысам казыдым, ярты чиләкләп җыеп алдым. Кеше көлмәсен, дип, вакларын аска, ә берничә иң эресен өскә салдым. Йорт ишеге алдында күршем Вахит абый очрады. Телемнән нәрсә тарткандыр, шаяру катыш:

— Күрше, яңа бәрәңге казып караганың бармы әле, үскәнме? Менә безнеке шулайрак булган инде, — дип иң өстә яткан куш йодрык зурлыгындагы бәрәңгене алып күрсәттем. Күрсәтмәсәмче!

...Икенче көнне Фатиха апа кергән.

— Теге юләр бүген бар бәрәңге бакчасын казып чыккан. Әнә, күршеләрнең бәрәңгесе инде хәзер үк баш чаклы булган, ә безнеке күгәрчен йомыркасы кадәр генә, үсмәгән, ди. Ай, Ходаем, бәрәңгесез калдырды бит бу быелга... — дип сыкранып чыгып китте.

...Үземне гаепле санамыйм — күршемнең

башына да шул көнчеллеге җитте. Хикмәт шунда, хезмәтем буенча миңа эшемне еш кына өйгә алырга туры килә — йә коралларны, йә кирәкле әйберләрне култык астына кыстырып кайтам да, кичен эшләп, иртән алып китәм. Безнең эштә кайчан, ничек эшләвең мөһим түгел, ә соңгы нәтиҗәне сорыйлар, һәм ул тиешле вакытына башкарылган булсын. Минем көн дә диярлек култык астына нәрсәләр кыстырып кайтуым күршемнең кытыгына тигәндер инде. Ул да эшеннән тегесен, монысын әләктереп кайта башлады. Ә ул зур заводта эшли, аяк астында караучысыз яткан, әмма йорт-хуҗалыкта кирәк булган нәрсәләр аз дисеңмени? Җитмәсә, күршең көн дә нәрсәләр алып кайтсын! Тик бу хәл озакка бармады. Берсендә күршем җиде тонна бакырны култык астына кыстырып алып кайткан, аны кемгәдер саткан. Тик артыннан милиция килеп җитте дә, күршемне алып та китте. Менә хәзер аны бер җиде ел күрә алмам инде. Тик Фатиха апа алдында гына кыен, ул мине гаепле саный бугай—хәзер керми башлады, хәтта, очрашканда, исәнләшми дә. Күршеләр белән син дә мин яшәп ята идек, югыйсә.

Шулай, егетләр. Күршең булса, көнчел булмасын икән ул... Уй-исәбең азрак була...



## САКЧЫЛ БАЙТҮРӘ

Төшке аштан соң мине цехның профком рәисе Юлдашбаев туктатты:

— Сиңа, местком әгъзасы буларак, йомыш кушмакчымын. Кыручы Барлыбаевны беләсең бит әле? Әнә ул авырып киткән, вакытлыча эшкә яраксызлык кәгазе алып, өендә ята икән. Кереп, хәлен белергә кирәк, кешенең күңеле булыр. Аннан, кылын да тартып кара: эшкә кайчанрак чыкмакчы икән? Кыручы булмагач, прәме ике кулсызбыз — план яна. «Озагракка сузылса, алмаш эзләргә кирәк булыр», — дип тора иде цех начальнигы.

...Ишекне хатыны ачты.

— Байтүрәме? Өйдә, өйдә. Хәзер кайтыр, кибеткә киткән иде, — диде дә, эчкә үтәргә чакырды.

— Алай кибеткә йөрергә хәле булгач, терелеп киләдер? — дидем, ишектән керә-керешкә.

— Һи, аңа чуртым булсынмы? Кибеткә шулай гел үзе йөри ул. «Сез әйбер ала белмисез. Акча күп бетерәсез, ә алган нәрсәгез күренми», — ди.

Хатыны мине залга үткәреп, караштыра торырга дип, журналлар тәкъдим итте дә:

— Гафу итегез, кухняда эшем бар иде, — дип чыгып китте.

Залга күз салдым. Бик бай яшиләр икән, бүлмә тулы мебель, бер якта — стенка, әллә ничә келәм. Берсе дә безнең илнекенә охшамаган. Һәр җирдә пөхтәлек, тәртип, бар нәрсә «ялт» итеп тора.

Шунда ишектә кыңгырау зыңгырдады. Байтүрә булган икән, бераздан аның кухнядан:

— Аны шулай булыр, дип уйлаган идем. Чәй әллә кайчан кайнап чыккан, ә газны һаман япмагансың. Мин бит сине, кайнап чыгу белән газны сүндер, дип, кисәтеп кенә торам. Сиңа күпме әйтергә мөмкин?! Балаларны да хуҗасызлыкка өйрәтеп бетеп барасың. Әнә, кешеләрне кара: һәр тиенне исәпләп тота... Ә сумнарның тиеннәрдән җыелганын үзең дә яхшы беләсең — бухгалтер кеше. — Аннан юыну бүлмәсе ишеге ачылган тавыш ишетелде. — Ә монда нигә көпә-көндез ут яна?! Ана сөте белән кермәгәч, сыер сөте белән кермәс, диләр, шул дөрестер, ахры. Көн саен телевизор карыйсың, шуның бер дә файдасы юкмыни соң?! Анда бит ике сүзнең берендә: экономия, сакчыллык, диләр. Ә сезгә ул сүзләр бар ни дә, юк ни...

Тавыш азга гына тынды да, икенче урыннан тагын яңгырады:

— Ә монысы инде бөтенләй китапка сыймый. Нигә бу әйберне чүп савытына ташладың? Тагын бер-ике ел хезмәт итә бит әле ул... Комиссионкага илтергә кирәк. Сезнең белән шул инде — азга гына күз уңыннан ычкындырдыңмы, хәзер бар өйне таратып бетерергә генә торасыз...

Тагын нәрсә белән бетәр иде бу «хуҗалыкны барлау», шунда хатыны сүз кыстырырга өлгерде:

— Байтүрә, Байтүрә, дим, тукта әле. Эндәшергә дә ирек бирмисең. Сине эшеңнән кеше көтеп утыра, янына чык. Калганын соңыннан сөйләшербез. — Шуннан, шаяртып булса кирәк, өстәп куйды. — Синең бергә шахмат уйный торган таныш табибың аша ничек вакытлыча эшкә яраксызлык кәгазе алганыңны

тикшерергә килгәннәр. Тик шуны аңлат әле миңа: ул, отылса, сиңа бюллетень бирә дә ул, ә син, отылсаң, аңа нинди хезмәт күрсәтәсең соң? — Аның тавышында көлемсерәү чаткылары сизелеп калды.

— Ә?! Нигә аны шунда ук әйтмисең?

— Соң, үзең авыз да ачтырмыйсың бит...

— Аннан, нәрсә сөйләгәнеңне колагың ишетәме синең? Уйнап сөйләшсәң дә, уйлап сөйләш, яме? Тагын шуны колагыңа киртеп куй: мине отарлык кеше дөньяга тумаган әле. Отылсам да, кулымнан килмәгән эш юк. Ә җиңел машинасы булган кеше өчен минем кебек кыручы, фрезерлаучы, калайчы күктән төшкән Алла бүләге ул...

Аларның шулай шаярып сөйләшүләренә шаһит булганга (зал ишеге ачык калган иде) уңайсыз булып китте.

Шунда ишектә Байтүрә үзе дә күренде. Тавышы бик теремек ишетелсә дә, аякларын чак сөйрәп, залга үтте. Хәле бетеп кәнәфигә ауганнан соң, авырлык белән тын алып, саулыгына зарланды.

— Авырсам да, менә кибеткә чыгып әйләндем әле. Хатынга болай да һич ярдәм итеп булмый, гел эштә дә эштә... Әле форсаты тигәндә, әйдә, авыр булса да... Аларга да ял кирәк... — дип сөйләнеп алды.

Хәлен белешкәч, тизрәк китү ягын карадым. Авыру кешене йончыту һич ярамас. Профком рәисенең йомышын әйтергә дә телем бармады.

Шушы вакыйгадан соң без Байтүрә белән танышлар булып киттек. Аралашып ук яшәмәсәк тә, очрашканда бер-беребезгә баш кагып үтәбез. Ул да мине белә, мин дә аны.

* * *

...Төш алдыннан гына кыру цехына йомышым төште. Биш минут эчендә эшләп алырлык бер кечкенә деталь кирәк булды. Тик, барып керсәм, әле төшке ашка кадәр ярты сәгать вакыт булса да, беркем дә юк. Бар җирдә «гөлт» итеп утлар яна, станок кабызулы килеш. Монда гына чыкканнардыр, ахры, дип уйладым. Әллә берәр нәрсә булдымы икән?

Тик, ни гаҗәп, күпме генә көтсәм дә, кеше-кара күренмәде. Электр утын өзеп, миңа да ашханәгә юнәлергә туры килде.

Төштән соң яңадан кердем. Тимер йомычкаларга күмелеп, Байтүрә нәрсәдер кырып маташа иде. Аяк астында да, почмакта да, ишек төбендә дә чүп-чар чәчелеп ята. Эшләпәле, галстуклы бер юан абзый Байтүрәнең эшен читтән генә күзәтеп тора.

Хәлне аңлатып бирдем. Байтүрә, ризасызлык белдереп («Бетмәде инде сезнең эшегез!»), йөзен чытты. Шулай да, кирәкле тимерне алды да, детальне штангенциркуль белән үлчәп, алай итеп, болай итеп, тиз генә аны беркетеп, кыргычны эшкә дә кушты. Тик ашыкканда шулай килеп чыга бит ул: йодрык кадәрле материалдан төймә зурлыгы деталь әзер булуга, үлчәп карагач, артык кечерәеп киткән булып чыкты. Байтүрә аны, ачу белән, тимер йомычкалар арасына ыргытты. Эшне яңадан башлап, инде монысында саграк тотынырга туры килде. Аның алдында үземне гаепле тойдым. Минем өчен ашыга бит ул, минем аркада күпме материал, иң мөһи-

ме — кадерле вакытын әрәм итте. Шуңа ачулана инде бу...

Деталь әзер булуга, аның эсселегенә карамастан, эләктереп алып, кулымда сикертә-сикертә, тизрәк китү ягын карадым.

* * *

Оешмабыз үз-үзен финанслауга күчү сәбәпле, бүген көн үзәгендә торган шушы мәсьәләгә багышланган җыелыш булып узды. Һәркемнең телендә сакчыллык, экономия, ресурсларны белеп файдалану, яңа резервлар эзләү, һәр тиенне исәпләп тотыну кирәк, дигән сүз булды.

Миңа, нигәдер, бу җыелышта Байтүрә һичшиксез чыгыш ясарга тиеш кебек тоелган иде. Ул бу темада судагы балык кебек йөзәргә тиеш. Тик... көтүем бушка булды. Мөнбәргә чыгу аның уенда да юк иде бугай. Ә менә һич уйламаган кешеләр, иркенлек сизеп, халык алдына чыгып, күңелләрен бушатып төштеләр. Ә Байтүрә хәтта йокымсырап та алды. Аннан еш-еш сәгатенә күз салды. Аңардагы бу үзгәреш мине шаккатырды. Әллә соң... өендә берәр бәхетсезлек бармы? Һәрчак кайдадыр ашыгабыз бит, туктап хәл белешер, исәнлек-саулык сорашыр вакыт та таба алмыйбыз. Мин үз ягымнан булган бу күздән ычкындыруны төзәтергә, җыелыш тәмамлану белән аның янына барып, ни булганын ачыкларга булдым.

Тик җыелыш тәмамлану белән Байтүрә сикереп торды да, ашыгып-кабаланып, ишеккә ташланды. Артыннан чак куып җитеп, җи-

ценә ябышкач кына, борылып карап, мине танып туктады.

— Ни хәлләрдә яшәп ятасың, Байтүрә? Гаиләләр тазамы, үзеңнең саулык ягы ничек?

— Барысы да яхшы, дус кеше. Гафу ит, ашыгам, ни йомыш иде?

— Йомыш, дип ни... Хәлеңне белим дигән идем. Әллә берәр нәрсә булдымы икән дип борчылуым. Син бик сакчыл кеше бит, монда чыгыш ясарсың, үз сүзеңне әйтерсең дип тора идем. Өеңдә ничек сакчыллык өчен янганыңны беләм, үзем шаһит...

— Әй, чыгаралар шунда бушны уйлап. Башка эшләре юкмы икән? Син дә тапкансың борчылыр нәрсә. Монда бит сакчыллык өчен җаваплы кешеләр бар, әнә, алар эшләсен үз эшләрен. Ә минем үз мәшәкатем муеннан ашкан. Нигә мин бер дә юкка башымны каңгыртыйм? Кеше эшен ишәк кайгыртсын...

— Тукта әле, тукта. Менә сиңа кирәк булса! Аптыраттың. Сине белмәсәм бер хәл иде. Син бит өеңдә, әнә, һәр милликубометр газ өчен, электр энергиясе артык бер генә минутка да файдасызга янмасын өчен җан атасың...

— Ә-ә, аны әйтәсеңме? Ул бит өйдә. Нинди газ, ди? Минем уйлавымча, чәйнүк утта никадәр озаграк торса, шулкадәр тиз тузадыр ул. Ә энергия... анысын үзең беләсең, һәр киловатты күпме тора... Күпме янса да, минем кесәдән чыга. Аннан, электр шәмнәре соң? Ничаклы озак кабызулы торса, шулкадәр тиз туза. Аннан, карап кына тормасаң, сафтан чыга торган әйберләр азмы — телевизор, суыткыч, үтүк, электр кырынгычы, тузан суыргыч...

Минем башыма кан йөгерде, күз алларым караңгыланып китте. Беренче тапкыр күргәндәй, аңа текәлеп карадым.

— Әле кая ашыгасың? Әйдә, бергә кайтырбыз, — бу сәер кешене аңлыйсым килә иде (хәер, нәрсәдер төшенә башлаган идем инде).

— Юк, ашыгам. Менә җыелышта уйлап утырдым әле: мөгаен, хатын тагын да юыну бүлмәсендәге утны сүндерми чыгып киткәндер. Ярый, сау булып тор. — Ул китәргә кузгалды.

Шунда яныбызга профком рәисе Юлдашбаев килеп җитте. Сакчыллык өчен әнә ул җавап бирә инде. Аның, Байтүрәне күргәч, кашлары җыерылды.

— Барлыбаев, син кайчан халык байлыгына үзеңнеке кебек карарга өйрәнәсең? Әллә коллектив җыелышына куйыйкмы? Ярый әле, кайтышлый цехка кереп чыгарга уйладым. Барып керсәм, утлар яна, станок кабызулы килеш. Берәрсе сменадан соң ашыгыч заказ үтәргә калганмы, дисәм, синең станок эшләп утыра. Нигә сүндермәдең?

— Җыелыш, дип, башымны катырдылар бит. Ашыккач, онытылгандыр инде. Йә, ярый, әллә нәрсә булмаган әле. Дәүләт аңардан гына ярлыланмас. Ярый, бигайбә, ашыгам, егетләр.

Ул китте.

* * *

Тик, шулай да, берничә көннән гадәттән тыш вакыйга булды. Тагын да эшләтеп кал-

дырып, Байтүрәнең станогына ут капты. Чак сүндереп калдык. Байтүрәне җыелышта тикшердек, китерелгән зыянны түләтергә, дигән карар чыгардык, бүләктән мәхрүм иттек, разрядын түбәнәйттек, стена гәзитенә сурәтен төшереп элдек. Шуннан тиз генә үз теләге белән эштән китү турында гариза язып, бездән шылды ул.

Хәзер кайда йөри икән? Сезнең оешмада түгелме? Бәлки, һөнәрен дә алыштыргандыр инде (йөзен дә үзгәртмәсә). Тик аны тануы авыр түгел. Сез аның өенә барыгыз да, хөкүмәт эшендә күзәтегез. Җир белән күк арасыдай аерма күрсәгез, шул үзе — безнең Байтүрә булыр. Тик тәртәгә кертә алырсызмы икән? Яшермибез, бездән булмады инде, егетләр. Ниндидер башка чара кирәк. Әйдәгез, бергәләп уйлашыйк. Бер баш яхшы, ә ике баш тагын да әйбәтрәк, диләрме әле? Җыелып, киңәш итик. Ә киңәшле эш таркалмас, дигәннәр борынгылар. Шул Байтүрәләрне отарлык җавап йөреше табылмасмыни?!

## МИН КАЙДАН БЕЛИМ?!

Һай, эттәгенәсе, кызык кешеләр бар инде бу фани дөньяда! Мине бигрәк тә үз-үзләрен белештермәгәннәре гаҗәпләндерә. Яисә үзләре булдыра алган эшне дә башкаларга йөкләтергә бик маһир булганнары. Ягъни кеше кулы белән ут көрәүчеләре. Менә, мәсәлән, бер-ике очракны карап үтик һәм үзегез уйларсыз — дөрес сукалыйммы мин, юкмы?

Эш бүлмәмдә телефон шылтырады, ди.

Трубканы күтәрәм, колагыма китерәм. Ә аннан шундый матур тавышлы бер хатын-кыз заты, йөрәккә май булып ята торган интонация белән, исәнләшеп тә тормастан:

— Але-е, кайда эләктем мин?—дип сорый. Билгеле, мин аптырап калам, ни дип җавапларга да белмим. Соң, бу хатынның кайда эләккәнен мин кайдан белим, ди?! Аннан битәр, кай төше белән эләккәнен. Үзе ныклабрак караса булмый микәнни? Бәлки кадакка эләккәндер, яисә урындык аягына, яисә өстәл почмагына... Дөрес, башы белән эләкмәде микән дигән шик-уй бар барын, тик кешегә ничек шулай дип әйтәсең. Инде мин бу хатынның адресын ачыклап, аны табып, кая һәм кай төше белән эләккәнен карап, әйтергә тиеш буламмы икән? Белмәссең... Аптырагач:

— Кая шылтыратасыз соң сез? — дип сорарга мәҗбүр буласың. Үзеңчә «юләрләр йортының кабул итү бүлмәсенә түгелме?» дигәнрәк мәгънә саласың инде тавышыңа. Шуннан соң гына матур тавышлы хатын: «Ә, не туда попала», — дип, трубканы куя. Ә кайда эләгәсе килгән иде икән соң аның? Шул юләрләр йортынадыр, ахры... дип үзеңне тынычландырасың.

Аннан хәтәррәк хәлләр дә булгалый. Трубканы күтәреп тә өлгермисең, теге баштагы кеше, синең колагыңны ярып:

— Фатир?! — дип кычкырып та җибәрә. Соң, мин аңа фатирны кайдан алыйм?! Үземә дә юк әле юньлесе — түбәсеннән су үтә, кыш салкын, җәй эссе, торбалары йә тишек — су ага, йә су чәпчим юк. Фатир кирәк булгач, әнә, тиешле кешеләренә шылтыратсын. Үзлә-

реннән артса, бирерләр. Артамы, юкмы, кайдан белим мин аны?!

Шактый четерекле сөйләшүләр алып барырга да туры килә. Трубканы аласың һәм сиңа шунда ук (исәнлек-саулык сорашу юк инде ул) өстеңә бер чиләк салкын су койгандай:

— Кем?! — дип сорау бирәләр. Фәкыйрегез тагын аптырашта: соң, мине әллә әүлия дип беләләрме болар?! Аның кем икәнен этләрем генә белмәсә. Шулай да, бер түрә галәмәте икәнен тавышыннан һәм сорау кую рәвешеннән сизенәсең инде сизенүен... Шуннан баш вата башлыйсың — кем соң әле бу? «Яңадан кабатла әле, бәлки тавышыңнан таныrмын»,— дип әйтмәссең бит инде. Тәрбия кушмый, аннан түрә халкы бик үпкәчел була, үпкәләтеп куйсаң, эшләрең харап, киттең булыр җибәргән җиренә туп-туры карап!

Ярый, монысы монысы булды әле ул. Кайберсе шылтырата да, эндәшми. Бу очракта инде тагын да зуррак аптырашта каласың. Заман башка — заң башка, дигәндәй, замана балаларының уены да башка шул хәзер. Әтиәни телефон үткәреп биргән, әйдә, уйна гына... Бәләкәйдән шулай өйрәнсәң генә түрә буласың инде: кечкенә чакта телефон аша кешеләр белән уйныйсың, ә үсеп түрә булгач (түрә баласы түрә булмый — кем булсын?!) телефон аша кеше язмышы белән уйный башлыйсың. Телефон аша законын да, хөкемен дә чыгарасың. Әнә шундый балалардан чыкмый микән әле ул үзенең кем икәнен башкалардан телефон аша белергә маташучылар? Менә монысын ачык әйтә алмыйм. Мин әүлиямени? Кайдан белим мин аны?

## МИН НИЧЕК ИМЗА ҖЫЙДЫМ

Халык төрлечә зарланган була, янәсе, заманалар авыр, еллар арык, акчалы дус кирәк дөнья көтәргә һәм башкалар, һәм башкалар. Дөрес, мин дә җөплим — авыр. Тик — аның урынына — элеккегә караганда мең тапкыр кызык. Мин элек тә җиңел яшәдек, дип әйтмәс идем һәм, өстәвенә, кызыгы да бик аз иде. Җиде кешегә бер ярты эчкән буласың шунда, концерты-мазары, дүрт елга бер сайлавы... Ә хәзерме... ә хәзер!.. Тормыш авыр, әмма кызык. Бер сайлау үтә, икенчесе җитә, анысын онытып бетерә алмыйсың, өченчесе!.. Менә кайда тамаша! Телевизорда депутатлар сугыша, монда исә кандидатлар белән очрашу арты очрашу. Халык йөри, нигә йөрмәсен, чөнки алар белә: депутат булып сайлансыннар гына, аларны кабат күрү түгел, эт белән эзләп тә таба алмыйсың. Йә Грециядә, йә Венециядә, яисә уптым илаһи Канар утрауларында. Тамаша инде, тамаша. Нинди генә гәзитне алма — тагын сайлау, кандидат, депутат, блок, партия, фирка... күп инде, күп. Сайламас идең — депутатларның яртысы чит илгә китеп беткән, алар урыны буш торсынмыни?!

Сайлаулар булмаса, ничек яшәр идек икән, дип аптырыйм. Һәм кайбер кешеләргә карап торам-торам да, бу аларга нәрсәгә кирәк икән, дип тагын бер тапкыр аптырыйм. Барыбер кулыннан да, теленнән дә бернәрсә дә килми бит инде. Әлеге дә баягы шул кызыгы өчендер инде. Тормыш казаны! Казан астына бераз коры утын да өстәсәләр — кайна да кайна гына! Депутат булып алып, икенче бер

депутатның колак төбенә ничек кундырганыңны телевизордан карап утыручылары үзе ни тора!

Аларны күзәтә торгач, минем башка да: «Ә мин кемнән ким?!» — дигән уй төшмәсенме?! Белеп әйтәләр икән, яхшы үрнәк кенә түгел, яманы да йогышлы, дип. Тукта әле, дим, болай читтән карап ятып булмас, бар тормышның кызыгы мине читләп үтә бит. Тиз генә биш-ун кешедән партия төзеп ташладым, шул фирка исеменнән үземне депутатлыкка кандидат итеп теркәлүгә куйдым. Монысы артык авыр булмады. Тик менә кандидат булып теркәлү өчен имзалар җыя башлагач кына сиздем үземнең нинди ахмаклык эшләгәнемне. Биш-ун кеше генә меңнәрчә имза җыя алмый икән шул. Меңәрләгән кеше эшләгән оешмага җитәкчелек иткән түрәләргә җиңел— күпме кеше эшли, барысы да имза куюга кандидат. Әмер генә бир. Коммунистлар фиркасенә дә рәхәт: аларның саны һаман шул ук — артмады да, кимемәде дә — унсигез миллион. Тәртип тә каты куелган. Каршы чыгып кара, хәзер демократ дип ярлык тагып, дөньяның бар этләрен сиңа өсләтәчәкләр. Әллә ике көн эчендә җыеп тапшырдылар, әллә өч... Безнең кебек шантрапалар гына йөри шунда чабышып, чиләктә давыл кубарырга тырышып...

Тик, эзләсәң, һәр явызлыктан изгелек табарга була, диләрме әле? Таптым бит тәки мин дә юлын! Ничек, дисезме? Ә шул ук, үзем кебек бичара кандидатлар, имза җыючылар коткарды. Хәзер бит тоташ ил — чирек кандидат, яртылаш депутат, бер бөтен имза җыючы. Ә алар әрсез чегән кебекләр: эштәге бүлмәгә дә бәреп керәләр, урамда да туктаталар,

фатир ишегеи төшке аш вакытында гына түгел, төнге уникедә дә килеп шакыйлар. Ярый мин башымны тиз эшләтеп калдым. Һәрберсенә шундый шарт куям: син — миңа, мин — сиңа! Заманы шундый, егетләр. Теләмисең икән — тәртәңне кире бор, синең кебекләр чебен урынына оча монда. Китте бит эш хутка: көненә, ким дигәндә, ике-өч йөз имза куям, шулкадәр үк алам. Һай, болай гына сизелми икән ул кандидатларның күплеге! Ә минем кара исәп буенча — бер урынга, аз дигәндә, — утыз тугыз кеше туры килә, имеш! Булсын, әйдә, аннан миңа ни зыян. Кандидат булып теркәлсәм, шул җиткән. Барыбер тик мине генә сайлаячаклар.

Тиешле биш мең имзаны җыйдым бит тәки. Кандидат булып та теркәлдем. «Бу сайлаулардан, бер көтү кандидатлардан ни файда», — дигән булалар. Кемгә ничектер, ә миңа файдасы хәзер үк — әле депутат булып сайланмас борын ук тиде. Шул имза җыю турында әйтәм, ә сайлаучылар белән очрашу вакытында тигән утын яркасы турында түгел. Аның да сайлаучылыкка кандидат түгел, ә үзебезнең брат — депутатлыкка кандидат томырды... Ә сайлана калсаммы?! Анда файдасын чыгарам тәк чыгарам инде! Чит илләрнең барысын бер итеп йөриячәкмен. Салым түләүчеләр генә үлеп бетмәсен.



## КУЫП ҖИТӘРБЕЗ...

Шаккатам: элек нинди томана булганбыз! Билгелелек һәм үзгәртеп кору елларында, ниһаять, күп нәрсә аңлашылды һәм ачыкланды. Безнең илдә хәтта торак та җитмәгән икән. Төзибез, дип, күпме күкрәк суккан булдык... Тик өметне дә өзеп бетерергә ярамый икән әле: бераз тырышканда, ташка кадак какканда, бу мәсьәләне ике меңенче елга ерып чыга алабыз, имеш. Ә нигә, булмас, димә. Әгәр инде ошбу вакытка бу вәгъдәбез дә куык очыру гына булып чыга икән, монда да рапорт бирергә сүзләрен табарбыз. Һич югы, моңа комачаулаган сәбәпләр турында. Анысын гына булдырабыз тәк булдырабыз инде. Беренче һәм соңгы тапкыр түгел бит. Заманында хәтта Американы да куып җитеп узып китәргә маташтык. Ил белән шулай йөгереш сукмагына чыккан идек. Хәзер ул спортчылар кайда икән дип, мин берсекөн, урыс әйткәндәй, справка наводить иткән идем, шул ачыкланды: бүген йөгерешчеләрнең күпчелеге дару сәдәбе ярдәмендә генә яши икән, ә шактые җантәслим кылган. Әйдә, җаннары җәннәттә булсын, заманында, һай, ничек котларын алган иделәр американнарның.

Шулай, күп нәрсә беләбез хәзер. Әттәгенәсе, без, имеш, һава суламыйбыз, ә агулы матдәләр йотабыз. Кайчандыр зәңгәр булган күгебез дә хәзер соры төстә икән. Аны, кем тели, шул агулый, ди. Ярый әле күзебезне ачтылар, белми үлеп харап була язганбыз. Хәзер белеп үләчәкбез инде, ягъни, мәсәлән... Чәчүлекләребез дә хәзер пестицидлар, гербицидлар, минераль ашламалардан гына тора,

бер чеметем кара туфрак юк, ди. Икмәктә, яшелчәдә, сөттә, иттә — йә нитрат, йә нитрит, имеш. Химия генә түгел, физика да хәзер кешелек бәхете, тынычлык өчен эшләргә теләми, буза куптарган, ди. Кешеләр атомны таркатканнар да, хәзер шуны җыеп ала алмый иза чигәләр икән, ул үзе безне өзгәли башлаган! Әстәгафирулла! Тәүбә! Әллә бар нәрсә безгә каршы чыккан инде, аптыраганнан радиактив күлгә артың белән чумарсың: тимер юлларда поездлар шартлый, вагоннар рельстан читкә сикерә, ди. Самолетлар тиктомалга һавадан егылып төшә. Диңгез, океаннарда кораблар кешене тыңламый йә маңгайга маңгай сөзешә, йә, ике дә уйлап тормый, су төбенә китә. Хәтта елгалар, «кирегә агарга телибез» дип, галимнәргә катгый таләп куйган, имеш. Ничек кирәк алай гына уйларыннан кире кайтара алганнар. Шулай да плотиналарны җимереп, ара-тирә баш күтәреп алалар, кешеләрне дә агызып алып китәләр икән. Аннан, кайдандыр ачлык дигән коточкыч афәт безнең илгә килергә чыккан, ди. Көрәшеләр алда икән.

Шуңа әйтәм әле, арытаба да болай барса, нигә «ике меңенче елга һәр гаиләгә — аерым фатир» дигән лозунгны хәл итеп булмасын, ди. Берсүзсез хәл итәрбез. Бары тик һавага газлар очыру, химикатлар, агулар чыгару күләмен, һәлакәтләр санын үткән елга караганда ике тапкыр, юк, өч, дүрт тапкыр арттырырга гына кирәк. Моңа һәркем үз өлешен кертә ала. Әллә ни күп көч түгәргә дә кирәкми: бары тик берсүзсез тыңлап, нәрсә әйтәләр, шуны үтәп, түшәм ишелерлек итеп кул чабып, баш кагып, тавыш биреп тору да җитә. Шулай итсәк, һичшиксез үтәләчәк бу бурыч.

Кемнәргәдер бәләкәйрәк «фатир» туры килсә килә инде — ике метр тирәнлегендә. Тик ни хәл итәсең — көрәш корбансыз булмый. Тулысынча үлеп бетү дә кирәкми. Яртысы оҗмахка күчсә, исән калганнар — һәрберсе! — фатирлы була. Икешәр, өчәр дә эләгүе ихтимал әле. Менә шунда Американы узып китәбез тәк китәбез инде, Аллаһы Тәгалә боерса.

Тик узып киткәч, безнең ялангач артны күрмәсеннәр өчен капларлык берәр нәрсә хәстәрләп куярга гына онытмаска кирәк. Һич югы, депутатларның кандидат чакларында тараткан программаларын.

## ЙӨРӘК ӨЯНӘГЕ

Шифаханәнең баш табибы Әрдиев соңгы вакытта аптырашка калды. Шифаханәгә берәмләп тә, төркемләп тә урындагы эреле-ваклы җитәкчеләр дәваланырга кереп тулды. Барысының да диагнозы — йөрәк өянәге. Аптырарлык та шул: ачлы-туклы, очын-очка чак ялгап яшәгән, сәгатьләр буе чиратларда торган, кибеттән кибеткә арзанрак хакка әйбер эзләп чапкан, ике-өч ай хезмәт хакы ала алмаган, нервылары соңгы чиккә җитеп киеренкеләнгән гади халык түгел, ә тук тормышлы җитәкчеләр авырый. Әллә бу төр авыруларга «кибеттән кибеткә чабарга», дип рецепт язаргамы? «Хәрәкәттә — бәрәкәт» дип халык белми әйтмәс. Тик Әрдиев бу авыруның телевизордан тапшырылган бер рекламадан соң башлануын белми иде шул. Ә барысы да база мөдире Хәбировның кирәкле кешеләргә телефоннан бер шылтыратуыннан соң башланды.

Базага вагоны белән арзанлы ит консервасы кайтып төште. Үзе чит илнеке. Кемгә шылтыратсын соң инде Хәбиров, язылмаган канун буенча, шул «кирәкле кешеләр»гә шылтыратмый? Бераздан «кирәкле кешеләр»нең шоферлары килеп тулды, тартмалап та, уптым да алдылар — җитәкчесенең комарлыгына карап инде. Башка таныш-тонышларга да өлеш чыкты. Билгеле, исем өчен бер-ике тартма кибеткә җибәрделәр — ашасын, әйдә, гади халык та. Заслужили.

Ит консервасы болай ару, тәмле генә булып чыкты. Чит ил капиталистлары эшли белә инде ул, тизәктән дә кәнфит әвәлиләр. Итле консерваны аш белән дә, табада кыздырып та ашадылар, кунак-мазар килеп төшсә, табынның иң уртасына куйдылар. Нигә, алар башкалардан киммени?! Ким булу кайда, хәтта артык та әле.

Арзанлы чит ил консервасы ашалып бетүгә, телевизор экраннарында: «Ваша киска купила бы вискас!» дигән реклама күренә башлады. Йөрәк өянәге кизүе әнә шулай башланды. Тик Әрдиев моны белми иде әле.

...Әрдиев эшеннән кайтып тамак ялгагач, кәнәфигә кырын ятып, телевизорны кабызды. Бик матур тапшыру бара иде. Тик бераздан күңелле көй астында мәчеләр чабыша башлады. Хуҗалары аларны ит консервасы белән сыйлый икән. Шунда Әрдиевның колагына «вискас» дигән таныш исем килеп керде. Аннан матур итеп эшләнгән савытын да күрсәттеләр. Әрдиевның хатыны әле кичә генә суыткычтан соңгысын алып аш пешергән иде. Аһ! Әрдиев кинәт, йөрәген тотып, бөгелеп төште, Шифаханә палатасында яткан таныш йөзләр

күз алдыннан үтте. Әх, явызлар, яхшылыкның кадерен белмәүчеләр, әйтмәделәр дә бит, эчмасам... Хәер... бер уйлаганда, нинди район түрәсе сиңа: «Мәче консервасы ашаганны белеп, гарьләнеп, йөрәк өянәге тотты», — дип сөйләп йөрсен инде. Һы-һ! Әрдиев һушын югалтты. Бераздан, яман сызгыртып, «Ашыгыч ярдәм» машинасы килеп җитте, шулай ук, ачы сызгыртып, хастаханәгә таба чапты...

Инде азрак хәл ала башлаган авырулар аны:

— Пароль? — дип каршы алдылар.

— ВКҚВ — ваша киска — купила бы вискас, — дип хәлсез генә җавап бирде Әрдиев.

— Үт, әйдә, үт, үзебезнең кеше, — дип палата ишеген ачтылар.

Ә Хәбиров икенче көнне «үз теләге» белән базадан эштән киткән иде инде.

## ҚЫЯР

Кичә күбрәк төшерелгән, каһәрең, баш авыртуы бүгенгә дә бетмәгән. Шофер халкының гадәтенә кергән шул инде — рейстан кайткач, гаражда өч-дүрт шешәне бушаткач кына өйләренә кайтып китәләр. Нигә, Таһир башкалардан калышмас бит инде. Эше дә төшемле — уңнан да, сулдан да кереп тора, утыргыч астында яткан шешә эчендәге сыеклык, «бүл-бүл» итеп, аппетитны тагын да котырта... Ярый, кичәгесе кичәге инде ул, үткән эш. Тик менә бүген эш хөртрәк. Аракы да, акча да юк. Үч иткәндәй, ял көне. Сөйгәне Зөһрә янына күрешергә дә барырга кирәк. Бармый

кара, хәзер тикшерү башланачак: кайда йөрдең, кем белән булдың, фәлән-төгән, фәсмәтән... — әйтерсең, никахлы ире, ачуы да килмәгәе. Кочагына кертсә бер хәл иде, «өйләнгәч, өйләнгәч», дип гел кире кагып тора. Өйләнгәч аның кызыгы буламыни, менә хәзергесе... Өйләнергә Таһирның үзенең дә исәбе бар ул, тик бераз шүрләтә генә. Хатын-кызны аңламассың. Алар, кыз чакларында, барысы да әйбәт.

Шулай караватта «аһ-ваһ» итеп, уяулыйокылы көне буе аунагач, егетебез, караңгы төшкәч, очрашуга китте. Берәр җае чыкмасмы, дип, чалбар кесәсенә, полиэтилен капчыкка урап, бер кыяр да тыгып алды. Кайчак кабымлык сорап йөрүчеләр дә очрый, аңа да бер йөз грамм өлеш чыгарырлар, бәлки.

...Киногa барганда, аннан кайтканда җанашына махмырдан икәнен сиздермәскә ничекләр генә тырышмады. Шуның нәтиҗәсе буларак, башы тагын да ныграк авырта башлады. Таныш-белеше дә очрамады, очраса да, йә исерек, йә үзләре соранып йөрүчеләр генә. Башын тәки «төзәтә» алмады.

Кайтып җиткәч, койма буенда шулай дөньясын каһәрләп, Зөһрәсен кочаклап басып торганда, Таһир җылыга эреп киткән. Зөһрәсе дә нигәдер тынып калган, нинди уйга баткандыр, белмәссең.

...Таһир төш күрә. Имеш, Зөһрәсе ап-ак күлмәктән. Туйларыдыр, ахры. Менә кәләше, елмаеп-көлеп, аңа мөлдерәмә тулы стакан суза: «Әйдә, башыңны төзәт тә, тизрәк юрган астына чумыйк!» — ди, имеш. Таһир, йотлыга-йотлыга, стаканны каплап куя да, кызны

каты итеп кысып алып: «Их, Зөһрәкәем!» — дип, ап-ак җәймәле урынга ава башлый.

...Чынлап да, егет, йокысына исереп, төшне өн белән бутап, кызны каты итеп кысып алган, «Их, Зөһрәкәем!» — дип кайнар пышылдап, җиргә авып бара, имеш. Ярый бер яктан койма, икенче яктан Зөһрә тотып калган. Шунда гына егет уянгандай булды. Тик хәзер икенче четерекле мәсьәлә килеп туды. Кесәдәге кыяр, каһәрең, егет белән кыз арасында калып, каты кысылудан изелгән, суы капчык аша агып чыккан (анысы тишек булгандыр инде, яхшылап карап торырга аның вакыты булдымыни), чалбарын юешләткән, юка күлмәк аша кызның тәненә дә үткән. Йә ашыйсы, йә ташлыйсы булган икән. Хәзер ничекләр генә кыен хәлдән чыгарга?! Баш авыртуына инде монысы өстәлде. Җитмәсә, егет, кабымлыкка булгач, өч-дүрт кешегә җитсен, дип, кесәсенә кыярның иң юанын, иң озынын сайлап алган иде — якынча бер егерме-утыз сантиметрлысын. Билләһи газим.

...Ә кыз бу көтелмәгән хәлдән өнсез-тынсыз катып калды. Тик ул кыяр хакында белми һәм, билгеле, уйлары бу гөнаһсыз яшелчә хакында түгел иде. Аның тәне буйлап эссе дулкын йөгерде, йөзенә кайнар кызыллык бәрде, күз аллары караңгыланды. Башыннан бер секунд эчендә йөз уй чагылып үтте. Егет һәм кыз һаман әле кысып кочаклашкан килеш басып торалар иде. Кыз шунда дулкынландыргыч, назлы һәм серле, үзгәреп киткән тавыш белән егетнең колагын пешерерлек итеп, ишетелер-ишетелмәс шыбырдады:

— Сиңа... кирәкменмени?

Махмырдан башы ватылып барган, мие

кайнаган егет моны ялгышрак ишетеп, йөрәге туктагандай булды. Ни ди?! «Сиңа кирәкмени?» — диме?! Йә, Хода, таштан да юкә суелыр икән! Ташның да йөрәге бар микәнни?! Һәм ул бертында, кыз кире уйлап куйганчы, дип, әйтеп салды:

— Бармыни?!

Көтелмәгән сораудан кыз яңадан өнсезтынсыз калды...

Ә арытаба вакыйгалар күз ачып йомган арада диярлек булды. Кыз егетнең чигәсенә чылтыратып берне саллы гына чәпәде дә, йөзен куллары белән каплап, елап, йөгереп кереп китте. Ә тез буыннары болай да бушаган егет, көтелмәгән һөҗүмнән җиргә үк барып төште. Шул бетмәгән бер кыяр булды бит: аста калып, изелеп, тагын суы акты.

Аягына баскач, изелеп беткән кыярны кесәсеннән тартып чыгарды. Читән аша томырырга булган иде дә, кире уйлап, зур кабып, бер тешләп алды, аны үткен тешләре белән акрын гына чәйни-чәйни, уйланып, өенә таба атлады. Кабымлыгы бар да ул, тик менә берәр йөз граммы да булсын иде аның...

## ТИМЕР РӘШӘТКӘ

Рамай бик каты башы авыртып, тамагы чатнап кибеп уянды. Кичә кайда, кемнәр белән шулкадәр эчте соң әле ул? Күпме генә тырышса да, хәтеренә бернәрсә дә килмәде. Соңгы вакытларда хәтере начарланганын үзе дә сизенә. Тик бу кадәр булганы юк иде. Тагын ак аракыны сыра белән бутап, «ерш»

эшләгәннәрдер, ахры. Баш авыртуы шуңа тарта. Күп булганга да охшаган. Их, берәр стакан кайнар чәй... Тик кулын кузгатырлык та хәле юк. Хатыны өйдәме икән? Рамай эчеп кайтып буза кубара башласа, чыгып китеп, танышларына барып йоклый торган гадәте бар. Тагын өйдә нәрсәләрне кырды икән инде? Эчсә, үзенең дә холкы начар шул. Хатынына Ходай ярдәм бирсен. Шулай да, хәләл җефетенә эндәшеп карарга булды: бәлки, кичә бернәрсә дә булмагандыр, исән-имин генә үткәндер.

— Сәкинә... Сәкинә...—дип ыңгырашты ул хәлсез тавыш белән, аңкавына ябышкан телен чак әйләндереп. Тик җавап бирүче булмады. Әх, чәнчелгере, кичә тагын нинди «батырлыклар» күрсәтте икән? Әллә бик каты йоклыймы? Шуңа тагын бер тапкыр бәхетен сынап карарга көч тапты.

— Сәкинә! — Инде тавышы көчлерәк чыкты. Тик нәтиҗәсе генә булмады — шул ук кабер тынлыгы. Их, уңмады шул хатыннан! Башкаларныкы хатын кебек, ә аныкы — чи утын кебек. Их!.. Рамай бар көчен җыеп, торып утырды, күзләрен ачты. Һәм... ник ачканына үкенде — таң сарысы сирпегән тәрәзә... тимер рәшәткәле иде! Дә, булган бу болай булгач! Айныткычка гына эләгәсе калган иде. Үзе килеп каптымы, әллә хатыны милиция чакырттымы? Моңа кадәр алай кылганы юк иде. Әх, сабакы хатын, сабакы хатын!.. Хәзер эштә ничек кеше күзенә күренер, түрәсе нәрсә дип әйтер? Вазифасында урләү мөмкинлеге дә бар иде, фатирга да чират җиткән. Их, егетләр, арбаны кем дегетләр! Юләр дә инде бу хатыннар, бер утырып уйласаң. Янә-

се, төрмәгә тыга, акылга утырта, ә унбиш тәүлек утырган өчен акча барыбер гаилә бюджетыннан чыга бит, зыянны химаячеләр капламый. Их, Рамай, үзең дә исәр инде. Нигә генә эчтең кичә? Их, бичә! Нигә генә өйләнде шуңа яшь чагында?! Аңардан ун тапкыр уңганрак, чибәррәк кызлар үзләре муенына асылынып йөрде. Камилә үзе генә ни тора иде! Чәче җирән дигән булды. Булмагае, чурт булсын икән. Әнә, хәзер барсы да җирән, җиренгә буяту өчен акча түлиләр әле хәтта. Их! Эх! Их-ма! Терсәк якын да бит, тик тешләп булмый. Менә утыр инде хәзер кутузкада. Шундый-шундый хәлләр, тора-бара нишләр, дигәндәй. Хатыны — хатын әле аның, килешеп булыр. Егерме биш ел бергә яшиләр, төрлесе булды, монысында да ярашырлар. Ә менә эштә ни диярләр. Хезмәттәшләре турында уйламый әле ул. Алар — аңлар. Ә Фәрхи Шәмиевич... Ай-һай, ничек күзенә күренер икән? Гафу итмәячәк, юк. Моңа кадәр гел үрнәк итеп куя иде. «Их, син, Рамай, өметемне акламадың, инде үз юлыңны үзең кара», — дияр. Фәрхи Шәмиевичның җылы канаты булмас. Хәзер барсы бетте. Менә шушы буладыр инде ул үзең утырган ботакка үзең балта чабу... Хет муеныңны элмәккә тык. Рамайның урыны начарлардан түгел иде. Җылы дисәң дә була. Акмаса да, тамып торды моңа кадәр. Менә хәзер тамар инде. Эх, җилкә тамырыңа тамызырлык синең, Рамай!

Шунда кемдер ыңгырашып куйды. Авырлык белән генә башын борып карады. Идәндә тагын ике кеше йоклап ята. Болары да, Рамай кебек, шундый ук бәхетсез Алла бәндәләре... Тик Рамайга моңардан җиңелрәк

түгел. Кешенеке — кештәктә, үзеңнеке — үзәктә шул. Рамайның тагын үзәге өзелеп китте. Эх, бәхеткәйләрең бер йокласамы!

Ярар, буласы булган, буявы уңган, диләрме әле? Бер йотым су булсын иде хәзер. Милиционерлар да кеше баласы бит, нүжәли бер стакан су бирмәсләр? Ишекләре кайдарак икән соң боларның? Әнә тегендә бернәрсә агарып күренә, шулдыр. Рамай караваттан шуышып төште, дүрт аяклап ишеккә китте. Тик шунда гына игътибар итте: киемнәре — өстендә, аяк киемен дә салдырмаганнар. Әйтәм бит, милициядә дә миһербанлы бәндәләр эшли, дип. Ә халык сүккән була тагын.

Ишеккә шуышып килеп җиткәч, тотынып, аягына басты, йодрыгы белән ишекне төя башлады:

— Иптәш милиционерлар, пажалысты, ачыгыз әле, су гына бирегез! — Тавышы сүрән чыкса да, йодрыклары үлгән кешене уятырлык тавыш кубарды. Тик җавап кайтаручы гына булмады.

— Ачыгыз, дим, үтерәсез бит кешене сусатып! — Инде монысында теге якта кемдер кыштырдады, иптәшләре дә баш калкытты. — Ачыгыз, югыйсә, ватам!

Кинәт ишек ачылып китте. Тик милиционер урынына хатын-кыз кыяфәтендәге, чәчебашы тузган албасты басып тора иде. Рамай, шикләнеп, артына чигенде.

— Нәрсә кычкырасың, адаштыңмы әллә? Яки юләрләнә башладыңмы? Шулкадәр эчсәң, исәрләнерсең дә шул. И-и, Ходаем, җир дә йотмый бит, ичмасам, шушы алкашларны! — дип сукранды теге албасты Сәкинә тавышы белән. Рамай азрак айныгандай булды.

— Их, бәгырем, Сәкинәм, — дип Рамай, шатланып кычкырып җибәрде. — Сине дә яптылармыни?!

— Кайда яптылар? И-и, Ходаем, әйтәм бит, чынлап юләрләнә башладың инде әллә? Кайда япсыннар сине, кемгә кирәгең бар синең?

— Нигә, мин айныткычта түгелмени?—Рамайның күңелендә өмет чаткылары кабынды.

— Кара, сиңа ак махмыр булган түгелме соң? Чынлап та, шылтыратырга кирәк әле. Юләрләр шифаханәсенә.

— Юк, юк! Аптыраганнан инде анысы. Ә нигә тәрәзәләр рәшәткәле? Төрмә түгелмени бу?

— Соң, алыпсатар Сәхидән күреп, кичә үзең тәрәзәләргә тимер рәшәткә алып кайттың, әллә кемнәрне алып килеп, көне буе шуларны урнаштырдыгыз. Әллә ун ярты аракы эчеп бетердегез, әнә, кайта алмый, бездә йоклап калдылар. Уят, хатыннары югалткандыр. Чәй эчереп, чыгарып җибәрик. Тимер рәшәткә, имеш. Аракы эчкән кешенең нәрсәсен урлыйсың инде аның, буш шешәләренмени?

— Их, бәгырем, Сәкинәм,— дип Рамай, гомердә булмаганны, хатынын кочаклап үбеп алды. Сусаулары бетеп киткән кебек булды.

Тимер рәшәткә куючы осталар, аннан-моннан гына чәй эчештереп, тизрәк ишеккә юнәлделәр. Кичтән бер генә тамчы да калмаган, каһәрең. Рамай аларны озата чыкты. Сүзсез генә тәмәке кабыздылар.

— Баш чатный бит әле, — диде Сәпи исемлесе, авыр уфтанып.

— Берәр нәрсә юнәтик, булмаса, — диде икенчесе, бераз җанлана төшеп.

— Зыян итмәс иде дә ни... — дип, икеләнебрәк, аларга Рамай да кушылды.

— Кая, кемдә күпме бар, брат башына берәр яртысыз булмас монда, — дип, Сәпи йөгәнне үз кулына алды.

Тиздән өчәү, бераз чайкалгалап, кибеткә таба юрттыра иде инде. Рамайның да әле күптән түгел кичергәннәре хәтереннән бөтенләй чыгып очкан, ахры. Әйтерсең, вөждан газаплары булмаган да. Әйтәм бит, соңгы араларда хәтере бөтенләй начарайды, дип. Хәерлегә генә була күрсен инде.

## КИЕМ КОТЛАТУ

Элек без бәләкәй чакларда, әнкәй берәр яңа кием-салым алса, аны тиз генә киеп алып, күршеләргә йөгереп керә идек. Алар синең нигә кергәнеңне бер күз ташлау белән аңлап ала.

— Уһу-у, күрше малае яңа күлмәк кигән түгелме соң? Кем алып бирде? Котлатырга кердең инде, ә? — дип, хәтта үз балаларыннан яшергән берәр уч кәнфитне кулга тоттыра. Шулай бар тирә-як күршеләрне урап чыгасың. Һәркем байлыгына, яисә юмартлыгына карап, синең сөенеч белән уртаклаша.

Тик сабый чаклар тиз уза, аның бәйрәмнәре дә бары хәтерләргә бер якты истәлек булып кына кала. Кайда ул хәзер яңа кием сатып алу, искесен караңгы почмакта салдырмасалар. Кием-салым сатучылар ике йөз-өч йөз мең сум, дип кенә җиффәрәләр хәзер. Эшләп тапкан акчаң тамак туйдырырга җитмәгәндә,

нинди тун, яхшы итек, модалы күлмәк, ди ул?! Шулай да, байлар аладыр инде ул, әнә бит урам тулы халык энә-җептән яңа төшкән күлмәк-чалбардан. Дөрес, барысы да чит илнеке. Кияренә булмаганы өендәрәк утыруны хуп күрәдер, ахры. Менә минем кебек.

Әтнәке, ярлылар да яңа кием-салым ала икән әле. Бүген танышыбыз Мәстүрә килеп кергән. Тупса аша үтүгә яңа күлмәге белән мактанырга тотынды.

— Ике ай икмәк-суда утырсам утырдым, яңа күлмәк сатып алдым. Менә сезгә котлатырга кердем, — ди үзе.

Балачакның хатирәләре яңарды. Кара, онытмаган кешеләр дә бар икән әле. Йоласы буенча котлап нәрсәдер бирергә дә кирәк бит инде. Тик, үч иткәндәй, кәнфите дә юк. Бер ел үзем түгел, балаларның да авыз иткәннәре юк. Бакыр-көмеш акча да басмыйлар хәзер. Тик, ни хәл итәсең, йоланы бозып булмый.

— Күлмәгең котлы булсын, кадерен күр, җылы тәнеңдә тузсын, — дип, электр чәйнүгенең берсен биреп чыгарырга туры килде. Юк, кызганмадым. Күрше шатлыгы — минем дә шатлык инде ул.

Бездән чыккач, Мәстүрәнең сул күршеләргә кереп киткәнен күреп калдым. Маладис, Мәстүрә, халкыбызның йоласын саклап калу артыннан йөри икән. Болай булса, бетмәбез, дошманнарга үч итеп — яшәрбез!..

Икенче көнне Мәстүрәнең байтак кына кешеләрдә булып, күлмәген котлатканын ишеттем.

Бер-ике айдан Мәстүрә тагын килеп кергән. Монысында импортный итек сатып алган

икән. Итеген котлап, сөенечтән чәй сервизын кулына тоттырдым. Мәстүрәнең дә куанычы йөзенә чыкты, күңеле тулып, бер чынаякны төшереп ватты. Икенчесен бирергә туры килде.

Мәстүрә шулай башка вакытларда да кергәләп йөрде. Буш кул белән чыгармадым — йоласы шундый булгач. Кием котлатучы хакы — Алла хакы. Аңардан гына хәерчегә калмабыз әле.

Тик беркөнне бу кием котлатуның сере ачыла төште.

Балаларга берәр кием-салым табып булмасмы дип, базарга юнәлдем. Булса шунда инде, булмаса — юк. Карасам, миннән алдарак Мәстүрә бер хатын белән сөйләшеп бара.

— Яхшы тормыштан түгел инде болай йөрү дә. Ничек кирәк алай табасың да, базарга чыгарып сатасың. Яшәргә кирәк бит, ачтан үлеп булмый, — ди Мәстүрә. Ә үзе хан хатыннарыннан ким киенмәгән. Дөрес, яхшы киенгән кеше дә ач булырга мөмкин, байлар да елый икән ич әнә...

Этешә-төртешә автобустан төшкәндә Мәстүрәне күздән яздырдым. Базарда ары-бире сугылып йөри торгач, «Товарлар — халыктан» дигән кече предприятие кибетенә килеп юлыктым. Уһу, монда нәрсәләр генә юк — энәсе дә, дөясе дә, дигәндәй. Миңа кирәк булган балалар киеме дә эленеп тора. Электр чәйнүкләре, чәй сервизлары, телевизорлар, яхшы хатын-кыз итекләре, өстәл-урындык, карават, вак-төяк әйбер белән кибет шыплап тулган. Тик сатучысы гына күренми. Тукта әле, базарны бер урыйм, бәлки анысы да килер дип, ары киттем. Базар шундый ук кибетләр белән тулы, аягүрә басып сатучылар да җитәрлек. Тик

хаклары гына «тешләшә». Шулай да, алучысы да бар. Халык бай инде ул безнең. Сатучысы гына булсын, алучысы һәрчак табыла. Барысы да, минем кебек, соңгы акчасын җыеп алып чыгамы, әллә... Аптырап йөри торгач, тагын теге кибет янына килеп чыкканмын. Анысы да ачык, сатучы бик җитез алыш-биреш итә. Ни күрим, Мәстүрә түгелме соң бу?! Шул бит! Тик ясалма чәч киеп алган — кызык өчендер инде...

— Кара әле, Мәстүрә, син түгелме соң бу? — дисәм, танымаганга салыша.

— Хөрмәтле сатып алучы, сез мине кем беләндер бутыйсыз, ахры, — дигән була. Ясалма чәч киюе генә җитмәгән, йөзенә ыштыр да каплаган икән, оятсыз. Шулай да эндәшмәдем. Киштәдә торган әйберләр арасында үземнең электр чәйнүген, чәй сервизын, балалар арбасын һәм башкаларны таныгач та, телемне тешләдем. «Сез» дип сөйләшә бит, каһәр. Яхшы мөгамәләсе белән тереләй суйды, кяфер. Моңа кадәр ишеткән булмагач ни...

Барыбер балаларга кием алып булмады, егетләр. Ничәдер мең дигәч, башым әйләнеп, күз алларым томаланып, балалар пальтосы урынына үземнең электр чәйнүген сатып алып чыгып киткәнемне дә абайламаганмын...



## МАЛАЙЛАРГА БИРГЕСЕЗ

Гомер буе «малай, малай» дип теше төште Хәбир абзыйның. Тик хатыны Хәтирә, әллә аңа үч итеп, әллә нәрсә эшләгәнен үзе дә аңламый, бала тудыру йортыннан ел саен кыз алып кайтты. Әниләре белән дүртәү булып киттеләр берзаман болар. Өй эчен хатын-кыз басты, ул чыр-чу, ыгы-зыгы. Шуңадырмы, дөньясына үч итеп, Хәбир абзый атна саен булмаса да, айга бер тапкыр хәләл җефетенең тузаннарын каккалап ала торган иде. Андый көнне бар хатын-кыз заты өйдән «фыйт!» итә. Итәкләре генә җилфердәп кала, малай, мин сиңайтим! Һай, кызык заманалар була торган иде. Ну-у, «иде» дип ни, әле дә булгалап ала ул, Аллага шөкер. Нинди генә Указлар чыкмасын, Хәбир абзый кебек оста куллы егетләргә тамак төбен чылатырга җай бетәмени! Бетми торсын әле, малай! Указ чыгаручылар, әнә, үзләре күптән тәхетләреннән чәнчелде, ә Хәбир абзыйлар да, хәмер сатучы кибетләр дә гөрләтеп яши бирә.

«Малай, малай!» дия торгач (безнең якта шулайрак сөйләшәләр инде: «ул тап» яисә «улы туган» түгел, ә «малай тап», «малае туган», диләр), Хәбир абзый үзе дә җөмлә саен шул сүзне кыстырып сөйләшә башлады. Аларны тел белгечләре «паразит сүзләр» дип атый. Мәсәлән, менә болайрак яңгырай ул:

— Китеп барам шулай, малай, ни күрим, малай, синең кәҗәң минем бакчада йөреп ята, малай. Таш белән тондырам, малай, ыжлап та бирми, малай. Мылтык алып чыгып, атып егарга туры килде, малай. Ачуланма инде, малай, күршеләр бит без, ничек тә килешер-

без әле. Әнә, минем сарыкны алып чык, йә, булмаса, мә, мылтык, атып ек, малай. Күрше хакы — Алла хакы инде ул, малай. Бар, пычак алып чык, әйдә, тиресен туныйк инде, малай...

Боларны кызык өчен генә яза икән бу, димәгез, андый хәл дә булып алды Хәбир абзыйның тормыш сәхифәсендә. Дөрес, күршесе бер гаепсез сарыкның җанын кыймады. Шундый ук мамык йонлы кәҗә сатып алып бирергә туры килде. Мылтыгын милиция алып калды. Унбиш тәүлектән чыккач та бирмәделәр. Башка вакытта акча гына түләтәләр иде, монысында мылтык та китте. Әйдә, игелеген күрсеннәр. Ул «кәҗә вакыйгасы» да шул хатын-кыз аркасында булды, мөртәт. Хатынын «Атам!» дип куалап йөртә торгач, тегесенең кайсы күршеләренә кереп качканын шәйләми калды. Шунда күзенә чалынды да инде мәлгунь кәҗә. Ә хатынын болай гына, куркыту өчен генә куалаган иде. Аны атса, теге өч кызны ничек тәрбияләсен, үстерсен, ди ул. Малайлар булса бер хәл иде...

Алай да кеше алдында бик сер бирергә ярата торган кешеләрдән түгел Хәбир абзый. Берәрсе тел чарларга чамалый башласа:

— Нәрсә миңа синең малаең, минем кызлар үзләре малайларга биргесез! — дип кенә җиффәрә торган иде.

Чыннан да, малайларга биргесез шук булып үстеләр кызлары. Курку дигәнне белмәделәр. Һе, кем кызлары соң?! Сигез сыйныфны тәмамлап тордылар, калага шуа тордылар. Кемнән күреп үскәннәр, диген, тәмәке тартырга, аракы эчәргә өйрәнеп алганнар, малай. Фильтрлысын тартсалар бер хәл иде —

ара-тирә ял көннәрендә авылга кайткан вакытларында әтиләренең «Астра» сигәритен урларга да оялмыйлар, малай. Кая бара бу дөньялар, ахырзаман җитүе шулмы икән инде? Хәбир абзый аларны «тәмәке тартыгыз, аракы эчегез» дип өйрәттеме? Ул гына түгел, чәч-башларын тузгытып, авыл егетләренең матаенда урам буйлап чабу дисеңме, бергә җыелышып алсалар, малайлардан уздырып, хахылдашып көлешүме, бергәләп тәмәке тартумы — берсе дә калмый. Киемнәре дә ир-атныкыннан аерылмый бит әле — шул зәңгәр киндер чалбар, куртка, маңгаена инглизчә язылган кипке. Егетләр кочакларга маташканда качу түгел, үзләре муеннарына асылынып, авызларына кереп баралар. Ата-анадан курку кайда, күзеңә карап:

— Хәзер заманы шундый, мы — девушки без комплексов, — дип кенә авызын томалыйлар, малай. Анысы нәрсә буладыр.

Анысы — анысы әле ул. Монысы да булган икән.

Бер көнне шулай «кыздырып» кайтып, энеләре белән бергә дүртесен «туздырып» ташлыйм, дип, башлаган иде, үзен бөтереп алып, егып салып (әллә самбо, әллә каратэ, әллә тхэк-вон-до булды), бәйләп ташладылар. «Ташладылар» дип әйтү язык инде, дөресе — бәйләп ташлаганнар икән. Анысын иртән, айныгач кына, чамалады. Җитмәсә:

— Тагын бер тапкыр энигә сүз әйткәнеңне, кул күтәргәнеңне йә ишетсәк, йә күрсәк, үзеңә үпкәлә. Безне беләсең хәзер. Гомер буе эчеп, аның да, безнең дә тормышыбызны агулаганың да җитәр. Арытаба да түзеп торыр-

лар болар, дип уйлама. Әйткәнне аңла, — дип куркытып куйдылар.

Ир кеше — ир кеше инде, жалу белән милициягә йөгереп булмый. «Менә күз төбем дә күргәргән, әллә үзем бәрелгәнмен, әллә кызларның терсәге тигән», — дип. Ояты ни тора, мал-лай!

Шулай да, ошбу вакыйгадан соң, Хәбир абзый бераз басыла төште, рюмканы ташлап бетермәсә дә, алай кеше кыяфәтен югалтырлык эчми башлады. Хәтирәсе дә ару гына хатын икән ләса! Болай кызларына да сүз тидерерлек түгел икән. Вәт бит, әй, малай. Уйлап кына карагыз. Ничә еллар буе хакимият әһелләре, милиционерлар, авыл советы һәм колхоз рәисләре, авылдашлары күпме үгетләп тә биздерә алмаган аракыдан кызлары биздерә язды. Дөрес әйткән теге вакытта Хәбир абзый, һай, дөрес мактанган: ну үзенең кызлары да кызлары, малай, — булырбулмас малайларга биргесез!

## БАКЧА ҖИМЕШЕ

Өй алдына тәмәке тартырга дип чыксам, артыма авып китә яздым: өр-яңа машина белән күршем Сабир абзый килеп туктады. Вәкарь белән генә машинасыннан төште, саклык белән генә ишегеен япты, пинжәк жиңе белән булмаган тузаннарын сөртеп алды да, миңа таба юнәлде. Көтелмәгән хәлдән «лып» итеп эскәмиягә утырдым, хәтта башлап исәнләшергә дә һуш җитми тора. Янәшәмнән урын алгач кына, исемә килеп, фикер йөртерлек хәлгә

килдем. Минем нәрсә сорарга теләгәнем йөземә үк чыккан булгандыр инде. Сабир абзый:

— Менә мин дә машиналы булдым, — дип куйды.

— Лотереягә оттыңмы әллә?! — дип аңа текәлдем. Чөнки гомер буе сиксән-йөз тәңкәгә эшләп, әле дә иске акча белән йөз сум пенсия алган кешенең машиналы булганын күргән юк иде.

— Нинди лотерея булсын? Үз акчама алдым, күптән исәп бар иде дә, мөмкинлеге генә чыкмый торды...

— Кит аннан, сөйләмә тузга язмаганны. Мин бит синең күпме акча алып эшләп, ничә сум белән пенсиягә чыкканыңны яхшы беләм.

— Тукта әле, нигә гаҗәпләнүеңне аңламыйм... — Аннан кинәт сүзне икенчегә борды. — Синең бер мәзәк ишеткәнең бармы? Бер карт базарда мәтрүшкә сатып тора икән. Бәйләме егерме суммы, утыз суммы, ди. Берәү килгән дә, сорый икән: «Файдасы бармы соң бу үләннең?» «Бар, улым, бар,—ди икән карт. — Өлкән улыма машина алдым инде, хәзер кечесенә акча җыям». Аңладыңмы?

— Юк, — дим, үҗәтләнеп. — Монда мәтрүшкәнең ни катнашы бар? Син бит базарга чыгып мәтрүшкә сату түгел, аны биш чакрым урап узасың. Үзең бит алыпсатарларны көне-төне сүгәсең...

— Соң, мәтрүшкәдәмени эш? Мәтрүшкәдән башка файдалы нәрсә азмы? Бакчаң бармы?

— Юк, — дип баш селкәм.

— Ә минеке бар. Үзең дә беләсең, ничә ел инде шунда казынам. Элек дүрт сотыйлы бе-

рәү иде, хәзер сигез сотыйлы өчәү: минем исемгә, хатынныкына, аның энисенә. Барсын да үстерәбез: иртә һәм соң өлгерүче бәрәңге, суган, помидор, аш чөгендере, кыяр, шалкан, кәбестә, укроп, кишер, борыч, яшел борчак, төрле-төрле чәчәк, салат, керән, көнбагыш, карлыган, кара миләш, шомырт, алма, чия, крыжовник, кура җиләге, җир җиләге, виноград, карбыз һәм тагын мин белмәгән әллә нәрсәләр...

— Йә, йә, җитәр, мине алдап утырма. Синең базарга чыгып сату итеп утырганыңны күрсәм дә, ышанмаячакмын. Андый кеше түгел син. Күзгә төтен җибәрмә, — дип, үртәлеп, сикереп торып, өйгә таба юнәлдем.

Сабир абзый артымнан куып җитте дә, иңбашыма кулын салып, туктатты.

— Бик тиз кызып барасың икән, энем. Ашыкма, хәзер аңларсың. Ничек дип башлыйм икән... Ярар... Син эле мин атап киткән ризык-нигъмәтләрне кайдан аласың?

— Кайдан, кайдан! Кайдан булсын — кибеттән йә базардан.

— Шул-шул. Һәм яртысын чыгарып ыргытасың. Бозылган була ул. Шуннан бар эшләп алган акчаң бер тамагыңа китә. Ә мин аларның берсен дә сатып алмыйм — үзем үстерәм. Димәк, акча янга кала. Ничә ел буена әнә шулай җыела икән ул. Бер тиен сумны саклый, ди торган иде минем мәрхүм әткәй, авыр туфрагы җиңел булсын. Аннан, энем, беләсеңме, мин... эһем-эһем... синең кебек тәмәке дә тартмыйм, аракы да эчмим .Яшелчә күп булгач, ит тә аз ашыйм, вегетариан диярлек...

Юк, ышанмадым. Тәүдә. Ә соңыннан, төнлә, урын өстендә, йоклый алмый, берничә сә-

гать әйләнгәләгәч, башка уй төште. Әллә миңа да, тәвәккәлләп, җир алыргамы? Машина ук булмаса да, виләсәпит алып булмасмы? Җәяү йөрү түгел инде.

Икенче көнне үк бакчачылык ширкатенә гариза тотып йөгердем. Кем белә, бәлки Сабир абзыйның сүзе дөрестер. Әйтәм аны, бар кала халкы икешәр-өчәр биләмә алып, яшелчә үстерергә тотынды. Файдасы бардыр шул...



## ЯНАРАЛ АРСЛАН МАҖАРАЛАРЫ

Дә-ә, бар иде элек авылда заманнар... Хәзер нәрсә ул авыл тормышы, тфү! Авыр, авыр, дип зарланалар. Элек яшәгән кешеләрдән сорагыз, алар әйтер. Сорашыр кешегез булмаса, китап укыгыз, хәзер ул заманнар турында күп язалар. Укысаң, чәчләр үрә тора.

Шулай да элек тормыш яхшырак булгандыр, ахры. Менә янгын сүндерү эшен оештыруны гына алыйк. Янгын сүндерү машинасын көтеп тормаганнар, чөнки бригада саен һәр авылның үз янгын сүндерү командасы булган. Хәзер генә ул, машина көтеп, утырып яналар, нигезе дә калмый.

Шуңа элек авылда халыкны дер селкетеп торткан кешеләрнең берсе — янгын сүндерүче була иде. Бездә бу җаваплы вазифа Арслан абзыйга тапшырылган һәм ошбу эшнең сер-

ләрен аңардан да яхшырак белүче хәтта тирә-як авылларда да булмагандыр. Кар эри башлау белән, ул авыл буйлап йөреп, һәр өйне, һәр ихатаны тикшереп чыга. Мичкәдә суы бармы, багоры, көрәге, чиләге әзерме? Булмый гына карасын — хәзер аның «трибуналына» эләгәсең. Ә җәй көне мунча ягып керү хакында уйлама да. Мунчаңның төтенлегеннән төтен чыкканын күреп калса, сөйләшеп тә тормый, командасы белән килә дә, мичеңә су сибеп, мунча ишеген каерып алып та китә. Исбат итеп кара аннан авылны яндырырга теләмәгәнеңне.

Янгынчылар өендә һәрчак тәртип булыр. Атларын тәрбияләп, карап кына торалар. Арба-тәгәрмәчләре яхшылап дегет белән майланган, арбага юан мичкә беркетелгән, анысына су тутырылган.

Бер уйласаң, кызык кеше иде Арслан абзый. «Янарал» кушаматы да бар үзенең. Һе, генералларың бер читтә торсын. Менә нәрсәләр эшләгәнен тыңлап торыгыз.

Үз эшен белә торган кеше иде Арслан абзый. Давыл түгел, таш яусын, һәркөн атларны барлык корамаллар төялгән арбаларына җигәләр дә, авылны җан-фәрман чаптырып, урап чыгалар. Ким дә түгел, артык та — көн саен өч тапкыр. Моны Арслан абзый:

— Һәрчак сугышчан әзерлектә булырга кирәк, ат тик торса, эштән чыга, — дип аңлата. Ә ул атлары ла, атлары! Сөлек кебекләр! Алларында гел солы булганлыктан, йоннары елкылдап тора. Кадерен белә иде элек атларның авыл кешесе, их-ма...

Халык, урамда янгын сүндерүчеләрнең җан-фәрманга чабуларын күрү белән:

— Әнә, Янарал Арслан күнегүләргә чыккан, — дип көлеп карап кала. Кирәк эш икәнен беләләр, көлүләре болай гына, коры тел чарлау гына.

Тик Арслан абзый бернәрсәне белмәгән булып чыкты. Шул аны соңыннан халык теленә кергән мәзәкнең төп герое итте дә инде. Ә бит, югыйсә, ул атларның арифметикага оста булуын бик яхшы хәтерендә тотарга тиеш иде. Атлар турында белмәгән нәрсәсе юк, ә менә шушыны өйрәтүче табылмаган, күрәсең.

...Беркөнне авылда көпә-көндез янгын чыкты. «Янарал» Арслан егетләре һәрвакыттагыча — үз урыннарында. Күз ачып йомганчы атларны җигә салып, болар дөбер-шатыр чыгып та чаба. Янгын авылның теге очында. Ә авылның озынлыгы өч чакрым. Тиз барып җитә болар... тик атлар янгынга таба борылмый, Янаралны тыңламый, «ялт» чабып, узып та китә. Туктатырга, кире борырга тырышып карыйлар, тик кайда ул! Авылны урап чаптырып килә болар. Тик монысында да шул ук хәл. Әнә шулай авылны өч ураганнан соң гына янгынга килеп житәләр. Тик өй янып бетә. Ярый әле абзар-курага, башка өйләргә сикерми «кызыл этәч».

Соңыннан авыл мәзәкчеләре:

— Арслан абзый, ярый әле репититсә вакытында урамны өч тапкыр гына урагансыз. Ә алты тапкыр әйләнгән булсагыз? Авыл белән утырып яна идек, — дип очрагы туры килгән саен тел чарлап, янгын сүндерүченең болай да янган йөрәген яндыралар иде. Эндәшми тагын үзе. Кулың белән эшләгәнне иңең белән күтәрә белү дә ирне ир итә инде анысы.

# ШИКАЯТЬ

Урындагы язучыларның җитәкчесе Каләмскийны ашыгыч рәвештә район түрәләренең берсенә чакыртып алдылар. Тиз генә килеп җитсен, ашыгыч эш, дигән. Бар эшен ташлап, үзенчә, әллә китап чыгарырга ярдәм итеп, акча бүләләрме икән, дип абына-сөртенә урынбасар бүлмәсенә барып керде. Сәламен алучы булмады, утыр, диюче бигрәк тә. Каш астыннан сөзеп карап, беренче сорау бирелде:

— Гәрәй Гамилев сезнең кешеме?

— Әйе, безнең оешмага карый, иҗат белән шөгыльләнә, әсәрләре ара-тирә гәзит-журналларда, шул исәптән күрше республика матбугатында да басыла...

— Кайда яши?

— Кайда булсын, безнең шәһәрдә, кирәк булса, адресын да әйтә алам.

— Кирәкми. — Урынбасар Каләмскийгә берничә биттән торган, дәфтәр битенә сыргаланган язу күрсәтте. — Бездә яшәгәч, нигә күрше республика гәзитенә шикаять язып ята ул? Безгә әйтсә булмыймыни, урында хәл итәр идек, юлын табар идек...

— Гафу итегез, мин бернәрсә дә аңламыйм...

— Монда аңламаслык бернәрсә дә юк, — дип кырт кисте аны урынбасар. — Менә Г. Гамилев безнең район сатучыларына зарланып шикаять язган, аны күрше республика гәзитенә җибәргән. Ә ул хат «урында тикшерелергә җибәрелә» дип, кире безгә кайткан. Нигә сез үзегезнең кул астындагы язучыларыгызга баш булмыйсыз? — Аннан Каләмскийгә сынап карап: — Бу шикаять хакында берәр нәр-

сә белә идегезме? — дип кискен сорау куйды район хуҗасының урынбасары.

— Ю-юк. Дөресен әйткәндә, кем нәрсә яза, кайда җибәрә — аны миңа хәбәр итү мәҗбүри түгел, бу әдәбият, әхлак кануннарына каршы килә...

— Каршы киләме, юкмы, тик барыбер белергә тиеш идегез, һәм бу сезне әйбәт яктан күрсәтми. Мәгез, үзегез карап чыгыгыз, ни яза бит хәсрәт язучы! — Һәм ул, йөзен чытып, хатны Каләмскийгә сузды. Анысы үз чиратында хат азагындагы имзага күз салды. Әйе, имзасы Г. Гамилевныкы. Кулы да, һичшиксез, аның каләмдәшенеке. Инде хатны әйләндереп, башына күз йөгертте. Аңа «Таландылар» дип баш куелган, ә астарак «юмореска» дип язылган.

— Әйе, бу аныкы, — дип җөпләде Каләмский. — Тик бу бит шикаять түгел, ә әдәби әсәр, сәүдә өлкәсендә булган кимчелекләрне фаш итә, кәкре куллыларын тәнкыйтьли...

— Фаш итәме, тәнкыйтьлиме, барыбер шикаять түгелмени?! — дип бүлдерде аны урынбасар.—Юморескамы, чуртмы, безгә барыбер, тик безнең районны гына тәнкыйтьләмәсен. Калганы безгә барыбер. Бу соңгы кисәтү булсын. Барыгыз, — дип аны чыгарып та җибәрделәр.

— Барыбер тәк барыбер, — дип борын эченнән сөйләнеп, Каләмский урамга чыкты. Ул анда Г. Гамилев белән чак маңгайга маңгай бәрелешмәде. Ә анысының күңел күтәренке, кочаклап ук алды да, тиз-тиз хәбәр сөйләүгә күчте:

— Беләсеңме, бер юмореска яздым әле, менә гәзиткә җибәрергә элемтә бүлегенә ки-

теп барыш. Тегүчеләр хакында. «Кыскартты-лар» дип атала. Ну теттем тетмәләрен үзләре-нең! Бастырып чыгарсалар, көлеп эче ката ин-де халыкның...

Каләмский нәрсәдер әйтергә дип авызын ачканчы, юморист «Хуш иттек» дип, саубул-лашып, элемтә бүлегенә таба юрттыра иде инде. Каләмский, авыр сулап куйды да, өенә таба атлады.

## ЯШЬ ЧАКТА НИ БУЛМАС...

Колхозчыларның гомум җыелышы бара. Көн тәртибендә сораулар күп, барысы да тиз арада хәл итүне көтә. Халык үткен бит ул — тыюыңны да белми, сүз бирүеңне дә сорамый, мөнбәргә менеп, үзенекен әйтеп калырга ашы-га. Җитәкчеләрне тәнкыйтьләүдән дә курык-мыйлар хәзер. Турысын ярып салалар. Бил-геле, моның президиумда утырган колхоз тү-рәләренә ошап бетмәгәне күренеп тора. Туры әйткән — туганына ярамаган, ди бит. Аннан, район вәкиле алдында да йөз кызара. Бернәр-сә әйтми, чыраена бернәрсә чыгармый тыңлап кына утырса да, кешенең күңелендә нәрсә барын ничек беләсең? Бәлки, эндәшми-тын-мый гына, хәтеренә салып барадыр. Ә соңын-нан, берәр кирәкмәгән җирдә кинәт исенә тө-шерсә? Әнә шуларны уйлый колхоз идарәсе рәисе Чакчаков, вәкилгә сиздерми генә күз төшереп алып. Дөрес, хуҗалык аягын чак сөйрәп килгән юлчы белән бер, менә-менә хәл-дән таеп егылам, таралам, дип тора. Шулай да... Әйтсеннәр иде үзенә генә, булмасенә

килеп. Анда ничек сөйләшергә белә ул, кәнишне, кара халык белән. Ә монда, кызарып-бүртенеп булса да, һәр әйткән сүзне кабул иткән булып утырмый чараң юк... Эх!.. Азындырдылар халыкны, йөгәнне бушаттылар... Үзгәртеп кору, яңарыш, дигәч тә, ул кадәр үк кирәкмәс иде... Хәзер пыр туздырып та булмый, шунда ук, тәнкыйть өчен эзәрлекли, дип, исем тагачаклар. Шуңа — түзәсең инде, ни кыласың. Рәислектән берәр җылы, югарырак урынга алганчы.

Барысы өчен дә эләкте рәис Чакчаковка. Дөресрәге, барысы да булмаганы өчен. Рәис үзе дә аптырап китте: нинди генә «юк» юк икән колхоз авылларында. Кибет, клуб, балалар бакчасы, фельдшерлык пункты, мәктәп, юллар, күперләр, яхшы техника, җиһазлар, абзарлар, торак, башлы белгечләр... Саный китсәң, исең-акылың китәрлек... Анысына гына түзәр идең әле...

Инде бетте бугай, дип җиңел сулап куюы булды, Сафа картны: «Бар, бар, бер-ике сүз әйтеп төш», — дип, мөнбәргә таба этеп диярлек чыгардылар. Алай куян йөрәклеләрдән түгел ул, әле, килештереп, бераз ялындырасы, үз дәрәҗәсен күтәрәсе килә.

— Менә монда белгечләр җитми, дип сүз куерталар, — дип башлады ул чыгышын, мөнбәргә күкрәге белән ятып. — Юкмыни алар бездә? Нигә, кайда булганнар, ди, бар кадрлар. Тик укыган берсе йә башка җиргә китә, йә кире кайтмый. Илнең кайсы гына почмагында эшләми безнекеләр. Ә нигә сыеша алмый соң алар? Чөнки мондагылары тегеләрне үзләреннән акыллы булганнары өчен сыйдыра алмый. Әнә Чатан Мәһәди малае бер

районда үзе хаким, үзе түш, ди. Нигә, ул үзебездә эшли алмас идемени? Эшләр иде. Тик ун ел элек китәргә мәҗбүр булды. Яхшы гына баш агроном булып эшләп йөри иде. Тагын күпме агрономнарыбыз, инженерларыбыз, техникум тәмамлаган егет-кызларыбыз читтә түрә булып йөри. Ә үзебездә өч яки сигез сыйныфлы «белгечләр» генә калган. Кайдан сөт, ит, икмәк булсын?! Кайтарырга кирәк аларны.

Аннан, кайбер чыгыш ясаучыларның яшьләргә таккан мөһеренә риза-бәхил түгелмен. Имеш, эш рәте белмиләр, алар болай, алар тегеләй, эчәләр, сугышалар, өйләнмиләр, йорт салмыйлар, ялкаулар, колхоз биргәнне көтеп яталар. Алай димәгез. Үзегезнең яшь чагыгызны оныттыгызмы әллә?! Кайсыгыз бүген урамда яисә мунчада яши? Тормыш өйрәтә ул, акылга да утырта, йортын да салдырта. Яшьләр булдыксыз, имеш, алар уенча. Кем белеп туган, ди, анасыннан туганда ук? Элек урамда эт сугарып йөргән күпме малай-шалай хәзер түрә булды. Соң, мисалга ерак йөрисе бармы? Менә, мәсәлән, әле пырзидиумда утырган үзебезнең рәис Малсызбайны алыйк. Чакчаковны әйтәм, әйе, Вафаичны. Мәктәптә дә гел «өчле» гә укыды, дәресләреннән качып, эрәмәлектә тәмәке тартып ятар иде. Егет чорына кергәч тә, аз елатмады авыл халкын. Әле эчсенме, әле сугышсынмы. Кыскасы, яшь чагында дүрәкнең дә дүрәге иде...

Сез бәлки хәтерләмисездер, ә мин онытмадым әле. Мәктәпне ничек кирәк алай бетергәч, Малсызбай шоферга укырга кергән иде. Остазы: «Шәмнең очкыны югалган, бар, шуны табып китер», — дигәч, бер ай эзләгән. Таба

алмаган — куып чыгарганнар. Аннан, ир-егет савучылар хәрәкәте башланды берзаман. Андыйларны югары уку йортларына куш куллап алалар иде. Малсызбай да савучы булып килде. Мин фермада мөдир чак ул вакытта. Сыерны сул яктан саварга маташуын әйтмим әле. Ә менә үгезне саварга булгач, тегесе моны тибеп очырган. Шифаханәгә керсә керде, әмма менә дигән карахтеристика бирделәр, үзенә биография эшләде. Шуннан, уку йортына китәргә тиешле кәгазен дә алды. Әнә шулай зоотехник булган кеше ул. Ә хәзер менә рәис булып утыра. Тәк шту, сез яшьләрне хурларга ашыкмагыз әле, яшь чакта ни булмас, — дип чыгышын тәмамлады.

Йөздән артык кеше җыелган клуб аны гөрселдәтеп көлеп, кул чабып озатты. Тик нәрсә әйтте ул кадәр кеше көлдерерлек? Сафа карт, аңлый алмыйча, иңбашларын гына сикертеп куйды да, урынына юнәлде.

...Чакчаков, җир ярылса, һич икеләнми шул тишеккә кереп китәр иде. Тик кайда китәсең инде халык күзеннән?

## САЙЛАУ АРТЫ ПРОГРАММАСЫ

Кичә Агалай Аһалаевичны урамда очраттым. Аның мине туктатып, исәнлек-саулык сорашуы гаҗәпнең дә гаҗәбе булып күренде. Кайда ул элек исәнләшү, биргәнен дә алмый, читкә карап уза иде. Бер-бер хикмәте бардыр, дигән уй төште башка. Кирәгем чыккандыр. Шулай икән шул.

— Энем, — дип башлады ул сүзен, уратып-

чуратып дигәндәй. — Язган нәрсәләреңне укып барам, ай-һай, усал язасың! Тел бар синдә. Урыс әйткәндәй, хураша патвишин. Шуңа сиңа бер тәкъдимем бар. Исәп — үземне депутатлыкка кандидат итеп күрсәтү иде. Сине үземнең унөченче ышанычлы кешем итеп чакырсам, риза булырсыңмы?

— Юк, юк, кая ул, мин сәясәттән ерак йөрергә тырышам. Үзегез беләсез, сәясәт — пычрак эш, буялсаң, исе чыга. Кирәге юк! — Шулай дип кул гына селтәдем. Мәңге ризалашачагым юк. Тик ул:

— Тукта әле, тоткан урыннан сындырма, энем. Башта уйла. Риза булсаң, торба бирәм, өй алдыңа асфальт җәйдерәм, һинд чәе дә эчеңне тишмәс. Үзең эчмәсәң, әниеңә күчтәнәч итеп алып кайтырсың, — дигәч, уйга калдым. Торба, диме?.. Әллә килешергәме?.. Әй, дип кул селтәдем дә, риза булдым.

Икенче көнне үк чакыртып алды бу.

— Бер идея бар иде, энем. Бүген төне буе йокламый, уйланып чыктым әле. Сайлаучыларны җәлеп итәр өчен безгә шаккатырырлык бирәр нәрсә уйлап табарга кирәк. Барысының да телендә мин булырга тиеш. Шунда гына без теләгебезгә ирешәчәкбез. Мин — депутат мандатлы, син — торбалы булачаксың. Бәс, шулай булгач, әйдә, башыңдагы шөрепләрне тәгәрәт...

Монысында инде мин төне буе йокламадым. Һәм... о-о, Алланың кодрәте, иртәнгә таба, йокламаска тырышып, аңкы-миңке ята торгач, башыма бик шәп идея килеп төште! Таң тишеге белән Агалай Аһалаевичка чаптым.

— Таптым! — мин әйтәм.—Без болай итик.

Депутатлыкка кандидатлар сайлау алды программасы белән чыгыш ясый. Ә без барысының да борынына чиртик. Сайлау алды түгел, ә сайлау арты программасы белән чыгыйк!

— Ну, баш та бар үзеңдә, энем. Әйтәм бит, ялгышмадым мин сине сайлап! Әйдә, хәзер үк эшкә тотын!

Һи, безгә нәрсә ул — тотындым. Бер сәгатьтән программа әзер иде.

— Булды, — мин әйтәм, — Агалай Аһалаевич!

— Кая әле, кая! — дип, сөенеченнән кәнәфиеннән чак егылып төшмәде. — Укы тизрәк! — Үзе иркенләп, аркасын терәп утырып, тыңларга әзерләнде. Дөресен әйтим, ара-тирә бүлдерүне көткән идем, тик ялгышканмын. Мин укыганнарны ул, ләззәтле елмаеп, хыялга бирелеп тыңлап утырды. Сезгә дә ишеттерим әле, нигә аны яшерергә?

— Депутатлыкка кандидат Агалай Аһалаевичның сайлау арты программасы, — дип башладым һәм киттем тезеп пунктлап, малай, мин сиңайтим! — Беренче. Үземә, балаларыма, балаларымның балаларына җитәрлек матди байлык туплап калырга.

Икенче. Депутат булып торган дүрт ел эчендә һәркемне — үземне, балаларымны, туганнарымны торак белән тәэмин итәргә. Кимендә дүрт бүлмәле фатирга чыгарга, якынча ике йөз квадрат метр торак мәйданы булган Сарай төзергә.

Өченче. Җир реформасын үткәрүгә актив булышлык итәргә — һич югы, йөз гектар мәңгелеккә беркетелгән җир мәйданы алырга. Ике-өч урында дача төзергә.

Дүртенче. Ун-унбиш югары килемле пред-

приятиенең ике йөз-биш йөз миллионлык өстенлекле акцияләренә хуҗа булырга.

Бишенче. Швейцария кебек илләрдә берничә валюта исәбе ачарга.

Алтынчы. Үз гаилә әгъзаларымның һәрберсенә кимендә ике машина сатып алырга. Билгеле, түбән хак белән.

Җиденче. Сөяркәсез булмас. Аны фатир һәм машина белән тәэмин итәргә.

Сигезенче. Тиешле кешеләр белән тиешле элемтәгә кереп, кимендә депутат булып торасы елларга гаиләмне, балаларны кием-салым, азык-төлек белән тәэмин итәргә.

Тугызынчы. Ришвәт бирсәләр — кире какмаска. Ришвәт сорасалар — канәгатьләндерергә.

Унынчы. Елына кимендә өч тапкыр бушлай чит илгә чыгып керергә (АКШ, Франция, Англия, Төркия, ахыр чиктә — Германия).

Унберенче. Хаҗга барырга, хаҗи булырга.

Уникенче. Сайлаучылар онытмасын өчен, гәзит-журналларга мактаулы мәкаләләр, әңгәмәләр оештырырга.

Унөченче. Дошманнарны — сытарга, изәргә, куарга, төрмәгә ябарга, һич югы — эшеннән алырга.

Ундүртенче. Депутат саулыгы—халык байлыгы. Елына кимендә дүрт тапкыр ял йортлары, курортларда дәваланырга.

Унбишенче. Депутатларның нindidер секцияләре дә бар бугай — аларга берәр ничек вакыт табарга, кул күтәрергә иренмәскә.

Уналтынчы. Эш бүлмәмә йөз миллион сумлык яңарту эшләре үткәрергә. Әллә тагын депутат булырга туры килә, әллә юк. Яхшы мар-

калы шәхси машинага (чит илнекенә) күчеп утырырга.

Унҗиденче. Сайлаучыларга яхшы тормыш, байлык, саулык, җир вәгъдә итәргә, өметләндерергә, ышандырырга, күп белгәннәренең телен кыскартырга: ышанмасалар, зур бәла түгел — чебен дулап тәрәзә ватмый ул. Сайлагансыз — арытаба сезнең бездә эшегез юк. Безнең дә сездә эшебез юк. Бигайбә. Сайламаска кирәк иде, әрекмән колаклар!

Унсигезенче. Артны ныгыту — үз кул астыма каршы сүз әйтмәстәй, һәр сүземне җөпләп торырдай урта кул белгечләрне җыярга.

Унтугызынчы. Туган-тумачаны җылы эш урыннары белән тәэмин итәргә: туган туганга — иптәш, дус һәм туган.

Егерменче. Депутатлык гомерлеккә бирелми, тик шулай да моңа омтылырга кирәк. Бу депутатлык вакытым чыгу белән икенче вакытка тагын кандидатурамны куярга.

Егерме беренче. Кул кулны юа, ике кул — битне. Алдагы барлык пунктлар буенча ярдәм итү, булышу, арттан этү шулай ук барча туганнарыма, дус-ишләремә дә кагыла.

Мин укып бетергәндә, ул һаман елмаюыннан туктамаган иде. Ошады бит, мин сиңа әйтим! Димәк, торба минем кесәдә!

Тик кинәт сикереп торды да:

— Нәрсә?! — дип, кулымнан кәгазьләремне йолкып алды, ике күзен шар итеп, аларга текәлде. Аннан кызара, бүртенә, кабара башлады һәм аның:

— Во-о-он! — дигән сүзләре мине бик гаҗәпләндерде. Нинди рәхәтләнеп тыңлаган булды тагын... Менә сиңа мә, ышан моннан соң депутатлыкка кандидатларга. Чыгып кит-

тем, әллә ялындырыр, дидеме икән? Торбасы үзенә булсын, тамагына тыгылсын.

Шулай итеп мин торбасыз торып калдым. Асфальт юл, һинд чәе дә башка кемгәдер эләкте.

Ә Агалай Аһалаевичмы? Нигә сайламасыннар, сайладылар. Бик матур сайлау алды программасы да бар иде . Тик ни хикмәт, сайланып ике-өч ай үттеме-юкмы, аны түгел, ә мин төзегән сайлау арты программасын тормышка ашыра башлады. Вәт, хәйләкәр! Теге, вәгъдә иткән торбасын сорап барам әле. Бернәрсә дә сизми бу дип бик кәпәренмәсен.



## ӘНӘ, АЛАР ОЯЛСЫН

Урамда баштанаяк модный киенгән кешеләргә карыйм да, шаккатам, тел шартлатам. Кайдан гына табалар дип әйт син аларны. Шулкадәр акчаны, дим? Әллә арзан хакка модалы кием сатыла торган берәр яшерен кибет бармы? Әллә соң мин генә белмимме? Тик кала кибетләрен күпме генә йөреп әйләнсәм дә, арзанлы рәтле кием таба алганым юк. Нишлисең, үзебезнең илдә тегелгәнен сатып алырга туры килә.

Башта күлмәк алып кидем. Ун төрле күлмәк арасыннан сайладым. Дөрес, бер җиңе озын, икенчесе — кыска, төсе дә ни дисәң, ул түгел. Җитмәсә, җиңнәренең җөйләре берсе

эчкә, икенчесе тышка кайтарып тегелгән, ак төймәләре кара җеп белән тагылган. Чуклары асылынып торган урыннары да бар. Беренче көнне үк култык асты сүтелеп чыкты. Тик берни эшләр хәл юк. Көн дә яңа күлмәк сатып алып булмый. Аның хакы да иске акча белән — ат хакы. Күлмәкне урамга киеп чыккан саен кешеләр кайсы елмаеп, ә әдәпсезрәкләре арттан шаркылдап көлеп кала. Гарьләнәдер бу, дип уйлыйсыздыр? Һе. Гарьләнми торсын әле. Нигә оялыйм, ди мин. Аны мин текмәгән, дәүләт контроле аша үткәрмәгән, сатуга чыгармаган. Әнә, алар оялсын. Ә кешеләргә үпкәләмим. Ул мәдәнилек дигән нәрсә бик дефицитка әверелде бит хәзер. Аны, башка товар кебек, чит илдән бер вагон кәгазь акчага да сатып алып булмый.

Тагын да костюм кирәк булды. Анысының нинди икәнен тасвирлап тормыйм, үзегез күз алдына китергәч тә, көлке хастасы ябышкандыр инде. Чалбарның иң мөһим аерым билгесен генә атап китәм. Ул да булса, гафу итегез, төбе. Анысы тезгә төшеп тора. Анда, мөгаен, бер-ике капчык арыш сыядыр. Ә биле шундый киң, бернинди каеш җитә торган түгел...

Шушы костюмны кигәч, хәтта танышларым: «Бу юләр белән без бер авылдан түгел», дигәндәй, урамның икенче ягына чыгып, танымаганга салынып үтә башладылар. Гарьләнәлә-әр! Ә миңа барыбер. Соң, нигә гарьләним? Әнә, модельерлар, тегүчеләр оялсын.

Кышкы кием белән дә шулай булды. Пальтоның да, бүрекнең дә, киез итекнең дә кимчелеге бар. Мин бернәрсә булмагандай йөри бирәм. Кеше көлә тора, ә мин йөри торам.

Чөнки беләм: кешеләр миннән көләбез дип уйласалар да, шул тегүчеләрдән көлә булып чыга бит инде.

Кыш көне җылы ботинкалар алып кигәч, тагын тегеләрне көлкегә калдырдым. Тәүге тапкыр киеп эшкә барырга чыксам, бераз ара үтү белән урынымда, сумалага ябышкандай, шып туктадым да калдым. Ни уңга, ни сулга барып булмый, ә алга яки артка бару турында әйткән дә юк. Нигә дисәң, алга атласаң, бер ботинка уңга, икенчесе сулга сөйри, Хода хикмәте! Шулай шактый вакыт бер урында таптынып торырга туры килде. Ярый әле бер шәфкатьлесе юләрләр йортына шылтыраткан. Алар килеп коткарды. Хәлне сөйләп биргәч үз носилкаларына үзләре ятып, эч тырнап көлделәр. Мин дә, карда оекбаш белән басып торган килеш, булдыра алганча авыз ердым. Әнә шулай көлдек без аяк киеме тегүчеләрдән! Мөгаен, җир тишегенә кереп китәрдәй булып кызарганнардыр, колаклары ут булып янгандыр. Көне буе очкылык та тотмаса әле.

Ә тегеләр, калдырыгыз, дип, күпме генә ялынсам да, барыбер алып киттеләр. Мине түгел, ботинкаларны. Хәтта акчасын да түләделәр.

— Шифаханәдә тынычландыру күлмәкләре бар, ә менә шушындый аяк киеме юк. Ә безнең авырулар арасында хәтта тугыз катлы йортның почмагыннан җәяү менеп-төшеп йөргәннәре дә очрый, хәзер безгә эш икеләтә ким булачак. Бу ботинкаларны кидерәсең дә... Үзегез аңлыйсыздыр инде... — диделәр. Тагын кайда сатылуын сорадылар.

— Очраган бер «Аяк киемнәре» кибетенә керегез, нәрсә телисез, шуны табарсыз. Ан-

да мондый аяк киемнәре безнең илне генә түгел, ә җир шарын бер урынга богаулап куярга җитәрлек, — дип, озатып калдым.

Тик менә күпме генә шулай киенеп йөрсәм дә, кешеләр күпме генә көлсә дә, сыйфатсыз кием чыгаручылар кимеми. Озак уйладым: эш нәрсәдә? Таптым, ахры, сәбәбен. Бу көлү аларга барып җитми икән ләбаса! Ә барып җитсен өчен, бәлки, һәр киемнең күренеп торган урынына фабриканың һәм тегүченең исемен язып куярга кирәктер? Ә бәлки... шул гарьләнгәнгә язмый торганнардыр? Шулайдыр. Ә бит чит ил фирмалары оялмый, чөнки беләләр: аларның тегүчеләре эшләрен хәтта тавык көләрлек башкармый. Киресенчә, фирма маркасы белән горурланалар. «Адидас», «Ле Монти» дисәң, барысы да аңлашылып тора. Ә бездә фабрика исеме бернәрсә дә аңлатмый: әзер киемме бу, яки корамалмы, әллә безне мыскыллап язып куйган бер әдәпсез сүзме? Минемчә, соңгысы дөреслеккә туры киләдер. Шуңа безнең ил халкы чит ил товарына капланып төшә дә инде.

## ӨСТӘМӘ СОРАУ

Ниһаять, мин дә институтны тәмамлап, авылга кайттым. Иң авыр һәм, нәрсәсен яшереп торасың,—иң күңелле вакыт артта калды.

Очраган бер авылдаш котлый, укыганыңның игелеген күр инде, дип яхшы теләк тели.

Хатип абзый да кулымны кысты. Аннан кинәт:

— Мин дә яшь чакта институтка керергә

барган идем дә бит, тик сынауларны үтә алмадым, — дип куйды.

Хатип абзыйны гомер буе тракторда эшләп йөргән кеше буларак белгәнгә:

— Чынмы?! — дип аптырап калдым. — Йә, сөйлә әле, сөйлә. Бер дә ишеткән юк иде.

— Үзе бер мәзәк булды ул, энем. Илленче еллар. Ачлы-туклы, ярым ялангач укып йөрелде. Ун сыйныфны әткәй карт бетертте, үземнең теләк юк иде. Әнә ул өзмәде дә куймады инде: «Бар, улым, укы, кеше бул, хәзер сугыштан соң ир-егет белгечләр күп кирәк. Үзең дә бал-май эчендә генә йөзәрсең, безгә дә карт көнебездә җиңелрәк булыр», — дигәч, риза булдым инде. Үзем тракторга кызыга идем. Әтәй сүзен егу элек кая ул! Хәзер генә беренчедә укыган малайны да җиңеп булмый.

Ничек иза чигеп калага барып җитеп, институтны табып, дукәмитләрне тапшырганны сөйләп тормыйм. Ничәдер имтиханны ничектер тапшырдым. Соңгысына кереп, сораулар алсам, берсен белмим. Өстәл артында утырган агайларның өлкәне, хәзергечә имтихан алу комиссиясе рәисе булгандыр инде, минем кәгазьләрне карады да, жәлләпме, әллә ир-егетләр кирәккәнгәме икән:

— Монысын белмәсәң, мин сиңа икенче, өстәмә сорау бирәм. Шуны әйтсәң, үзеңне студент дип исәпли аласың. Йә, әйт әле, бу нинди төр тереклек: үзе ит тә бирә, сөт тә бирә, йон да бирә, тире дә бирә, өйрәтсәң җигеп йөрергә дә була?

Мин уйлыйм бит инде хәзер. Үзем дулкынланам, тез буыннарым калтырый. Баш та каткан, ачлы-туклы кешенең ни. Уйладым-уйладым да:

— Колхозчы, — дидем. Чөнки ул вакытта нинди генә салым юк иде колхозчы мескенгә. Салым түлибез дип, үзләре ялангач йөри иде. Түлисең, тагын киләләр: «Давай йон, ит, сөт, йомырка, тире», — дип. Бик үзәккә үткән булгандыр инде.

Бер-берсенә карашып алдылар да, болар мине тиз генә чыгарып җибәрделәр. Нигәдер, куркып киттеләр шикелле. Әнә шулай үтә алмадым институтка. Җавабым дөрес булмагандыр инде.

Мин рәхәтләнеп көлдем дә, ары киттем. Шундый шаян сүзле агай инде ул авылдашым Хатип.

## КУЯН ШУЛПАСЫНЫҢ ШУЛПАСЫ

Ниһаять, безнең колхоз да баш инженерлы булды. Яшь кенә бер егет җибәргәннәр. Институт бетергән диме шунда. Әй, институт түгел, чурт бетерсен, тик безгә инженер булсын. Читтән килгән инде килүлеккә... Колхоз үзебезнең егетләрне укырга җибәрә лә ул. Кире кайтучы гына юк.

Бу белгечебез үзе каланыкы, ди. Шулай да авылга килгән, курыкмаган икән. Шәһәр авылга бурычын кайтарырга тиеш, дип сөйләнәләр иде, шул бурычмы икән инде бу? Шуңа яңа баш инженерны күрергә бар колхоз җыелды. Мөгезе юклыгын үз күзләре белән күреп ышангач кына, таралышты халык. Нияз карт кына егетне сөйләндереп калды. Һәрнәрсәдә эше булган шундый карт инде ул. Чакыраларммы, чакырмыйлармы — кысылып йөрер-

гә ярата. Шулай да кешегә бәяне төгәл бирә, әйткәне дә дөрес килә. Аннан, табышмак белән сөйләшергә ярата Нияз карт.

Соңыннан, чыннан да, кемнәрдер:

— Йә, яңа инженер ничек? — дип сораганнар икән.

— Куян шулпасының шулпасы, — дип кенә әйтеп куйган.

Моның нәрсә аңлатканын берсе дә төшенмәде. Тик бу табышмакның бер чишеләчәген белгәнгә, көтеп яши башладылар. Һәм ул озак көттермәде.

Баш инженер вазифасының мәшәкате җитәрлек аның. Әле ватылган-җимерелгәнне төзәтергә әйбер, әле яңа техника кайтарту турында уйларга кирәк. Җитмәсә, икенчел чимал, яки тимер-томыр ватыкларын тиешле урынга озатырга кирәк. Анысы җиткерелгән саннан артык та, ким дә булмасын. Артыграк тапшырдыңмы — икенче ел көт тә тор — ул артып киләчәк.

Менә әле дә, баш инженер эшкә башлап ике көн үттеме-юкмы, өстән тимер-томыр тапшыруның үтәлеше турында сорап шылтыраттылар. Хуҗалыкның бу яктан бурычы байтак икән. Шул эшкә тотынырга туры килде.

Тимер-томырны төяп озату әллә ни күп вакытны алмады. Хәзер андый байлык аяк асты тулып ята. Запчасть булмый тырым-тырагай таралып төшкән, бер яки ике шөребе җитмәгән теләсә нинди авыл хуҗалыгы машинасын сүт тә, озат.

Шулай иттеләр дә.

Тик икенчел чимал кабул итү пунктыннан шофер егетне кире борып кайтарганнар. Имеш, тимер-томыр сыныкларын сортларга—

карасын карага, төслесен төсле металлга аерып тапшырырга кирәк икән. Яшь инженерга моны әйтүче булмагандыр, ахры. Үзе дә, мондый эш белән тәүге тапкыр очрашкач, белмәгәндер.

Карасын карага, төслесен төслегә аерып, яңадан озатырга туры килде.

Инде генә тынычланып йөри иде, кичкә машиналар тагын йөге белән кире борылып кайтты.

Яшь инженер аптырауга калды. Нәрсәсе ярамый икән соң? Шулай башын ике куллап кыскан килеш утыра иде, бүлмәгә Нияз карт килеп керде. Аның сәламенә күңелсез генә җавап кайтарды. Шуңа кызыксынучан карт сорамый булдыра алмады:

— Нинди кайгы төште башыңа, улым?

— Аптыраган инде, картлач, — диде тегесе. — Аңлап җитмим әле. Тимер-томыр сыныклары тапшырырга кирәк, дигән иделәр. Кара металлны аерым, төслесен үзенә башка озатырга кирәк, имеш. Мин шулай итәм, тик кире кайтаралар.

— Һай, эттәгенәсе икән. Мин ярдәм итә алмаммы соң? Ә металл нәрсәсе белән карага-акка аерыла? Төшендереп бирмәссеңме?

— Соң, бабай, аның нәрсәсе бар? Шуны да белмәскә томана булырга кирәк. Кара буяулысы — кара, ә яшел, кызыл, сары буяулысы — төсле була.

Нияз карт:

— Алай икә-ә-ән!— дип суздьı. Аннан әйтеп куйды: — Шуны белер өчен биш ел укыдыңмы инде? Мин аны, балам, институтта укымасам да аерам. Кире боралар, дисең инде? Алай булгач, ныклап уйларга кирәк. Ди-

мәк, монда бер-бер гыйльләсе бар. — Бераз вакыт башын кашып торды да, кинәт, зур ачыш ясагандай җанланып китте. — Инженер улым, беләсеңме нәрсә? Заводта буяуларын бутаганнардыр. Ничек, дисеңме? Мәсәлән, кара металлны — сары буяу, ә төсле тимерне кара белән буяганнардыр. Берәр эш рәте, акны карадан аера белмәгән юньсезе, бутап, синең башны катырадыр. Тәртип бетте шул хәзер, инженер улым. Кайда гына карама, илкесалкылык, буталыш.

Егет урыныннан сикереп торганын сизми дә калды.

— Кара әле, улатай, син — даһи! Элегрәк бу ничек минем башка килмәгән икән? Син туганда ук академия бетереп дөньяга килгәнсеңдер. Чынлап та, син әйткәнчә булуы бик ихтимал... Складта кара буяу да, төслеләре дә бар иде кебек. Ярый, мин йөгердем. — Инженер егет ишеккә ташланды. Аннан яңадан, нәрсәдер исенә төшкәндәй, башын кире тыкты. — Эшең юкмы, карт? Булмаса, мине көтеп тор, буярга булышырсың, — дип юк булды.

— Булышырмын, улым, булышырмын, — дип, Нияз карт мыек астыннан елмаеп калды аның артыннан.

...Бер айдан колхоз тагын да баш инженерсыз калды. Бар халык бармак төртеп күрсәтеп көлә башлагач, түзмәде—китте ул. «Куян шулпасының шулпасы» нәрсә икәнен халык та, ниһаять, белде.

Тик колхоз идарәсе рәисе генә Нияз картка бик каты ачуланган, ди. «Ун ел эзләп, чак бер инженер тапкан идек, анысыннан да синең аркада колак кактык. Акыллы булгач әнә, үзең эшлә», — дип, аны... баш инженер итеп

куйган. Эшләп йөри әле. Нигә эшләмәсен: кара металлны төсле металлдан гына аерырлык тормыш тәҗрибәсе булган карт тракторчы бит ул.



## РӘХМӘТ, ЭНЕМ!

Хасбулат урамга йөгереп, атылып диярлек килеп чыкты. Җитәр, болай күпме җәфа чигеп йөрергә була?! Куркып күпме яшәргә мөмкин?! Кеше күзенә күренерлеге калмады бит хәзер. Нәрсәдер эшләргә кирәк. Табиблар өнәп бетермәсә дә, халык медицинасына мөрәҗәгать итми чарасы юк. Шифаханәгә барсаң, чират ел буена да җитмәячәк.

Хасбулат үзе йөгерә-атлый тукталышка таба бара, үзенең башында шундый уйлар бөтерелә. Әйтерсең, эченә корт төшкән алма — үзе бөгелеп төшкән, йөзе чытык.

Әһә, әнә, трамвай тукталышы. Барып җиткәч, бер читтәрәк урын алды да, күктән чебеш күзәткән карчыга төсле, үзенә «корбан» сайлый башлады. Трамвай көтүчеләр артык күп түгел. Бер дә аның таләпләренә җавап бирердәй, эше барып чыгардай кеше күренми. Булгач, берәгәйле, уйлаганы тормышка ашарлык булсын.

Бераз шулай басып торгач, ниһаять, ул көткән кеше тукталышка килеп басты. Чи-

бек Хасбулатка караганда — бу пәһлеван. Өлгерми калырмын, дип, ул тизрәк аңа якынлашырга ашыкты. Тукталышта кеше күп инде күплеккә... Хәер, хәзерге заманда кеше кешене яклап бармый ул. Баштанаяк чишендереп китсәң дә, читкә карап торачаклар. Яки тиз генә сыпыртачаклар.

Шулай бер минутлап торгач, Хасбулат, тәвәккәлләп, «корбанына» иңбашы белән каты гына орынды. Тегесе сабыр икән, бер сүзсез кенә карап алды да, бер адым читкәрәк китеп басты. Берәр авыру, тиле бәндә, дип уйлый булыр. Хасбулат теге кеше читкә караган арада янә якынаеп, пәһлеванны гәүдәсе белән этеп җибәрде. Теге ир һаман каршы сүз әйтергә уйламый. Куркак! Ә бит үзенең йодрыгы гына да — оһо-һо! Бер генә тондыра бит инде, эш алай-болай аңа барып җитсә. «Ну, нәрсә көтәсең, селтән дә, сугып очыр инде», — дип эчтән ялына Хасбулат. Тегесе аңламый.

Хасбулат эчке әрнүенә түзә алмый, үрсәләнеп тагын да нәрсә эшләргә кирәген уйлый башлады. Кыюрак булырга кирәк.

Хасбулат корбанын бер генә мизгелгә дә күз уңыннан ычкындырмады. Ул читкә бер адым ясаса, Хасбулат янә аңа якынлый. Тик тегене тәвәккәл адымга этәрер өчен нәрсәдер эшләргә кирәк иде. Шуңа, урын иркен булса да, Хасбулат, дорфа итеп, кинәт кенә:

— Нәрсә монда бар тукталышны биләп басып торасың?! — дип эндәште дә, кабыргасына төртте. Тавышы катырак та чыкты бугай, башкалар алар ягына борылып карады. Карасыннар, әйдә, эш зурга китә башласа, берсе дә калмаячак аларның.

— Син нәрсә, тилебәрән орлыгы ашадыңмы әллә?

— Әә-ә?! Нәрсә?! Минме тилебәрән орлыгы ашаган?! Хәзер мин сине, беләсеңме, ничәгә бөклим?!

Хасбулат тегеңә көзге әтәчтәй очып кунды. Тик кайда инде аңа, орчык кебек кешегә. Теге азрак терсәге белән төрткән иде, чак егылмый калды. «Юк, энем, мин синең белән бер дә юкка вакыт уздырмадым», — дип, Хасбулат, йөгереп барып, аны башы белән сөзде...

Тегенең, ниһаять, түземлеге бетте, ахры, җитез генә борылды да... Хасбулат аның йодрыгы ничек итеп күз иярмәслек тизлек белән һавага күтәрелгәнен генә күреп калды. Ачуы чыккан ир мазасына тиюченең күз төбенә чамалаган иде бугай, тик монысы, чослык күрсәтеп, сул яңагы белән борылып өлгерде...

Күз алдында ниндидер ут көлтәсе балкып китте, аннан нәрсәдер җиргә «шап» итеп барып төште. Хасбулат моның үзе икәнен, егылгач шундый тавыш чыкканын аңлый иде, әлбәттә. Ул тиклем юләр түгел.

Баһадир исенә килгәнче, Хасбулат аягына басарга ниндидер көч тапты. Теге ир ни булганын үзе дә аңламый тора, ахры. Ә Хасбулат авызында тозлы тәм тоя, теленә коелган тешләре тия. Ул шулай, башын кырын салып, нидер тыңлагандай, торды-торды да:

— Ха! — дип кинәт каратэчыларча кычкырып җибәрде, аннан урынында сикереп куйды. Әзмәвер дертләп китте. Хасбулат учына тешләрен төкерде. — Ха, күрәсеңме? Ә син курыккан идең. Сызламый бит, әй! — Ул кинәт тагын алга ташланды, тегенең кулларын кысты. — Аптыраттым, ахры, сине, энем. Сәбәбе

шул. Башка чарам калмагач, сиңа бәйләнергә туры килде. Менә бер ай инде, тешем белән җәфаланам. Бер ай йөрдем. Менә бүген, уйладым-уйладым да... Рәхмәт, энем!

Теге кеше дә акрынлап аңына килә башлады, яңадан күтәргән йодрыгын төшерде. Аннан сорап куйды:

— Бу, — ул Хасбулатның учына ымлады, — алты тешеңнең барсы да сызлый идемени?

Хасбулат кулын гына селтәде.

— Берсе дә җәл түгел. Бүген сызламаса, башка вакытта тагын җаныма тияр иде. Яхшы булды әле. Рәхмәт, энем, тагын бер тапкыр. Сәламәт бул, — дип, аның гәүдәсенә ишарә ясады.

Хасбулат йөгерә-атлый кайтыр якка китте. Шатлыгы йөзенә чыккан, үзе тешсез авызын ерып, очраган бер кешегә сәлам биреп уза.

Тукталышта аның артыннан баш чайкап, юләрдер бу, дип калдылар. Димәк, бер дә тешләре сызлаганы юк икән әле аларның...

## ИҢ ШӘП БҮЛӘК

Бүген безнең авылда туй. Кайсы якта ничектер, ә бездә туйга бар авыл белән йөриләр. Шуңа, чакырганда, өй борынча чакыралар. Теләгең бар икән — рәхим ит. Бүләгең булмаса да, сиңа сүз әйтүче дә, кырын күз белән караучы да булмаячак. Монысы чит-ят кешегә инде. Ә туганнарга таләп икенче. Алар йөзләренә кызыллык китермәскә тиеш. Соңгы сыерыңны сатсаң сатасың, ә бүләк китерә-

сең — йоласы шундый. Шуңадыр, ахры, кәләш белән кияүнең туганнары бар кешене шаккатырырлык бүләк әзерләргә тырыша. Кешеләр туйга тамашасыннан битәр әнә шул бүләк бирешкән мәлне күрергә йөри, дисәм, һич ялгыш булмас.

Бу туй бигрәк тә зур бүләкле булмакчы, ди. Нигә дисәң, туганлашучылары кем соң?! Сатучы Сәкинә һәм балта остасы Кадим белән бухгалтер Нәфисә һәм колхоз идарәсе рәисе Сафа Вафич үзе. Кыз тәүгеләренеке, ә кияү — Сафа Вафич улы. Тик болай дип әйтү белән генә аңлашылып бетмәс, янәсе, шуннан ни булган, азмыни дөньяда колхоз идарәсе рәисләре һәм сатучылар? Ачыклык кертәм. Дөнья көтү ягына килгәндә ике як та андый-мондыйлардан түгел. Ике йортта да байлык ишелеп тора, малын-туарын әйткән дә юк.

Туй кайсы якта да шул туй инде ул, шуңа аның ничек үткәнен сөйләп тормыйм. Иң кызыгын гына — бүләк бирешүне генә сурәтләп китәм.

Бездә бүләк бирешү алдан ук «сәхнәләштерелеп» куелган була. Ягъни, иң беренче, чама белән, бәләкәйрәк бүләктән башлыйлар. Әнә дә бүләк, дөя дә бүләк, дип әйтәләр әйтүен, тик ул сезнең яктадыр, ә бездә алай түгел.

Тәү башлап кәләш ягына сүз бирелә. Бүген дә бозмадылар бу йоланы. Кызның туганнары йөзләрен кызартмады. Бүләкләр арасында йомшак караваты да, келәме дә, телевизоры да, ниндидер илнең стенкасы да, тагын әллә нәрсәләр бар иде. Иң зур бүләкне, гадәттәгечә, ата белән ана бирде.

— Миннән яшьләргә өч миллион сум акча, — дип, әти кеше эре генә яңа тормыш коручылар алдына саклык кенәгәсе салды.

Шуның белән кәләш ягы бүләк бирүне тәмамлады. Чират кияү ягына күчте. Бу яктан да сүз тидерерлек булмады. Магнитофоны да, бала арбасы да, бәллүр савыт-сабасы да һәм башка тормыш кирәк-ярагы да яшьләр алдына өелде.

Чират әти кешегә житте. Сафа Вафич торып баскач, барысы да тын калды. Аның бүләге барысыныкыннан да зур булачагына бернең дә шиге юк иде. «Машинадыр инде», — дигән сүзләр ишетелеп калды. Нигә, булыр да, безнең рәис ким-хур кешемени? Колхозы — алдынгы, тирә-якта дан тота, үзенең әллә ничәмә орден-медале бар, колхозының әллә ничә байрагы бар.

Сафа Вафич тыныч кына сүз башлады:

— Менә, улым, киленем, сезгә карап-карап торам да, тагын бер карап куям. Килен нык, таза күренә. Кода-кодагый, рәхмәт, яхшы кыз үстергәнсез. Безнең малай да начар түгел. Шуңа — маладис, Нәфисә, маладис, Сафа, дим. Кыскасы, икесе дә чибәр, буй-сыннары да бар, димәк, пар килгәннәр. Шуңа тазалык кирәк, сәламәтлек кирәк, дип әйтәм. Аннан тагын, балалар, тырышлык һәм уңганлык та кирәк нәрсә. Алары булса инде — җаның нәрсә тели, барысы да булыр. Шуңа, улым, сине иртәгә үк идарәдә көтәм. Һөнәр бирдем, укыттым, хәзер кеше булдың — эшкә тотынырсың. Сиңа да, килен, сүзем шул: колхозыбыз каладан ким түгел, җаның теләгән эшне сайлап алырсың. Тик иң мөһимен онытмагыз: та-

залык һәм тырышлык кирәк, ә дөнья малы табылыр, — диде дә, урынына утырды.

Барысы да, тәүдә бернәрсә аңламый, аптырашып калдылар.

Кыз белән егет бер-берсенә карашып алды. Аннан торып бастылар. Сүзне улы алды.

— Икебез исеменнән дә, ягъни безнең гаилә исеменнән, рәхмәт, әти, яхшы сүзләрең, изге теләкләрең өчен. Бу безгә иң зур бүләк. Һәм без аны кабул итәбез, — диде ул, кәләшенә елмаеп карап.

...Бу аптырашу нәрсә белән беткән булыр иде, ярый әле кемдер:

— Әче! — дип кычкырып җибәрде. Аны башкалар да күтәреп алды.

## КЫШ БАБАЙ КҮЧТӘНӘЧЕ

«Бер рәхәтнең бер михнәте була», дип әйтә торган иде минем дәү әти. Дөрес әйткән ул. Мәсәлән, Яңа ел бәйрәмен алыйк. Аның михнәте билгеле инде — чыршы табу. Михнәт кенә түгел, үзе зур мәсьәлә. Ярый ла, кибеттә булып, этешә-төртешә, сугыша-талаша бер-ике ылыс ботагы булган, шулай да чыршы дип аталган сагызлы таяк эләктерә алсаң. Ә эләктерә алмасаң яки ярдәм итәрдәй танышларың булмаса? Әнә шуннан башлана инде аның михнәте. Беренчедән, чыршыны кайда барып, кайдан кисеп алырга? Ярый, урманга бардың, ди. Икенчедән, аны ничек урман каравылчысына, милиционерларга тотылмый гына өйгә алып кайтырга? Ә чыршы булмаса, өйдә тыштагы бураннан да хәтәррәк давыл куба.

Яңа елны котсыз һәм ямьсез өйдә каршы ала-сың килмәсә, миеңдәге барлык күзәнәкләрне эшләтеп, бар осталыгыңны, хәйләңне эшкә ку-шасың. Яңа елны кемнең генә сый тулы бәй-рәм өстәле артында каршы аласы килмәсен. Ә бәйрәм кичендә сөйгән хатының, матур итеп елмаеп:

— Синең кебек ир дөньяда берәү генә, — дип әйтеп, «әп» итеп ала икән, монысы инде бәйрәм өстенә бәйрәм, син үзеңнең чын ир икәнлегеңә ныклап ышана аласың. Аннан ка-нәгать төс белән, өйне ямьләп, хуш ис тара-тып утырган чыршыга күз сирпәсең. Их, шул-чакта дөньяның рәхәтлеге!

...Һм... Хыялга бирелеп киттем, ахры. Яшел чыршы — урман кунагы — өйгә кайтып утыр-маган бит әле. Хатынның да, әнә, Яңа елга ун көн кала йөзе җимерелгән иде һәм, чыршы булмый торып, аның, ачылып китеп, сүз әй-тәчәгенә өмет тә юк. Үткән елның ачы тәҗри-бәсеннән беләм. Бер атна буена тәмсез аш-ханә ашы да туйдырды... Анысы шулай, тик урманда аның каравылчысы да була бит әле. Алар да үз эшләрен яхшы белә шул. Тотыл-дыңмы — саллы гына штраф чәпәргә тора. Та-гын — кеше алдында хурлыгы...

Шулай да тәвәккәлләргә булдым. Минем дәү әти тагын: «Бүредән курыккан — урманга бармас», — дип әйтә торган иде.

Төннең иртәнгә авышкан вакытын чама-лап, чыгып машинамны кабыздым. Урманда хәзер мине сагалап кем утырыр дисең.

...«Минем янга кил» дә «минем янга кил» дип үзенә чакырып утырган иң матур бер чыр-шыны кисеп алу авыр булмады. «Урман сы-луын» ныклап урнаштырып та өлгермәдем,

артымда, урман каравылчысының булса кирәк:

— Тукта, бур! Кузгаласы булма! — дигәнен ишетеп, чак артыма авып китмәдем.

Кайда ул туктау! Урман каравылчысының тырпайган мыегы гына исемдә калган. Машинага ничек алай җитез кереп утырганымны, ничек кузгалып киткәнемне хәтерләмим. Ә исемә килгәндә өй алдына килеп туктаган идем инде. Азрак җан кергәч, эчтән генә көлеп тә куйдым. Йә, ничек, тоттыңмы, янәсе!

...Ниһаять, Яңа ел сәгатьләре сугарга да күп калмады. Без аны гаилә белән генә каршыларга яратабыз. Бүген хатынның йөзе кояш кебек, беркайчан да булмаганча, нур чәчә. Өстәл әзерләп йөргән җиреннән минем битемнән «әп» итеп алырга да өлгерә. Ә мин өйне ямьләп, ылыс исе таратып утырган чыршыга күз сирпәм...

Әнә шунда Яңа елны каршыларга урамга чыккан улым, шатлыктан йөзе балкып, йөгереп килеп керде дә:

— Әти, әни! Безгә Кыш бабай кереп килә! — дип хәбәр салды. Ул ара да булмады, ишекне киң ачып, зур гәүдәле, ап-ак сакаллы Кыш бабай өйгә үтте.

— Котлы булсын бәйрәмнәр! — диде ул карлыккан тавыш белән сәлам биргәннән соң. Урынымнан сикереп торып, аны түргә үтәргә чакырдым. Ә Кыш бабай шунда безнең бар өйгә ямь биреп утырган чыршыны күреп калды.

— Ничәмә кешедә булдым, тик мондый матур чыршыны беренче күрәм. Ай-һай-һай, чибәр! Аны тапкан ирне ир дисәң дә була, — дип хатынның салпы ягына сәлам кыстырды.

Ә аңа шул җитә калды (эндәшми генә торса да буласы икән) — урман кунагының тарихын сөйләде дә бирде. Кыш бабай көлә-көлә тыңлады да, ул сөйләп бетергәч, канәгать төс белән тамак кырып алды.

— Эһем... алай икән! — диде ул. Аннан ашыга башлады. — Ярый, миңа башка урыннарда да булырга кирәк әле. Бәйрәмнәрегез күңелле узсын, — диде сүз азагында. — Ә монысы балаларыгызга Кыш бабай күчтәнәче,— дип аларга үзенең бүләкләрен өләшеп чыкты. Аннан бер кәгазь алып нәрсәдер язды да:

— Ә менә бусы сиңа, — дип миңа тоттырды. Анда: «Сәмиев Кәлигә законсыз рәвештә урманнан чыршы кисеп алган өчен фәлән сум штраф түләргә», — дип язылган иде.

Шунда Кыш бабай үзенең битлеген салды. Аның астыннан урман каравылчысының тырпайган сары мыеклы йөзе килеп чыкты...

— Нәсим абыең булам, — диде ул миңа, кулын биреп. Аннан: — Ярый, сау булып торыгыз. Минем «күчтәнәч» бирәсе тагын берике «танышым» бар әле, — дип ишектән чыгып юк булды.

## ИСКЕ ГАДӘТ БУЕНЧА

Яңа оештырылган җәмгыятьнең башлангыч оешмасы рәисен сайлап кую өчен билгеләнгән җыелыш күп вакытны алмады, чөнки эш көне тәмамланган иде инде. Алып баручы башта ике сүз белән генә яңа оешманың барлыкка килү сәбәпләрен, әгъза булып керү кагыйдәләрен аңлатты. Шуннан нинди тәкъдимнәр

булыр дигән сорау куйды да, үзе өч кешене күрсәтте. Аннан аларны тикшерү башланды. Галиев шунда ук төшеп калды. Урыннан:

— Планын үтәми бит ул! — дип кычкырган бер тавыш ишетте моңа. Ә Вәлиевның кандидатурасын ярты җыелыш яклап, яртысы каралап чыкты. Ә менә Сәләевка барысы да бертавыштан кул күтәрде. «Үзебезнең кеше, сайлыйк», — диделәр. Аны чын күңелдән котладылар, яңа эшендә (җәмәгать эше генә булса ни!) зур уңышлар теләделәр. Таралыша башладылар. Шунда почмакта тын гына утырган Вәкилев, кинәт йокысыннан уянгандай, сикереп торды да:

— Туктагыз әле, иптәшләр! Болай булмый, бу вакыйганы «юарга» кирәк! — дип кычкырып җибәрде.

Аны кемдер күтәреп алды. Тик җыелыш өчкә бүленде. Коллектив икеләнүчеләр, тәкъдимне хуплап күтәреп алучылар һәм каршыларга таркалды. Каршылар, кул гына селтәп, кайтып китте. Икеләнүчеләрнең дә яртысы ишектә юк булды. Ә калган яртысын, сүз әйтә алмаслык дәлилләр китереп, үз якларына аудардылар.

— Гомер буена килгән йоланы бозабызмы?

— Күптән килгән гадәт бит, ә гадәт белән шаярырга ярамый.

— Яңа дәрәҗәсен «юмасаң», эше уң бармас бит әле, — дигәнрәк сүзләр дә ишетелде.

...Яңа рәисне «юу» мәҗлесе шау-шулы узды. Бер-бер артлы рюмкалар күтәрелде. Аңа күп теләкләр әйтелде, эшендә зур уңышлар теләделәр. Бу яңа җәмгыятькә йөкләтелгән эшнең моңача күрелмәгән биеклеккә күтәре-

ләчәгенә һич шик юклыгы кат-кат телгә алынды.

— Яшәсен безнең рәис! — дип оран салды кемдер. Аны «ура» кычкырып дәррәү күтәреп алдылар.

...Мәҗлес соң гына, яңа оешма башлыгыннан зур эшләр көтеп, таралды. Күпләрне күтәреп алып кайтып китәргә туры килде. Аек тормыш өчен көрәш җәмгыятенең башлангыч оешмасы рәисен сайлау өчен җыелган иде алар...

## БАЕП БУЛМАДЫ

Баеп булмады, егетләр. Әнә, кешеләргә карап торам да, шаккатам. Бер елны йорт сала, икенче елны машина ала, ә өченче елны яшь хатынлы була... Болай үзем төшеп калганнардан да түгелмен кебек. Юк, булмагач, булмый икән.

Ә менә фермерлар хәрәкәте турында Указ чыккач, күңелдә кечтеки генә өмет уянды. Нүжәли минем сәгать сукты?! Тукта әле, мин әйтәм, мин дә җир алыйм, мал асрыйм — баеп булмасмы? Тик тиз арада чыгымнарны каплап, файда китерә башлардай берәр шөгыль табарга кирәк. Уйлый торгач, дуңгыз үрчетергә булдым. Кяфер мал, хәрәм ит, дип тиргәсәләр дә, тиз үрчи, тиз симерә бит ул, каһәр суккан. Кяфер ашы дигәннән, шул ягы да бар: мөселманга ярамагач, үзең ашамыйсың, башка мөселманнарга сатып кына ятасың, ә үзең ашамый, сатып кына яткач, тизрәк баеыйсың да инде, әйе бит? Шәп бит, ә?!

...Чучка үрчетеп, бик тиз баеп киткән бер

урыс фермерына барып, утыз дуңгыз алып кайттым. Фәһемле киңәшләрен дә бирде. Тик аларга нәрсә ашаталар, шуны гына әйтмәде. Анысын үзем сорарга мәҗбүр булдым. Ул иңбашларын гына сикертте дә, «шуны да белмисеңмени?» дигәндәй:

— Соң, үзең нәрсә ашыйсың, шуны ашатасың инде, — дип кенә куйды.

«Үзе фермер булырга йөри, үзе берни белми», — дип уйлый күрмәсен, дип, төпченеп тормадым. Һәм, җиңне сызганып, эшкә тотындым. Тик, иртә уңмаган — кич уңмас, кич уңмаган — һич уңмас, кара сакалың кайда барсаң да артыңнан калмас, дип картлар белеп әйткән. Бер атна-ун көн дигәндә, чучкаларым аяк сузып бетте. Баедың болай булгач, баемый ни! Әллә дөрес тәрбияли белмәдем, әллә кяфер малы мөселманга баш бирергә теләмәде, аңламассың... Булыр алардан, начар кешене бер дә юкка «дуңгыз» димәсләр иде. Шулай да, күңелне корт кимерә. Тукта әле, дим, урыс Иванга барып, сорашып карыйм. Киттем. Ә ул инде череп баеган. Шулай-шулай, дим, чучкаларың җантәслим кылды. Ә бит барысын да син әйткәнчә эшләдем, тик барыбер кырылып беттеләр. Үзем ашаганны ашаттым, үзем эчкәнне эчердем, дим.

— Ә нәрсә ашыйсың-эчәсең соң син? — ди.

— Нигә, билгеле инде, татарның ашы — иртән дә чәй, кич тә чәй, — дим.

Урысым эчен тотып егылып китте. Кара, кара, әллә көлә инде?! Әй, бу урысның үзен дә аңламассың, дуңгызларын да. Кул селтәп, кайтып киттем. Ярый, баемагач, баемаган инде, баемый кеше үлмәгән әле. Кайтып, кайгыдан каралай яндырып, чәемне эчим, ичмасам.

**Инсур Мөсәнниф** (Инсур Гаделгәрәй улы Шәңгәрәев) 1958 елда Яңавыл районының Иткинәй авылында туып, шул ук районның Урал авылында үскән. Урта мәктәптән соң шоферлар курсын тәмамлагач, колхозда шофер, слесарь, кочегар, терлекче, көтүче булып эшли. 1980 — 1985 елларда Башкорт дәүләт педагогия институтында укый. Югары белем алгач, Тәтешле һәм Яңавыл район газитләрендә авыл хуҗалыгы бүлеге хәбәрчесе, җаваплы сәркатип урынбасары, хатлар һәм социаль-икътисади тормыш бүлекләре мөдире вазифаларын башкара, Яңавыл язучылар оешмасында әдәби консультант була. 1995 елның октябреннән — Яңавыл район газитендә мөхәррир урынбасары.

Әдәби иҗат белән мәктәп елларыннан ук мавыга, аның шигырьләре һәм хикәяләре Башкортстан, Татарстан республикаларының вакытлы матбугатында, төрле район газитләрендә татар, башкорт, рус телләрендә дөнья күрде, радио һәм телевидение аша бирелде, «Йәш көстәр», «Замандаш», «Бүә буе каеннары», «Тәлгәш» күмәк җыентыкларында басылды. 1996 елда «Тургайлар канат кага» күмәк җыентыгында «Бер гомер» дигән тәүге шигырьләр китабы чыкты. «Озак яшәү сере» — авторның беренче проза җыентыгы.

## ЭЧТӘЛЕК

### Учак яктысы

Авыл үре . . . . . . . . . . . . . 5
Кайту . . . . . . . . . . . . . 16
Юлдагы сөйләшү . . . . . . . . . 28
Каерылган канатлар . . . . . . . . 36
Учак яктысы . . . . . . . . . . 50
Чәчәкләр . . . . . . . . . . . 59
Таш сын . . . . . . . . . . . 65
Вөждан газабы . . . . . . . . . 70
Ходай хөкеме . . . . . . . . . 74
Бер-берсенә охшаган . . . . . . . 77
Җир тетрәү . . . . . . . . . . 81
Җаен тапты . . . . . . . . . . 84
Һәрнәрсәнең тәртибе бар . . . . . . 88
Тайгалак . . . . . . . . . . . 90
Чиратсыз аракы . . . . . . . . . 93
Гаилә кыйссалары . . . . . . . . 95
Табигый тойгы . . . . . . . . . 96
Тиргәсеннәр, әйдә... . . . . . . . 97
Шаярта бит ул... . . . . . . . . 98
Сабантуйда . . . . . . . . . . 101
Кое сатучы . . . . . . . . . . 105
Үсентеләр . . . . . . . . . . . 106
Ак бабай . . . . . . . . . . . 108
Зәңгәр чәчәкләр . . . . . . . . . 109
Исбат итте . . . . . . . . . . 111

### Ялангач дивар заманы

Телсез гармун зары . . . . . . . . 114
Дөнья — куласа . . . . . . . . . 118

Кара тавык йомыркасы . . . . . . . . . 122
«Экстра» сеанс . . . . . . . . . 125
Өч бажа . . . . . . . . . . . . 129
Кемнең сөяркәләре күбрәк . . . . . . . 134
Озак яшәү сере . . . . . . . . . . 138
Ялангач дивар заманы . . . . . . . 140
Кем түрә — шул көлә . . . . . . . . . 144
Көнчел күрше . . . . . . . . . . 147
Сакчыл Байтүрә . . . . . . . . . 151
Мин кайдан белим?! . . . . . . . . 158
Мин ничек имза җыйдым . . . . . . . 161
Куып җитәрбез . . . . . . . . . 164
Йөрәк өянәге . . . . . . . . . 166
Кыяр . . . . . . . . . . . . 168
Тимер рәшәткә . . . . . . . . . 171
Кием котлату . . . . . . . . . 176
Малайларга биргесез . . . . . . . 180
Бакча җимеше . . . . . . . . . 183
Янарал Арслан мажаралары . . . . . . 186
Шикаять . . . . . . . . . . 189
Яшь чакта ни булмас... . . . . . . 191
Сайлау арты программасы . . . . . . 194
Әнә, алар оялсын . . . . . . . . 199
Өстәмә сорау . . . . . . . . . . 202
Куян шулпасының шулпасы . . . . . . 204
Рәхмәт, энем! . . . . . . . . . 208
Иң шәп бүләк . . . . . . . . . 211
Кыш бабай күчтәнәче . . . . . . . 214
Иске гадәт буенча . . . . . . . . 217
Басп булмады . . . . . . . . . 219

Литературно-художественное издание

**Инсур Гаделгареевич Шангареев**

(Инсур Мусанниф)

**СЕКРЕТ ДОЛГОЛЕТИЯ**

*(на татарском языке)*

Редакция мөдире **Сабир Шәрипов**
Мөхәррире **Динә Морзакаева**
Рәссамы **Марат Байназаров**
Бизәүче мөхәррир **Рәшит Рамазанов**
Техник мөхәррире **Венера Абдрахманова**
Корректоры **Зилә Адыева**

Лицензия № 0168, 10.04.96

Җыярга бирелде 27.05.97. Басарга кул куелды 18.09.97. Кәгазь форматы 70×90¹/₃₂. Китап-журн. кәгазе. Әдәби гарнитура. Калку ысул белән басылды. Шартлы басма таб. 8,19. Шартлы буяу отт. 8,37. Исәп-нәшер таб. 7,75. Тиражы 4000 данә. Заказ № 443. Бәясе ирекле.

Башкортстан «Китап» нәшрияты, 450001, Уфа, Левченко урамы, 4а. Уфа полиграфия комбинаты, 450001, Уфа, Октябрь проспекты, 2.